МӨСЕЛМАННЫҢ КАЛКАНЫ

Иң кирәкле догалар

Өшкерү тәртибе

Исме Әгъзам

Китабият үзәге
Рисаля
Издательский центр

ИҢ КИРӘКЛЕ ДОГАЛАР

Беренче басма

Казан 2014

ББК 86.38
© Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

بسم الله الرحمن الرحيم

Зикернең фазыйләте

Аллаһ ﷻ әйтте:

«Мине итагатьлек белән зикер итегез! Мин сезне савап вә мәгьфират белән искә алырмын. Миңа шөкер итегез һәм көферлек кылмагыз»[1]

Янә Аллаһ ﷻ әйтте:

«Әй иман китерүчеләр! Аллаһны күп зикер итегез!»[2]

Янә Аллаһ ﷻ әйтте:

«Аллаһны күп зикер кылучы ирләр һәм хатыннар, Аллаһ аларга мәгьфират һәм олуг әҗер-саваплар хәзерләде»[3]

Янә Аллаһ ﷻ әйтте:

«Раббыңны көннең әүвәлендә һәм

1 әл-Бәкара 152
2 әл-Әхзәб 41
3 әл-Әхзәб 35

ахырында түбәнчелек вә курку илә эчеңнән генә кычкырмыйча зикер ит, һәм дә гафилләрдән булма»[4]

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

– ***«Раббысын зикер итүче һәм Аны зикер итмәүчеләрнең мисалы — тере һәм үле кебек»***[5]

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

– ***«Сезгә, Раббыгыз каршында иң пакьрәге булган, дәрәҗәләрегезне иң югарыга күтәргән, сезнең өчен алтын вә көмеш сарыф итүдән дә хәерлерәк булган, һәм башларыгызны чабучы вә сез аларның башларын чаба торган дошманнарыгыз белән очрашудан да яхшырак булган, иң хәерле гамәлегезне әйтимме?», — диде. Алар: «Әлбәттә!», — диделәр. Пәйгамбәр ﷺ: «Аллаһ тәгаләне зикер итү», — диде.***

4 әл-Әгъраф 205
5 әл-Бохари 6407

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

– *«Аллаһ тәгалә әйтә: «Колым Мине нинди дип саный, Мин шундый булырмын[6], һәм ул Мине зикер иткәндә, Мин аның белән бергә булам[7]. Әгәр ул Мине яшерен зикер итсә, Мин дә аны яшерен зикер итәрмен; әгәр ул Мине башка кешеләр янында зикер итсә, Мин аны алардан да хәерлерәкләр (ягъни, фәрештәләр) янында зикер итәрмен; әгәр ул Миңа бер карышка якынайса, Мин аңа бер терсәккә якынаермын; әгәр ул Миңа бер терсәккә якынайса, Мин аңа бер сажинга[8] якынаермын; әгәр ул Миңа атлап килсә, Мин аңа йөгереп килермен», — диде»[9]*

6 Ягъни, кеше Аллаһтан нәрсә өмет итсә, Аллаһ аңа шуны эшләр

7 Ягъни, Аллаһ аңа бу вакытта ярдәм итә

8 Сажин - озынлык үлчәү берәмлеге

9 әл-Бохари 7405, Мөслим 2675

Габдуллаһ бин Бүсрадан ﷺ риваять итеңә:

– ***«Бер кеше пәйгамбәребезгә ﷺ: «Әй Аллаһның расүле! Дөреслектә, Исламның хөкемнәре минем өчен бик күбәйде, син миңа мин нык үти торган берәр нәрсә әйт», — диде. Пәйгамбәр ﷺ аңа: «Синең телең һәрдаим Аллаһны зикер итүдән туктамасын», — диде»***

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

– ***«Кем Корьәннән бер хәреф укый икән, аңа шуның өчен бер яхшылык языла, ә һәрбер яхшылык өчен ун әҗер бирелә. Мин «ӘлифЛәәмМиим» — бер хәреф ул дип әйтмим, юк, «Әлиф» — хәреф, «Ләм» — хәреф һәм «Мим» — хәреф»***[10]

Гукъбә бин Гамир ﷺ әйтте:

– ***«Бервакыт без әс-Суффәдә***[11]

10 әт-Тирмизи 2910

11 Пәйгамбәр ﷺ заманында, аның мәчетендә фәкыйрь мөһәҗирләр өчен билгеләнгән махсус урын, шуңа да алар «әс-Суффә әһелләре» дип аталдылар

булганда, безнең янныбызга Аллаһның расуле ﷺ чыкты, һәм: «Кайсыгыз көндә иртә белән Бутхәнга[12] яки әл-Гакыйкка[13] барып бернинди гөнаһ кылмыйча һәм туганнары белән кардәшлекне өзмичә ике зур өркәчле дөяне алып кайтасы килә?», — дип сорады. Без: «Әй Аллаһның расуле! Без!», — дидек. Ул: «Сезнең берәрегезнең иртә белән мәчеткә барып Аллаһ ﷻ Коръәненнән ике аять өйрәнүе яки укуы ул ике дөядән хәерлерәк була. Өчне укуы өч дөядән, дүртне укуы – дүрттән хәерлерәк, һәм шулай күпме укыганга карап дөя саннары да була», — диде»[14]

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

– «Кем дә кем Аллаһны зикер итмичә (искә алмыйча) кая гына булса да утыра икән, аңа Аллаһның

12 Мәдинә янында булган урынның исеме

13 Мәдинәдәге үзәнлекнең исеме

14 Мөслим 803

тирасы[15] булыр. Шулай ук, кем дә кем Аллаһны искә алмыйча кая гына булса да ята икән, аңа да Аллаһның тирасы булыр»[16]

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

«Әгәр кешеләр Аллаһ тәгаләне зикер итмәгән һәм пәйгамбәрләренә салават әйтмәгән мәҗлестә (җыенда) булсалар, аларга һичшиксез тира (хәсрәт) ирешер. Әгәр Аллаһ теләсә аларны җәза кылыр, теләсә гафу итәр»[17]

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

«Әгәр дә кешеләр бер урында утырганнан соң Аллаһ тәгаләне зикер итмичә (искә алмыйча) торып китәләр икән, ул кешеләр сасыган ишәк үләксәсе янынан торып киткән кебек китәрләр һәм аларга хәсрәт булыр»[18]

15 Ягъни, ул кешегә Аллаһтан хәсрәт булыр
16 Әбү Дауыд 4856
17 әт-Тирмизи 3380
18 Әбү Дауыд 4855

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

«Хакыйкатьтә, Раббыгыз тәбәракә вә тәгалә оялчан һәм юмарт. Колы Аңа кулларын күтәреп дога кылса, аның кулларын буш кайтарудан, аннан ояла»[19]

Дога кылуның әдәпләре

Аллаһка дога кылганда кабул булсын өчен түбәндәгеләрне эшләү мөһим:

1 – Ихласлык;

2 – Доганы Аллаһка хәмед-сәнә вә пәйгамбәргә салават белән башлау, тәмамлаганда да шулай ук бетерү.

3 – Җитдилек белән сорау, доганың кабуллыгына инану һәм ашыктырмау.

4 – Күңел вә йөрәк белән бирелү.

5 – Шатлыкта да, кайгыда да дога

19 Әбү Дауыд 1488

белән ялвару.

6 – Догада Аллаһтан башкага ялвармау.

7 – Үзеңне, гаиләңне, балаларыңны һәм байлыгыңны, берсен дә ләгънәт кылмау.

8 – Аллаһка ялварганда бик кычкырып та, бик эчтән дә дога кылмау, ә уртача ялвару.

9 – Барча гөнаһларны тану һәм алар өчен гафу сорау, шулай ук Аллаһның рәхмәтен танып Аңа шөкер кылу.

10 – Доганың сүзләрен ясалма рәвештә рифмага салмау. Сораганда хәерлене генә сорау.

11 – Дога кылганда тыйнаклык, буйсынучанлык, өмет һәм курку белдерү.

12 – Хаксыз алынган нәрсә булса, аны хуҗасына кайтару һәм тәүбә итү.

13 – Доганы 3 тапкыр кабатлап әйтү.

14 – Кыйблага таба юнәлү.

15 – Дога кылганда кулларны күтәрү.

16 – Таһәратле булу.

17 – Дога кылучы изгелеккә өндәүче вә бозыклыктан тыючылардан булу.

18 – Башка кеше өчен дога кылганда, иң әүвәле үзең өчен сорау.

19 – Аллаһның күркәм исемнәрен вә камил сыйфатларын әйтеп сорау.

20 – Гөнаһлардан саклану һәм сораучының ризыгы да, киеме дә хәләл юл белән кәсеп ителгән булу.

21 – Гөнаһка вә туганлык җепләрен өзүгә китерә торганны сорамау.

Дога кабул була торган вакытлар һәм урыннар

1 – Кадер кичендә.

2 – Төннең өченче өлешендә.

3 – Азан белән камәт арасында.

4 – Яңгыр яуганда.

5 – Мөлтәзәмдә[20].

6 – Җомга көненең бер өлешендә.

7 – Зәмзәм суы эчкәндә.

8 – Сәҗдә вакытында.

9 – Фарыз намазларыннан соң.

10 – Тәшәһһүд ахырында.

11 – Мөселман кардәшең гаип (янында булмаган) вакытта аның өчен дога кылу.

12 – Гарәфәт көнендә (хаҗда булучы).

13 – Рамазан аенда.

20 Кәгьбәтуллаһның ишеге белән кара таш арасындагы урын

14 – Золым кылынган вә җәберләнгән кешенең догасы.

15 – Ата-ананың балага карата догасы.

16 – Юлчының догасы.

17 – Ураза тотучының догасы.

18 – Авыз ачканда.

19 – Гадел имамның догасы.

20 – Изге баланың догасы.

21 – Хаҗда беренче ике баганага таш аткач.

22 – Кәгьбәтуллаһ эчендә, шулай ук хиҗер эчендә, чөнки ул Кәгьбәтуллаһның бер өлеше.

23 – Сафа һәм Мәрьва калкулыкларында.

Гомумән алганда, мөселман һәрвакытта да Аллаһка дога белән ялварырга тиеш, чөнки Аллаһ әйтте: **«Әгәр колларым синнән Минем турында сорасалар, хакыйкатьтә, Мин якын. Дога кылучы Миңа дога белән**

мөрәҗәгать итсә, Мин мөрәҗәгатенә җавап бирәмен».[21] Шулай да, искә алып узган вакытларга һәм урыннарга аерым әһәмият бирергә кирәк.

1 – Йокыдан уянгач та укыла торган зикер-догалар

١ – «اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِى أَحْيَانَا بَعْدَ مَا أَمَاتَنَا وَإِلَيْهِ النُّشُورُ»

1 – /Әлхәмду лилләһилләҙи әхйәнә бәгьдә мә әмәтәнә үә иләйһиннүшүр/

1 — «Безне үле кылганнан соң[22] терелткән Аллаһка барча мактаулар булсын, һәм Аңа кире терелеп Кыяматтә җыелу»[23].

٢ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَىْءٍ قَدِيرٌ سُبْحَانَ اللَّهِ

21 әл-Бәкара 186
22 Йокы – үлемнең кече кардәше
23 әл-Бохари 6312

وَالْحَمْدُ لِلَّهِ وَلَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَاللَّهُ أَكْبَرُ وَلَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللَّهِ الْعَلِيِّ الْعَظِيمِ، رَبِّ اغْفِرْ لِي»

2 – /Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәһү лә шәрикә ләһ, ләһүл-мулкү үә ләһүл-хәмдү үә һүә галә күлли шәй'ин кадир, сүбхәнАллаһи үәлхәмдүлилләһи үә лә иләһә иллә Аллаһ, үә Аллаһү әкбәръ, үә лә хәүлә үә лә куәтә иллә билләһил-галийил-гаҙыйм, Раббигьфирли/

2 — «Аллаһтан башка һич иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау һәм Ул бар нәрсәгә кодрәтле. Аллаһ барча кимчелектән пакь вә Аңа барча мактау һәм Аллаһтан башка иләһ юк. Аллаһ бөек, һәм әл-Галий әл-Газыйм булган Аллаһтан башка көч-куәт юк. Раббым, мине ярлыка»[24].

24 Ибен Мәжәһ 3878. (Кем төнлә уянганнан соң ошбу сүзләрне әйтсә – гөнаһлары ярлыканыр, дога кылса – догасы кабул булыр, торып таһәратләнеп намаз укыса – намазы кабул булыр)

٣ – «الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي عَافَانِي فِي جَسَدِي وَرَدَّ عَلَيَّ رُوحِي وَأَذِنَ لِي بِذِكْرِهِ»

3 – /Әлхәмдүлилләһилләҙи гафәни фи җәсәди үә раддә галәййә рухи үә әҙинә ли биҙикриһи/

3 — «Минем тәнемне савыктырган, җанымны кайтарган һәм миңа Аны зикер итәргә рөхсәт иткән *Аллаһка* барча мактаулар булсын»[25]

2 – Яңа кием кигәндә укыла торган дога

٤ – «اللَّهُمَّ لَكَ الْحَمْدُ أَنْتَ كَسَوْتَنِيهِ، أَسْأَلُكَ خَيْرَهُ وَخَيْرَ مَا صُنِعَ لَهُ، وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهِ وَشَرِّ مَا صُنِعَ لَهُ»

4 – /Аллаһуммә ләкәлхәмд! Әнтә кәсәутәниһи әс'әлүкә хайраһү үә хайрә мә сунига ләһү, үә әгүҙү бикә мин шәрриһи үә шәрри мә сунига ләһү/

25 әт-Тирмизи 3401

4 — «Әй Аллаһ, Сиңа барча мактау! Син мине киендердең. Синнән бу киемнең яхшылыгын вә аның нәрсә өчен эшләнгәненең яхшылыгын сорыйм, һәм Сиңа аның явызлыгыннан вә аның нәрсә өчен эшләнгәненең явызлыгыннан сыенам»[26]

3 – Кием кигәндә укыла торган дога

٥ — «الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِى كَسَانِى هَذَا الثَّوْبَ وَرَزَقَنِيهِ مِنْ غَيْرِ حَوْلٍ مِنِّى وَلاَ قُوَّةٍ»

5 – /Әлхәмдулилләһилләҙи кәсәни һәҙәҫ-ҫәүбә үә разәканиһи мин гайри хәүлин минни үә лә куүәһ/

5 — «Минем көч-куәтемнән тыш, мине ошбу киемгә киендергән вә аның белән мине ризыкландырган Аллаһка барча мактаулар булсын»[27]

26 Әбү Дауыд 4020, ибен Мәҗәһ 1767

27 Әбү Дауыд 4023. (Кем кием кигәндә ошбу доганы әйтсә, аның гөнаһлары ярлыканыр)

4 – Яңа кием киючегә әйтелә торган дога

٦ – «الْبَسْ جَدِيدًا وَعِشْ حَمِيدًا وَمُتْ شَهِيدًا»

6 – /Илбәс җәдидән үә гыйшь хәмидән үә мүт шәһидән/

6 — «Яңа килеш ки, мактауга лаек булып яшә һәм шәһид булып үл»[28]

5 – Кием салгач әйтелә

٧ – «بسم الله»

7 – /Бисмилләһ/

7 — «Аллаһ исеме белән»[29]

6 – Бәдрәфкә кергәндә укыла торган дога

28 Ибен Мәҗәһ 3558

29 Сахих әл-Җәмигь вә әс-Сагыйр 3610. (Кием салгач бу сүзне әйтү кешеләрнең гаурәтләре белән җеннәрнең күзләре арасында пәрдә булып тора)

٨ – «[بسم الله] اَللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْخُبْثِ وَالْخَبَائِثِ»

8 – /Бисмилләһ! Аллаһүммә инни әгүҙү бикә минәл-хубҫи үәл-хабәиҫ/

8 — «Аллаһ исеме белән! Әй Аллаһ! Хакыйкатьтә, мин Сиңа ир һәм хатын-кыз җенесеннән булган җеннәрдән сыенам»[30]

7 – Бәдрәфтән чыккач

٩ – «غُفْرَانَكَ»

9 – /Гуфранәк/ — дип әйтелә

9 — «Гафу ит»[31]

8 – Таһәрат алдыннан әйтелә

١٠ – «بسم الله»

10 – /Бисмилләһ/

10 — «Аллаһ исеме белән»[32]

30 әл-Бохари 142, Мөслим 375

31 Әбү Дауыд 30

32 Әбү Дауыд, ибен Мәҗәһ

9 – Таһәрат алганнан соң әйтелә торган зикер-дога

١١ – «أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ اللَّهُمَّ اجْعَلْنِى مِنَ التَّوَّابِينَ وَاجْعَلْنِى مِنَ الْمُتَطَهِّرِينَ»

11 – /Әшһәдү әллә иләһә иллә-Аллаһ, үәхдәһү лә шәрикә ләһү үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһү үә расүлүһ. Аллаһүммәҗгални минәт-тәүүәбин үәҗгални минәл-мүтә-таһһирин/

11 — «Шаһитлык кылам — хакыйкатьтә, Аллаһтан башка иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Шаһитлык кылам — хакыйкатьтә, Мөхәммәд Аның колы вә расүле. Әй Аллаһ! Мине күп тәүбә кылучылардан һәм пакьланучылардан кыл»[33]

33 эт-Тирмизи 55. (Кем таһәратне иң күркәм рәвештә, барча сөннәтләре белән алса һәм аннары ошбу сүзләрне әйтсә, аңа Җәннәтнең сигез ишеге ачылыр һәм ул теләгән ишегеннән керер)

10 – Өйдән чыкканда укыла торган дога

١٢ – «بِسمِ اللهِ تَوَكَّلْتُ عَلَى اللهِ،
وَلا حَولَ وَلا قُوَّةَ إلاَّ باللهِ»

12 – /Бисмилләһ, тәүәккәлтү галә-Аллаһ, үә лә хәүлә үә лә куүәтә иллә билләһ/

12 — «Аллаһ исеме белән. Мин Аллаһка тәвәккәлләдем һәм Аллаһтан башка көч тә, куәт тә юк»[34]

11 – Өйгә кергәндә укыла торган дога

١٣ – «بِسْمِ اللَّهِ وَلَجْنَا وَبِسْمِ اللَّهِ خَرَجْنَا وَعَلَى اللَّهِ رَبِّنَا تَوَكَّلْنَا» ثُمَّ لِيُسَلِّمْ عَلَى أَهْلِهِ

13 – /Бисмилләһи үәләҗнә үә бис-

34 Әбү Дауыд 5095. Кеше өеннән чыкканда ошбу доганы укыса, аңа: «Син туры юлдан баручы, тынычсызлык китерә торган нәрсәләрдән котылучы һәм барча явызлыклардан сакланучысың», – дип әйтелер, һәм шәйтан аннан ераклашыр

милләһи хараҗнә үә галәАллаһи раббинә тәүәккәлнә/

13 — «Аллаһ исеме белән кердек вә Аллаһ исеме белән чыктык һәм Раббыбыз Аллаһка тәвәккәлләдек»

Бу сүзләрне әйткәннән соң, керүче йорт әһелләренә сәлам бирә[35].

12 – Мәчеткә барганда укыла торган дога

١٤ – «اللَّهُمَّ اجْعَلْ فِى قَلْبِى نُورًا، وَفِى بَصَرِى نُورًا، وَفِى سَمْعِى نُورًا، وَعَنْ يَمِينِى نُورًا، وَعَنْ

35 Әбү Дауыд 5096. Мөслимдә (2018) килгән риваятьтә болай диелде: «Әгәр кеше өенә кергәндә һәм ашаганда Аллаһ тәгаләне зикер итсә (ягъни, Бисмилләһ дип әйтсә), шәйтан үзенең иярченнәренә: «Сезгә монда торырга урын да, ашарга ризык та юк!», — дип әйтер. Әгәр ул кеше өенә кергәндә Аллаһ тәгаләне зикер итмичә керсә, шәйтан иярченнәренә: «Сез торырга урын таптыгыз», — дип әйтер. Әгәр ул ашаганда да Аллаһ тәгаләне зикер итмәсә, шәйтан үзенең иярченнәренә: «Сез торырга урын да, ашарга ризык та таптыгыз!», — диер

يَسَارِى نُورًا، وَفَوْقِى نُورًا، وَتَحْتِى نُورًا، وَأَمَامِى نُورًا، وَخَلْفِى نُورًا، وَاجْعَلْ لِى نُورًا»

14 – /Аллаһүммәҗгал фи калби нүран, үә фи бәсари нүран, үә фи сәмги нүран, үә ган йәмини нүран, үә ган йәсәри нүран, үә фәүкый нүран, үә тәхти нүран, үә әмәми нүран, үә халфи нүран, үәҗгал-ли нүран/

14 — «Әй Аллаһ! Йөрәгемдә, күрүемдә, ишетүемдә, уң ягымда, сул ягымда, өстемдә, астымда, алдымда вә артымда нур кыл, һәм миңа нур бир»[36]

13 – Мәчеткә кергәндә укыла торган дога

١٥ – «بِسْمِ اللَّهِ وَالسَّلَامُ عَلَى رَسُولِ اللَّهِ اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِى ذُنُوبِى وَافْتَحْ لِى أَبْوَابَ رَحْمَتِكَ»

36 әл-Бохари 6316. Шулай ук бу хәдис башка өстәмәләр белән башка хәдисләр җыентыгында да бар

15 – /Бисмилләһ, үәссәләму галә расүлилләһ, Аллаһүммәгьфир ли ҙунуби үәфтәх ли әбүәбә рахмәтик/

15 — «Аллаһ исеме белән, Аллаһ расүленә сәлам. Әй Аллаһ! Минем гөнаһларымны ярлыка һәм миңа Үзеңнең рәхмәт ишекләреңне ач»[37]

14 – Мәчеттән чыкканда укыла торган дога

١٦ — «بِسْمِ اللَّهِ وَالسَّلاَمُ عَلَى رَسُولِ اللَّهِ اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِى ذُنُوبِى وَافْتَحْ لِى أَبْوَابَ فَضْلِكَ»

16 – /Бисмилләһ, үәссәләму галә расүлилләһ, Аллаһүммәгьфир ли ҙунуби үәфтәх ли әбүәбә фәдълик/

16 — «Аллаһ исеме белән, Аллаһ расүленә сәлам. Әй Аллаһ! Минем гөнаһларымны ярлыка һәм миңа Үзеңнең фазыйләт ишекләреңне ач»[38]

37 Ибен Мәҗәһ 771
38 Ибен Мәҗәһ 771

15 – Азан әйткәндә укыла торган зикер-догалар

17 — Тыңлаучы азанны мөәзин артыннан кабатлап бара, һәм ул:

«حَيَّ عَلَى الصَّلاَةِ وَحَيَّ عَلَى الْفَلاَحِ»

/Хәййә галәс-саләһ. Хәййә галәс-саләһ. Хәййә галәл-фәләх. Хәййә галәл-фәләх/

дигәннән соң, кабатлап баручы һәрбер җөмләдән соң:

«لاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللَّهِ»

/Лә хәүлә үә лә куүәтә иллә биллләһ/ — дип әйтә.

18 — Мөәзин азанда шәһәдәт кәлимәләрен әйткәннән соң, тыңлаучы болай ди:

«أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَأَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ رَضِيتُ بِاللَّهِ رَبًّا وَبِمُحَمَّدٍ رَسُولاً وَبِالإِسْلاَمِ دِينًا»

/Әшһәду әллә иләһә илләАллаһ, үәхдәһү лә шәрикә ләһү үә әшһәду әннә Мүхәммәдән габдүһү үә расүлүһ, радыйтү билләһи раббә, үә би-Мүхәммәдин расүлә, үә бил-исләми динә/

«Шаһитлык кылам - хакыйкатьтә, Аллаһтан башка иләһ юк, һәм шаһитлык кылам - хакыйкатьтә, Мөхәммәд Аның колы вә расүле. Мин Аллаһтан Раббы буларак, Мөхәммәдтән расүл буларак һәм Исламнан дин буларак разыймын»

19 — Мөәзин артыннан кабатлап бетергәч пәйгамбәребезгә салават әйтә

٢٠ — «اللَّهُمَّ رَبَّ هَذِهِ الدَّعْوَةِ التَّامَّةِ وَالصَّلاَةِ الْقَائِمَةِ آتِ مُحَمَّدًا الْوَسِيلَةَ وَالْفَضِيلَةَ وَابْعَثْهُ مَقَامًا مَحْمُودًا الَّذِى وَعَدْتَهُ [إِنَّكَ لاَ تُخْلِفُ الْمِيعَاد]»

20 – /Аллаһүммә раббә һәзиһид-дәгүәтит-тәәммәһ, үәс-салятил-

каʻимәһ, әти Мухәммәдәнил-үәсиләтә үәл-фәдыйләһ, үәбгаҫһү мәкамән мәхмүдәнилләҙи үәгадтәһ, иннәкә лә тухлифул-мигад/

20 — «Әй, бу мөкәммәл чакыруның һәм торгызыласы намазның Раббысы булган Аллаһ! Мөхәммәдкә бөек вә югары дәрәҗә бир һәм аны Үзең вәгъдә иткән мактаулы урынга җибәр! Хакыйкатьтә, Син вәгъдәңне бозмыйсың!»[39]

16 – Истифтәх догасы

٢١ – «سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ وَبِحَمْدِكَ وَتَبَارَكَ اسْمُكَ وَتَعَالَى جَدُّكَ وَلاَ إِلَهَ غَيْرُكَ»

21 – /Сүбхәнәкә Аллаһүммә үә бихәмдикә үә тәбәракәсмүкә үә тәгалә җәддүкә үә лә иләһә гайрукь/

21 — «Әй Аллаһ! Син барча кимчелекләрдән пакь һәм Сиңа

39 әл-Бохари 614. Кем азаннан соң ошбу доганы укыса, аңа Кыямәт Көнендә пәйгамбәребезнең шәфәгате ирешер

барча мактау! Синең исемең мөбәрак, Синең бөеклегең югары һәм Синнән башка иләһ юк!»[40]

۲۲ – «اللَّهُمَّ بَاعِدْ بَيْنِى وَبَيْنَ خَطَايَاىَ كَمَا بَاعَدْتَ بَيْنَ الْمَشْرِقِ وَالْمَغْرِبِ اللَّهُمَّ نَقِّنِى مِنْ خَطَايَاىَ كَمَا يُنَقَّى الثَّوْبُ الأَبْيَضُ مِنَ الدَّنَسِ اللَّهُمَّ اغْسِلْنِى مِنْ خَطَايَاىَ بِالثَّلْجِ وَالْمَاءِ وَالْبَرَدِ»

22 – /Аллаһуммә бәгид бәйни үә бәйнә хатайәйә кәмә бәгадтә бәйнәл-мәшрикый үәл-мәгърибби. Аллаһуммә нәкъкыйни мин хатайәйә кәмә йүнәкъка әҫ-ҫәүбүл-әбйәду минәд-дәнәси. Аллаһуммәгъсилни мин хатайәйә биҫ-ҫәлҗи үәл-мә‘и үәл-бәради/

22 — «Әй Аллаһ! Мине хаталарымнан мәшрикъны мәгърибтан ерак кылган кебек ерагайт. Әй Аллаһ! Ак киемне пычрактан пакьләганнары кебек, мине хаталарымнан пакьлә. Әй Аллаһ! Мине хаталарымнан кар,

40 Мөслим 399 һәм дүрт «Сөннәт» ияләре

су һәм бозлы яңгыр белән юу»[41]

17 – Рөкүгь догасы

٢٣ – «سُبْحَانَ رَبِّىَ الْعَظِيمِ»

23 – /Сүбхәнә раббиәл-газыйм/ 3 тапкыр

23 — «Бөек Раббым барча кимчелектән пакь»[42]

٢٤ – «سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ رَبَّنَا وَبِحَمْدِكَ، اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِى»

24 – /Сүбхәнәкә, Аллаһүммә, Раббәнә үә бихәмдикә, Аллаһүммәгьфир ли/

24 — «Әй Аллаһ! Безнең Раббыбыз! Син барча кимчелектән пакь һәм Сиңа барча мактау! Әй Аллаһ! Мине гафу ит!»[43]

41 әл-Бохари 744, Мөслим 598

42 Мөслим 772 (3 тапкырсыз), һәм 4 «Сөннәт»

43 әл-Бохари 794, Мөслим 484

٢٥ – «سُبُّوحٌ قُدُّوسٌ رَبُّ الْمَلاَئِكَةِ وَالرُّوحِ»

25 – /Сүббүхүн, Куддүсүн, Раббүлмәлә‘икәти үәр-рух/

25 — «Барча кимчелекләрдән пакьнең пагы, мөкатдәснең мөкатдәсе, фәрештәләрнең һәм Җәбра‘илнең Раббысы»[44]

18 – Рөкүгьтан торгач укыла торган дога

٢٦ – «سَمِعَ اللَّهُ لِمَنْ حَمِدَهُ»

26 – /СәмигАллаһү лимән хәмидәһ/

26 — «Аллаһ Үзен мактаучыны ишетә»[45]

٢٧ – «رَبَّنَا وَلَكَ الْحَمْدُ، حَمْدًا
كَثِيرًا طَيِّبًا مُبَارَكًا فِيهِ»

27 – /Раббәнә үә ләкәл-хәмдү, хәмдән кәҫиран тайибән мүбәракән

44 Мөслим 487
45 әл-Бохари 689

фиһи/

27 — «Әй Раббыбыз! Сиңа гына барча мактау! Сиңа гына күп, яхшы, мөбәрак булган мактау!»[46]

19 – Сәждә догасы

٢٨ – «سُبْحَانَ رَبِّىَ الأَعْلَى»

28 – /Сүбхәнә раббиәл-әгълә/

28 — «Әгълә (иң югары) булучы Раббым барча кимчелектән пакь»[47]

٢٩ – «سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ رَبَّنَا وَبِحَمْدِكَ، اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِى»

29 – /Сүбхәнәкә, Аллаһүммә, Раббәнә үә бихәмдикә, Аллаһүм-мәгьфир ли/

29 — «Әй Аллаһ! Безнең Раббыбыз! Син барча кимчелектән пакь һәм Сиңа барча мактау! Әй Аллаһ! Мине гафу ит!»[48]

46 әл-Бохари 799

47 Мөслим,. Ибен Мәҗәһ 888

48 әл-Бохари 794, Мөслим 484

٣٠ – «اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِى ذَنْبِى كُلَّهُ دِقَّهُ وَجِلَّهُ وَأَوَّلَهُ وَآخِرَهُ وَعَلاَنِيَّتَهُ وَسِرَّهُ»

30 – /Аллаһүммəгьфир ли ҙəнби күлләһү дикъкаһү үә җилләһү үә әүүәләһү үә әхыйраһү үә галәнийәтәһү үә сирраһү/

30 — «Әй Аллаһ! Минем кече һәм олы, әүвәлге һәм ахыргы, ачык һәм яшерен булган барча гөнаһларымны да ярлыка!»[49]

20 – Ике сәҗдә арасында утырганда укыла торган дога

٣١ – «رَبِّ اغْفِرْ لِى رَبِّ اغْفِرْ لِى»

31 – /Раббигъфир ли, раббигъфир ли/

31 — «Әй Раббым! Мине гафу ит! Әй Раббым! Мине гафу ит!»[50]

49 Мөслим 483

50 Әбү Дауыд 874

٣٢ – «اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِي، وَارْحَمْنِي، وَاهْدِنِي، وَاجْبُرْنِى، وَعَافِنِي، وَارْزُقْنِي، وَارْفَعْنِى»

32 – /Аллаһүммәгъфир ли, үәрхәмни, үәһдини, үәҗбүрни, үә гәфини, үәрзүкъни, үәрфәгьни/

32 — «Әй Аллаһ! Мине гафу ит, миңа рәхимле бул, мине һидәяткә күндер, мине төзәт, мине котылдыр, мине ризыкландыр һәм мине югары кыл!»[51]

21 – Тиләвә сәҗдәсенең догасы

٣٣ – «سَجَدَ وَجْهِى لِلَّذِى خَلَقَهُ وَشَقَّ سَمْعَهُ وَبَصَرَهُ بِحَوْلِهِ وَقُوَّتِهِ { فَتَبَارَكَ اللَّهُ أَحْسَنُ الْخَالِقِينَ }»

33 – /Сәҗәдә үәҗһи лилләҙи халәкаһү үә шәкъка сәмгьәһү үә бәсараһү бихәүлиһи үә куүәтиһи {фәтәбәракАллаһү әхсәнул-халикыйн}/

51 Әбү Дауыд 850, әт-Тирмизи 284, ибен Мәҗәһ 898

33 — «Минем йөзем, аны Үзенең көч вә куәте белән халикъ кылучысына һәм аңа ишетү белән күрүне бирүчесенә сәҗдә кылды. {Бердәнбер иң яхшы халикъ кылучы Аллаһ мөбәрак булды!}»[52]

٣٤ – «اللَّهُمَّ اكْتُبْ لِى بِهَا عِنْدَكَ أَجْرًا وَضَعْ عَنِّى بِهَا وِزْرًا وَاجْعَلْهَا لِى عِنْدَكَ ذُخْرًا وَتَقَبَّلْهَا مِنِّى كَمَا تَقَبَّلْتَهَا مِنْ عَبْدِكَ دَاوُدَ»

34 – /Аллаһүммәктүб ли биһә гыйндәкә әҗра, үә дагь ганни биһә үизра, үәҗгалһә ли гыйндәкә ҙүхра, үә тәкаббәлһә минни кәмә тәкаббәлтәһә мин габдикә Дәүд/

34 — «Әй Аллаһ! Миңа аның[53] белән Үзеңдә әҗер яз, аның белән миннән гөнаһымны җуй, аны минем өчен Үзеңдә өлеш ит, һәм аны Үзеңнең колың Даудтан кабул иткән кебек миннән дә кабул ит!»[54]

52 Әбү Дауыд 1414, һәм башкалар

53 Сәҗдә өчен

54 эт-Тирмизи 579

22 – Тәшәhhүд догасы

٣٥ – «التَّحِيَّاتُ لِلَّهِ وَالصَّلَوَاتُ وَالطَّيِّبَاتُ، السَّلاَمُ عَلَيْكَ أَيُّهَا النَّبِىُّ وَرَحْمَةُ اللَّهِ وَبَرَكَاتُهُ، السَّلاَمُ عَلَيْنَا وَعَلَى عِبَادِ اللَّهِ الصَّالِحِينَ، أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ»

35 – /Әттәхиятү лилләhи үәс-саләүәти үәт-тайибәт, әссәләмү гәләйкә әййүhән-нәбийү үә рахмәтүллаhи үә бәракәтүh, әссәләмү галәйнә үә галә гыйбәдилләhис-салихин, әшhәдү әллә иләhә иллАллаhү үә әшhәдү әннә Мүхәммәдән габдүhү үә расүлүh/

35 — «Тәхиятләр,[55] салаватлар hәм иң яхшы мактау сыйфат сүзләре Аллаhка гына. Әй пәйгамбәр! Сиңа Аллаhның сәламе, рәхмәте hәм бәракәте булсын! Безгә дә hәм Аллаhның башка изге-салих колларына да сәламнәр булсын! Хакыйкатьтә, Аллаhтан башка

55 Сәламнәр

иләһ юк дип шаһитлык кылам һәм хакыйкатьтә, Мөхәммәд Аның колы һәм расүле дип шаһитлык кылам!»[56]

23 – Тәшәһһүдтән соң салават догасы

٣٦ – «اللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ، كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ، اللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ، كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ»

36 – /Аллаһүммә салли галә Мүхәммәдин үә галә әли Мүхәммәд, кәмә салләйтә галә Ибраһимә үә галә әли Ибраһимә иннәкә хәмидүм-мәҗид. Аллаһүммә бәрик галә Мүхәммәдин үә галә әли Мүхәммәд, кәмә бәрактә галә Ибраһимә үә галә әли Ибраһимә иннәкә хәмидүм-мәҗид/

56 әл-Бохари 1202

36 — «Әй Аллаһ! Ибраһимга һәм анын әһле-бәйтенә салаватларын булган кебек, Мөхәммәдкә һәм анын әһле-бәйтенә дә салаватларын булсын, дөреслектә Син мактаулы вә данлыклы! Әй Аллаһ! Ибраһимга һәм анын әһле-бәйтенә бәрәкәтең булган кебек, Мөхәммәдкә һәм анын әһле-бәйтенә дә бәрәкәтең булсын, дөреслектә Син мактаулы вә данлыклы!»[57]

٣٧ – «اللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى أَزْوَاجِهِ وَذُرِّيَّتِهِ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ وَبَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى أَزْوَاجِهِ وَذُرِّيَّتِهِ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ»

37 – /Аллаһүммә салли галә Мухәммәдин үә галә әзүәҗиһи үә зүррийәтиһи, кәмә салләйтә галә әли Ибраһимә, үә бәрик галә Мухәммәдин үә галә әзүәҗиһи үә зүррийәтиһи, кәмә бәрактә галә әли

57 әл-Бохари 3370

Ибраһимә иннәкә хәмидүм-мәҗид/

37 — «Әй Аллаһ! Ибраһимның әһле-бәйтенә салаватларың булган кебек, Мөхәммәдкә һәм аның хатыннарына вә нәселенә дә салаватларың булсын! Ибраһимның әһле-бәйтенә бәракәтең булган кебек, Мөхәммәдкә һәм аның хатыннарына вә нәселенә дә бәракәтең булсын! Дөреслектә Син мактаулы вә данлыклы!»[58]

24 – Салаваттан соң, сәлам алдыннан әйтелә торган дога

٣٨ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابِ الْقَبْرِ، وَمِنْ عَذَابِ النَّارِ، وَمِنْ فِتْنَةِ الْمَحْيَا وَالْمَمَاتِ، وَمِنْ فِتْنَةِ الْمَسِيحِ الدَّجَّالِ»

38 – /Аллаһүммә инни әгүҙү бикә мин газәбил-кабри, үә мин газәбин-нәри, үә мин фитнәтил-мәхйә үәлмәмәти, үә мин фитнәтил-мәсихид-дәҗҗәл/

58 әл-Бохари 3369

38 — «Әй Аллаһ! Дөреслектә, мин Сиңа кабер газабыннан, җәһәннәм газабыннан, яшәү белән үлем фетнәсеннән һәм мәсих Дәҗҗәл фетнәсеннән сыенам!»[59]

٣٩ – «اللَّهُمَّ إِنِّى ظَلَمْتُ نَفْسِى ظُلْمًا كَثِيرًا وَلَا يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلاَّ أَنْتَ، فَاغْفِرْ لِى مَغْفِرَةً مِنْ عِنْدِكَ، وَارْحَمْنِى إِنَّكَ أَنْتَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ»

39 – /Аллаһүммә инни ҙаләмтү нәфси ҙулмән кәҫиран үә лә йәгьфируҙ-ҙүнүбә илләә әнт, фәгьфир ли мәгьфиратән мин гыйндик, үәрхәмни иннәкә әнтәл-гафүрур-рахим/

39 — «Әй Аллаһ! Дөреслектә, мин үземә бик күп золым кылдым, ә Синнән башка гөнаһларны беркем дә ярлыкамый! Мине Үзеңнең мәгьфиратең илә гафу ит һәм миңа рәхимле бул! Дөреслектә, Син гафу итүче вә рәхимле!»[60]

59 әл-Бохари 1377

60 әл-Бохари 834

٤٠ — «اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِى مَا قَدَّمْتُ وَمَا أَخَّرْتُ وَمَا أَسْرَرْتُ وَمَا أَعْلَنْتُ وَمَا أَسْرَفْتُ وَمَا أَنْتَ أَعْلَمُ بِهِ مِنِّى أَنْتَ الْمُقَدِّمُ وَأَنْتَ الْمُؤَخِّرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ»

40 – /Аллаhүммәгьфир ли мә каддәмтү үә мә әххартү үә мә әсрартү үә мә әгьләнтү үә мә әсрафтү үә мә әнтә әгьләмү биhи минни. Әнтәл-мукаддимү үә әнтәл-мү'әххирү лә иләhә иллә әнт/

40 — «Әй Аллаh! Минем әүвәлге һәм ахырдан, яшерен һәм ачыктан кылган, чиктән узып эшләгән һәм миннән Үзең яхшырак белгән гөнаhларымны гафу ит! Син (тәүфыйк биреп) алга чыгаручы һәм Син (тәүфыйктан мәхрүм итеп) ахырга калдыручы. Синнән башка иләh юк»[61]

٤١ — «اللَّهُمَّ أَعِنِّى عَلَى ذِكْرِكَ وَشُكْرِكَ وَحُسْنِ عِبَادَتِكَ»

61 Мөслим 771

41 – /Аллаһүммә әгыйнни галә зикрикә үә шүкрикә үә хүсни гыйбәдәтик/

41 — «Әй Аллаһ! Сине зикер кылуга, Сиңа шөкер итүгә һәм Сиңа иң яхшы рәвештә гыйбадәт кылырга миңа ярдәм ит!»[62]

٤٢ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْأَلُكَ الْجَنَّةَ وَأَعُوذُ بِكَ مِنَ النَّارِ»

42 – /Аллаһүммә инни әс'әлүкәл-җәннәтә үә әгүзү бикә минән-нәр/

42 — «Әй Аллаһ! Дөреслектә, мин Синнән Җәннәт эстим (сорыйм) һәм Җәһәннәм Утыннан сыенам»[63]

25 – Намаз ахырында сәламнән соң укыла торган догалар

٤٣ – «أَسْتَغْفِرُ اللَّهَ (ثلاثا) اللَّهُمَّ أَنْتَ السَّلاَمُ وَمِنْكَ السَّلاَمُ تَبَارَكْتَ ذَا الْجَلاَلِ وَالإِكْرَامِ»

62 Әбү Дауыд 1522
63 Әбү Дауыд 792

43 – /Әстәгъфируллаһ (өч тапкыр) ***Аллаһүммә әнтәс-сәләм, үә минкәс-сәләм, тәбәрактә ҙәл-җәләли үәл-икрам/***

43 — «Аллаһтан ярлыкау эстим! (өч тапкыр) Әй Аллаһ! Син – Сәлам һәм Синнән – сәлам, Син мөбәрак булдың, әй бөеклек вә хөрмәт Иясе!»[64]

٤٤ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ اللَّهُمَّ لاَ مَانِعَ لِمَا أَعْطَيْتَ وَلاَ مُعْطِيَ لِمَا مَنَعْتَ وَلاَ يَنْفَعُ ذَا الْجَدِّ مِنْكَ الْجَدُّ»

44 – /Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәху лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмдү үә һүә галә күлли шәй'ин кадир. Аллаһүммә лә мәнигә лимә әгьтайтә үә лә мугътыйә лимә мәнәгьтә үә лә йәнфәгү ҙәл-җәдди минкәл-җәдд/

44 — «Аллаһтан башка иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше

64 Мөслим 591

юк. Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау һәм Ул бар нәрсәгә кодрәтле. Әй Аллаһ! Син биргәнне тыючы юк, ә Син тыйганны бирүче юк һәм Синең каршыңда дөнья мәртәбә иясенә аның бернәрсәсе дә файда бирми»[65]

٤٥ – «سُبْحَانَ اللهِ، وَالحَمْدُ للهِ، واللهُ أكْبَرُ (ثلاثا وثلاثين) لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ»

45 – /СүбхәнАллаһ, үәл-хәмдү лилләһ, үәАллаһү әкбәр *(һәрберсен 33 тапкыр)* ***Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәһү лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмдү үә һүә галә күлли шәй‘ин кадир/***

45 — «Аллаһ барча кимчелектән пакь, Аллаһка барча мактау, Аллаһ һәрнәрсәдән бөек. Аллаһтан башка һич иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча

65 әл-Бохари 844

патшалык вә Аңа гына барча мактау һәм Ул бар нәрсәгә кодрәтле»[66]

46 — һәр намаздан соң Коръәннең ахыргы 3 сүрәсе укыла[67]

«قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ اللَّهُ الصَّمَدُ لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ وَلَمْ يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ»

– /Куль һүәАллаһү әхәд. Аллаһүс-самәд. Ләм йәлид үә ләм йүләд. үә ләм йәкүл-ләһү күфүән әхәд/

— «Әйт: Аллаһ – Бер. Аллаһ – Омтылылган Хуҗа, Мәңге. Ул тудырмады һәм тудырылмады һәм һичкем Аңа тиң булмады»

«قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ وَمِنْ شَرِّ غَاسِقٍ إِذَا وَقَبَ وَمِنْ شَرِّ النَّفَّاثَاتِ فِي الْعُقَدِ وَمِنْ شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ»

– /Куль әгүҙү бирабиль-фәләкъ.

66 Мөслим 597 (Кем дә кем бу сүзләрне һәрбер намаздан соң әйтсә, аның гөнаһлары диңгездәге күбек кадәр булса да, гафу ителер)
67 Әбү Дауыд 1523

Миң шәрримә халәкъ. Үә миң шәрри гаасикыйн иҙә үәкаб. Үә миң шәррин-нәффәәҫәти фил-гукад. Үә миң шәрри хәәсидин иҙә хәсәд/

— «Әйт: Мин таңның Раббысына сыенам; Ул халикъ кылган барча нәрсәнең явызлыгыннан, караңгылыгы белән каплаган төннең явызлыгыннан, сихер-ырым төеннәренә өрүче хатыннарның явызлыгыннан һәм хөседле кешеләрнең хөсед явызлыгыннан»

«قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ النَّاسِ مَلِكِ النَّاسِ إِلَهِ النَّاسِ مِنْ شَرِّ الْوَسْوَاسِ الْخَنَّاسِ الَّذِي يُوَسْوِسُ فِي صُدُورِ النَّاسِ مِنَ الْجِنَّةِ وَالنَّاسِ»

– /Куль әгүҙү бирабиннәс. Мәликиннәәс. Иләһиннәәс. Миң шәррил-үәсүәсил-ханнәәс. Әлләҙи йүәсүисү фи судүриннәәс. Минәл-җиннәти үәннәәс/

— «Әйт: Мин – кешеләрнең күңелләренә вәсвәсә салучы җеннәрдән һәм кешеләрдән булган, Аллаһны

зикер иткәндә юкка чыгучы шәйтанның вәсвәсәсеннән – кешеләрнең Раббысына, кешеләрнең Патшасына, кешеләрнең Иләһенә сыенам»

47 — һәр намаздан соң «аять әл-Көрси» укыла[68]

«اللَّهُ لَا إِلَهَ إِلَّا هُوَ الْحَيُّ الْقَيُّومُ لَا تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلَا نَوْمٌ لَهُ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ مَنْ ذَا الَّذِي يَشْفَعُ عِنْدَهُ إِلَّا بِإِذْنِهِ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ أَيْدِيهِمْ وَمَا خَلْفَهُمْ وَلَا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلَّا بِمَا شَاءَ وَسِعَ كُرْسِيُّهُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ وَلَا يَئُودُهُ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ»

– /Аллаһү лә иләһә иллә һүәл-хәййүл-каййүм, лә тә‘хуҙүһү синәтүүә лә нәүүм, ләһү мә фис-сәмәүәти үә мә фил-әръд, мәң-ҙәлләҙи йәшфәгү гыйңдәһү иллә би‘иҙниһ, йәгьләмү мә бәйнә әйдиһим үә мә халфәһүм, үә лә йүхитунә бишәй-

68 Сахих әл-Җәмигъ (Кем дә кем моны һәр намаздан соң укыса, аңа Җәннәткә керергә киртә булмас)

‘им-мин гыйлмиһи иллә бимә шәә‘, үәсига күрсийүһүс-сәмәүәти үәл-әръд, үә лә йә‘үдүһү хифҙуһүмә үә һүәл-галийүл-гаҙыйм/

— «Аллаһ – Аннан башка иләһ юк. Ул – мәңге Тере, Ул – яшәешне Барлап торучы. Ул беркайчан йокымсырап черем итмәс. Ул беркайчан йокыга китмәс. Күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә Аныкы. Кем Аның каршысында, Аның рөхсәтеннән башка шәфәгать кыла алыр икән? Ул һәрнәрсәнең үткәнен дә, киләчәген дә белә. Тик алар гына, Аның гыйлеменнән, Ул Үзе теләп аларга белгерткән нәрсәдән башканы белмиләр, чолгап ала алмыйлар. Аның көрсие күкләрне һәм җирне үз эченә ала. Аларны саклау Аның өчен бер дә авырлык китерми. Ул – барнәрсәдән дә Биек һәм Бөек»[69]

٤٨ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ

69 әл-Бәкара 255

الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ يُحْيِى وَيُمِيتُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَىْءٍ قَدِيرٌ»

48 – /Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәху лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмду йүхйи үә йүмитү үә һүә галә күлли шәй'ин кадир/ (иртәнге һәм ахшам намазларыннан соң 10 тапкыр әйтелә)

48 — «Аллаһтан башка иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау. Ул терелтә вә үлеләндерә һәм Ул бар нәрсәгә кодрәтле»[70]

٤٩ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْأَلُكَ عِلْمًا نَافِعًا وَرِزْقًا طَيِّبًا وَعَمَلاً مُتَقَبَّلاً»

49 – /Аллаһүммә инни әс'әлүкә гыйлмән нәфиган үә ризкан тайибән үә гамәлән мүтәкаббәлән/

49 — «Әй Аллаһ! Дөреслектә, мин Синнән файдалы гыйлем, яхшы

70 әт-Тирмизи 3474, 3534

ризык һәм кабул булган гамәлне сорыйм!»[71]

26 – Истихара (хәерлене сорау) намазының догасы

Җәбир бин Габдуллаһ радыяллаһү ганһүмә әйтте:

— «Аллаһның расүле безгә барча эшләребездә дә истихара кылуны (хәерлесен сорауны) Коръән сүрәсен өйрәткән кебек өйрәтә иде, һәм әйтә иде: ***«Әгәр дә берәрегез нинди дә булса эш эшләргә уйласа, фарыз намазыннан башка ике ракәгать нәфел намазы укып ошбу доганы әйтсен:***

٥٠ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْتَخِيرُكَ بِعِلْمِكَ وَأَسْتَقْدِرُكَ بِقُدْرَتِكَ، وَأَسْأَلُكَ مِنْ فَضْلِكَ الْعَظِيمِ، فَإِنَّكَ تَقْدِرُ وَلاَ أَقْدِرُ وَتَعْلَمُ وَلاَ أَعْلَمُ وَأَنْتَ عَلاَّمُ الْغُيُوبِ،

71 Ибен Мәҗәһ 925 (иртәнге намазның сәламеннән соң)

اللَّهُمَّ إِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الأَمْرَ خَيْرٌ لِي فِي دِينِي وَمَعَاشِي وَعَاقِبَةِ أَمْرِي - أَوْ قَالَ عَاجِلِ أَمْرِي وَآجِلِهِ - فَاقْدُرْهُ لِي وَيَسِّرْهُ لِي ثُمَّ بَارِكْ لِي فِيهِ، وَإِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الأَمْرَ شَرٌّ لِي فِي دِينِي وَمَعَاشِي وَعَاقِبَةِ أَمْرِي - أَوْ قَالَ فِي عَاجِلِ أَمْرِي وَآجِلِهِ - فَاصْرِفْهُ عَنِّي وَاصْرِفْنِي عَنْهُ، وَاقْدُرْ لِي الْخَيْرَ حَيْثُ كَانَ ثُمَّ أَرْضِنِي بِهِ»

50 – /Аллаhүммә инни әстәхирукә бигыйлмик, үә әстәкъдирукә бикудратик, үә әс‘әлүкә мин фадъликәл-гаҙыйм, фә‘иннәкә тәкъдирү үә лә әкъдир, үә тәгьләмү үә лә әгьләм, үә әнтә галләмүл-гуйүб. Аллаhүммә ин күнтә тәгьләмү әннә hәҙәл-әмра хайрун ли фи дини үә мәгаши үә гакыйбәти әмри фәкъдүрhү ли үә йәссирhү ли çүммә бәрик ли фиh, үә ин күнтә тәгьләм әннә hәҙәл-әмра шәррун ли фи дини үә мәгаши үә гакыйбәти әмри фәсрыйфhү ганни үәсрыйфни ганhү үәкъдүр лиәл-хайра хәйçү кәнә çүммә әрдыйни

биhи/

50 — «Әй *Аллаh*! Хакыйкатьтә, мин Синең гыйлемең белән Синнән хәерлесен сорыйм, Синең кодрәтең илә Синнән көч сорыйм, Синең бөек фазылыңнан сорыйм! Дөреслектә, Синең көчең җитә ә минем көчем җитми, Син беләсең ә мин белмим, һәм Син барча яшеренне белүчесең! Әй *Аллаh*! Әгәр Син бу эшнең (нәрсә икәнен әйтеп китә) миңа динемдә дә, тормышымда да һәм эшләремнең ахыргы нәтиҗәсендә дә[72] (бу һәм киләсе дөньяда) хәерле икәнлеген белсәң, аны миңа тәкъдир кыл, аны миңа җиңеләйт һәм миңа анда бәракәт бир. Әгәр Син бу эшнең миңа динемдә дә, тормышымда да һәм эшләремнең ахыргы нәтиҗәсендә дә (бу вә киләсе дөньяда) зыянлы вә яман икәнлеген белсәң, аны минән читләштер вә мине аннан читләштер һәм ул эш кайда гына булса да

72 Ягъни, Ахирәттә

миңа хәерлесен тәкъдир кыл, соңра мине аннан канәгать кыл»[73]

Аллаһка истихара кылып хәерлесен сораган һәм мөэминнәр белән киңәшләшеп эшендә ныклы булган кеше беркайчан да үкенмәс. Аллаһ тәгалә әйтте: **«Эшеңдә алар белән киңәшләш, ә инде аны эшләргә карар кылсаң, Аллаһка тәвәккәллә».** (әли-Гыймран 159)

27 – Иртә һәм кич укыла торган догалар

٥١ – «اللَّهُ لَا إِلَهَ إِلَّا هُوَ الْحَيُّ الْقَيُّومُ لَا تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلَا نَوْمٌ لَهُ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ مَنْ ذَا الَّذِي يَشْفَعُ عِنْدَهُ إِلَّا بِإِذْنِهِ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ أَيْدِيهِمْ وَمَا خَلْفَهُمْ وَلَا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلَّا بِمَا شَاءَ وَسِعَ كُرْسِيُّهُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ وَلَا يَئُودُهُ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ»

51 – /Аллаһү лә иләһә илләә һүәл-

73 әл-Бохари 1162

хәййүл-кайййүм, лә тә‘хузүһү синәтү-үә лә нәүүм, ләһү мә фис-сәмәүә-ти үә мә фил-әръд, мәң-зәлләҙи йәшфәгү гыйңдәһү иллә би‘иҙниһ, йәгьләмү мә бәйнә әйдиһим үә мә халфәһүм, үә лә йүхитунә бишәй-‘им-мин гыйлмиһи иллә бимә шәә‘, үәсига күрсиййүһүс-сәмәүәти үәл-әръд, үә лә йә‘үдүһү хифҙуһүмә үә һүәл-галиййүл-гаҙыйм/

51 — «Аллаһ – Аннан башка иләһ юк. Ул – мәңге Тере, Ул – яшәешне Барлап торучы. Ул беркайчан йокымсырап черем итмәс. Ул беркайчан йокыга китмәс. Күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә Аныкы. Кем Аның каршысында, Аның рөхсәтеннән башка шәфәгать кыла алыр икән? Ул һәрнәрсәнең үткәнен дә, киләчәген дә белә. Тик алар гына, Аның гыйлеменнән, Ул Үзе теләп аларга белгерткән нәрсәдән башканы белмиләр, чолгап ала алмыйлар. Аның көрсие күкләрне һәм җирне үз эченә

ала. Аларны саклау Аның өчен бер дә авырлык китерми. Ул – барнәрсәдән дә Биек һәм Бөек»[74]

52 — Иртән һәм кич 3 тапкыр ошбу сүрәләрне укучы барча начарлыклардан сакланыр: **әл-Ихлас** сүрәсе; **әл-Фәләкъ** сүрәсе һәм **ән-Нәс** сүрәсе[75]

٥٣ – «أَصْبَحْنَا وَأَصْبَحَ الْمُلْكُ لِلَّهِ (أَمْسَيْنَا
وَأَمْسَى الْمُلْكُ لِلَّهِ) وَالْحَمْدُ لِلَّهِ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ
وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى
كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ، رَبِّ أَسْأَلُكَ خَيْرَ مَا فِى هَذَا الْيَوْمِ
وَخَيْرَ مَا بَعْدَهُ وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ مَا فِى هَذَا الْيَوْمِ
وَشَرِّ مَا بَعْدَهُ (رَبِّ أَسْأَلُكَ خَيْرَ مَا فِى هَذِهِ اللَّيْلَةِ
وَخَيْرَ مَا بَعْدَهَا وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ مَا فِى هَذِهِ
اللَّيْلَةِ وَشَرِّ مَا بَعْدَهَا) رَبِّ أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْكَسَلِ

74 әл-Бәкара 255. Кем дә кем бу аятьне иртән укыса, кичкә кадәр шәйтаннан сакланыр, ә кем кич белән укыса - иртәнгә кадәр шәйтаннан сакланыр

75 Әбү Дауыд, әт-Тирмизи. Бу сүрәләр 44-45нче биттә килә

وَسُوءِ الْكِبَرِ رَبِّ أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابٍ فِى النَّارِ وَعَذَابٍ فِى الْقَبْرِ»

53 – /Әсъбәхнә үә әсъбәхәл-мүлкү лилләһи (әмсәйнә үә әмсәл-мүлкү лилләһи)[76] үәл-хәмдү лилләһи лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәхү лә шәрикә ләһү ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмдү үә һүә галә күлли шәй'ин кадир. Рабби әс'әлүкә хайра мә фи һәҙәл-йәүми үә хайра мә бәгьдәһү үә әгүҙү бикә мин шәрри мә фи һәҙәл-йәүми үә шәрри мә бәгьдәһү (Рабби әс'әлүкә хайра мә фи һәҙиһил-ләйләти үә хайра мә бәгьдәһә үә әгүҙү бикә мин шәрри мә фи һәҙиһил-ләйләти үә шәрри мә бәгьдәһә)[77] Рабби әгүҙү бикә минәл-кәсәли үә сү'ил-кибәри Рабби әгүҙү бикә мин гаҙәбин фин-нәри үә гаҙәбин фил-кабр/

76 Җәя эчендәгесе, кич беләән алдагы җөмлә урынына әйтелә
77 Җәя эчендәгесе, кич беләән алдагы җөмлә урынына әйтелә

53 — «Без вә Аллаһка буйсынучы барча мөлек иртәнгә иреште[78] (кичкә иреште)[79] һәм Аллаһка бар-ча мактау. Аллаһтан башка иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау һәм Ул бар нәрсәгә кодрәтле. Әй Раббым! Синнән бу көннең (бу төннең) хәерлесен вә аннан соң килгән хәерлелекне сорыйм, һәм бу көннең (бу төннең) яманлыгыннан вә аннан соң килгән яманлыктан Сиңа сыенам. Әй Раббым! Мин Сиңа ваемсызлыктан һәм яман картлыктан сыенам. Әй Раббым! Мин Сиңа ут газабыннан һәм кабер газабыннан сыенам!»[80]

٥٤ – «اللَّهُمَّ بِكَ أَصْبَحْنَا وَبِكَ أَمْسَيْنَا وَبِكَ

78 Гыйлем ияләре әйтүенчә, монда барча мөлек иртән Аллаһка сабит булган кебек, кич тә барча мөлекнең Аңа сабит булуы күздә тотыла
79 Җәя эчендәгесе кич белән укыла
80 Мөслим 2723

نَحْيَا وَبِكَ نَمُوتُ وَإِلَيْكَ الْمَصِيرُ»

54 – /Аллаһүммә бикә әсъбәхнә үә бикә әмсәйнә үә бикә нәхйә үә бикә нәмутү үә иләйкәл-мәсыйр/

54 — «Әй Аллаһ! Синең сәбәпле генә иртәнгә ирештек вә Синең сәбәпле генә кичкә ирештек, Синең сәбәпле генә яшибез вә Синең сәбәпле генә үләбез һәм Сиңа әйләнеп кайтуыбыз»

Кич белән болай әйтелә:

«اللَّهُمَّ بِكَ أَمْسَيْنَا وَبِكَ أَصْبَحْنَا وَبِكَ نَحْيَا وَبِكَ نَمُوتُ وَإِلَيْكَ النُّشُورُ»

– /Аллаһүммә бикә әмсәйнә үә бикә әсъбәхнә үә бикә нәхйә үә бикә нәмутү үә иләйкән-нүшүр/

— «Әй Аллаһ! Синең сәбәпле генә кичкә ирештек вә Синең сәбәпле генә иртәнгә ирештек, Синең сәбәпле генә яшибез вә Синең сәбәпле генә үләбез һәм Сиңа әйләнеп

кайтуыбыз»[81]

٥٥ – «اللَّهُمَّ أَنْتَ رَبِّى، لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ،
خَلَقْتَنِى وَأَنَا عَبْدُكَ، وَأَنَا عَلَى عَهْدِكَ وَوَعْدِكَ مَا
اسْتَطَعْتُ، أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ مَا صَنَعْتُ، أَبُوءُ لَكَ
بِنِعْمَتِكَ عَلَىَّ وَأَبُوءُ بِذَنْبِى، فَاغْفِرْ لِى، فَإِنَّهُ لاَ
يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلاَّ أَنْتَ»

55 – /Аллаһүммә әнтә рабби, лә иләһә иллә әнтә, халәкътәни үә әнә габдүкә, үә әнә галә гаһдикә үә үәгдикә мәстәтагтү, әгүҙү бикә мин шәрри мә санәгату, әбү'ү ләкә бинигьмәтикә галәййә үә әбү'ү биҙәнби, фәгьфирли, фә'иннәһү лә йәгьфируҙҙүнүбә иллә әнт/

55 — «Әй Аллаһ! Син минем Раббым. Синнән башка иләһ юк. Син мине халикъ кылдың, ә мин Синең колың һәм мин Синең гаһедеңә вә вәгъдәңә булдыра алганымча тугрылык саклаячакмын. Кылганнарымның явызлыгыннан Сиңа сыенам, Син миңа

81 эт-Тирмизи 3391

биргән нигъмәтеңне таныйм һәм үземнең гөнаһымны таныйм. Минем гөнаһларымны ярлыка, хакыйкатьтә, Синнән башка гөнаһларны ярлыкаучы юк»[82]

٥٦ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَصْبَحْتُ (أَمْسَيْتُ) أُشْهِدُكَ
وَأُشْهِدُ حَمَلَةَ عَرْشِكَ وَمَلاَئِكَتَكَ وَجَمِيعَ خَلْقِكَ
أَنَّكَ أَنْتَ اللَّهُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ وَحْدَكَ لاَ شَرِيكَ لَكَ
وَأَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُكَ وَرَسُولُكَ»

56 – /Аллаһүммә инни әсъбәхтү (әмсәйтү)[83] үшһидүк, үә үшһидү хәмәләтә гаршикә үә мәлә‘икәтәкә үә җәмига халькыйкь, әннәкә әнтә Аллаһү лә иләһә иллә әнтә үәхдәкә лә шәрикә ләк, үә әннә Мүхәммәдән габдүкә үә расүлүк/

82 әл-Бохари 6306. Кем бу сүзләргә инанып иртәнге якта әйтсә һәм кичкә кадәр үлеп китсә, ул Җәннәт әһеленнән була. Ә кем бу сүзләргә инанып кичке якта әйтсә һәм иртәнгә кадәр үлеп китсә, шулай ук Җәннәт әһеленнән була

83 Җәя эчендәгесе, кич белән алдагы сүз урынына әйтелә

56 — «Әй Аллаһ! Дөреслектә, бу иртәдә (кичтә): Син – Аллаһ, Синнән башка иләһ юк вә Син бер Үзең генә, Синең тиңдәшең юк һәм Мөхәммәд Синең колың вә расүлең дип — мин Сине, Синең гарешеңне хәмел[84] кылучыларны, фәрештәләреңне һәм барча Син халикъ кылган затларны шаһит кыламын»[85]

٥٧ – «اللَّهُمَّ مَا أَصْبَحَ (أَمْسَى) بِى مِنْ نِعْمَةٍ أَوْ بِأَحَدٍ مِنْ خَلْقِكَ فَمِنْكَ وَحْدَكَ لاَ شَرِيكَ لَكَ فَلَكَ الْحَمْدُ وَلَكَ الشُّكْرُ»

57 – /Аллаһүммә мә әсъбәхә (әмсә)[86] би мин нигъмәтин әү би әхәдин мин халькыйкә фәминкә үәхдәкә лә шәрикә ләк, фәләкәл-хәмду үә

84 Күтәреп баручылар

85 Әбү Дауыд 5078 (бу сүзләрне иртән әйтүченең шул көненең гөнаһлары кичерелә, ә кич беләп әйтүченең шул төненең гөнаһлары кичерелә) (шәйх Әлбәни зәгыйфь диде)

86 Җәя эчендәгесе, кич белән алдагы сүз урынына әйтелә

ләкәш-шукр/

57 — «Әй Аллаһ! Бу иртәдә (кичтә) миңа яки Синең берәр мәхлукатыңа күрсәтелгән нигъмәт – Бер Синнән генә. Синең тиңдәшең юк. Сиңа гына барча мактау вә шөкер»[87]

٥٨ – «اللَّهُمَّ عَافِنِى فِى بَدَنِى اللَّهُمَّ عَافِنِى فِى سَمْعِى اللَّهُمَّ عَافِنِى فِى بَصَرِى لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ. اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْكُفْرِ وَالْفَقْرِ اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابِ الْقَبْرِ لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ»

58 – /Аллаһүммә гафини фи бәдәни Аллаһүммә гафини фи сәмги Аллаһүммә гафини фи бәсари лә иләһә иллә әнт. Аллаһүммә инни әгүҙү бикә минәл-күфри үәл-фәкъри Аллаһүммә инни әгүҙү бикә мин гаҙәбил-кабри лә иләһә иллә әнт/ (3 тапкыр иртә һәм кич белән әйтелә)

87 Әбү Дауыд 5073 (бу сүзләрне иртән әйтүче - шул көненең шөкерен үтәгән була, ә кич белән әйтүче - шул төненең шөкерен үтәгән була (шәйх Әлбәни зәгыйфь диде).ән-Нәсәи «Гамәл әл-йәүм үә әл-ләйлә», ибен әс-Сүнни, ибен Хиббән

58 — «Әй Аллаһ! Минем тәнемне кимчелекләрдән сәламәт кыл! Әй Аллаһ! Минем ишетүемне кимчелекләрдән сәламәт кыл! Әй Аллаһ! Минем күрүемне кимчелекләрдән сәламәт кыл! Синнән башка иләһ юк! Әй Аллаһ! Дөреслектә, мин Сиңа көферлектән вә фәкыйрьлектән сыенам! Әй Аллаһ! Дөреслектә, мин Сиңа кабер газабыннан сыенам! Синнән башка иләһ юк!»[88]

٥٩ – «حَسْبِىَ اللَّهُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ هُوَ عَلَيْهِ تَوَكَّلْتُ وَهُوَ رَبُّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ»

59 – /ХәсбиАллаһү лә иләһә иллә һүә галәйһи тәүәккәлтү үә һүә Раббүл-гаршил-гаҙыйм/ (7 тапкыр иртә һәм кич)

59 — «Миңа Аллаһ җитә! Аннан башка иләһ юк, Аңа тәвәккәлләдем һәм Ул – бөек гарешнең Раббысы!»[89]

88 Әбү Дауыд 5090

89 Әбү Дауыд 5081 (Кем дә кем бу сүзләрне иртә һәм кич белән 7 тапкыр әйтсә, Аллаһ аны дөнья һәм

٦٠ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْأَلُكَ الْعَفْوَ وَالْعَافِيَةَ فِى الدُّنْيَا وَالآخِرَةِ اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْأَلُكَ الْعَفْوَ وَالْعَافِيَةَ فِى دِينِى وَدُنْيَاىَ وَأَهْلِى وَمَالِى اللَّهُمَّ اسْتُرْ عَوْرَاتِى وَآمِنْ رَوْعَاتِى اللَّهُمَّ احْفَظْنِى مِنْ بَيْنِ يَدَىَّ وَمِنْ خَلْفِى وَعَنْ يَمِينِى وَعَنْ شِمَالِى وَمِنْ فَوْقِى وَأَعُوذُ بِعَظَمَتِكَ أَنْ أُغْتَالَ مِنْ تَحْتِى»

60 – /Аллаһүммә инни әс'әлүкәл-гафүә үәл-гафийәтә фид-дүньйә үәл-әхыйра, Аллаһүммә инни әс'әлүкәл-гафүә үәл-гафиәтә фи дини үә дүньйәйә үә әһли үә мәли, Аллаһүммәстүр гаураати үә әәмин раүгаати, Аллаһүммәхфәҙни мин бәйни йәдәййә үә мин халфи үә ган йәмини үә ган шимәәли үә мин фәүкый үә әгүҙү бигаҙамәтикә ән үгътәлә мин тәхти/

60 — «Әй Аллаһ! Дөреслектә мин Синнән, дөньяда һәм ахирәттә

ахирәт мәшәкатьләреннән коткарыр) (шәйх Әлбәни маудуг диде. шәйх Шөгайб Әрънәүут иснәде сахих диде. шәйх Габдулгазиз әл-Худайр сахих-маукуф диде)

ярлыкауыңны вә кимчелекләрдән сәламәт кылуыңны сорыйм! Әй Аллаһ! Дөреслектә мин Синнән динемдә, дөньямда, гаиләмдә һәм мал-мөлкәтемдә ярлыкауыңны вә кимчелекләрдән сәламәт кылуыңны сорыйм! Әй Аллаһ! Минем гаурәтләремне капла һәм мине куркудан имин кыл! Әй Аллаһ! Мине алдан да, арттан да, уңнан да, сулдан да һәм өстән дә сакла, һәм мин Синең бөеклегеңә хыянәтчел рәвештә астан үтерелүдән сыенам!»[90]

٦١ – «اللَّهُمَّ عَالِمَ الْغَيْبِ وَالشَّهَادَةِ فَاطِرَ السَّمَوَاتِ وَالأَرْضِ لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ رَبَّ كُلِّ شَيْءٍ وَمَلِيكَهُ أَشْهَدُ أَنْ لا إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ نَفْسِي وَمِنْ شَرِّ الشَّيْطَانِ وَشِرْكِهِ (وَشَرَكِهِ) وَأَنْ أَقْتَرِفَ عَلَى نَفْسِي سُوءًا أَوْ أَجُرَّهُ إِلَى مُسْلِمٍ»

61 – /Аллаһуммә галимәл-гайби уәш-шәһәдәти, фәтыйрас-

90 Әбү Дауыд 5074, ибен Мәҗәһ 3871

сәмәүәти үәл-әръдый, раббә күлли шәй'ин үә мәликәһү, әшһәду әллә иләһә иллә әнтә, әгүҙү бикә мин шәрри нәфси, үә мин шәрриш-шәйтани үә ширкиһи (үә шәракиһи), үәән әкътәрифә галә нәфси сү'ән әү әҗүррраһү илә мүслим/

61 — «Әй Аллаһ! Син яшеренне вә ачыкны Белүче, күкләрне вә җирне Халикъ кылучы, барча нәрсәнең Раббысы вә Патшасы, Синнән башка иләһ юк дип шәһидлек кылам. Мин үземнең нәфсемнең яманлыгыннан, шәйтанның явызлыгыннан вә аның ширеккә чакыруыннан (ятьмәсеннән), һәм үземә яманлык кылудан яки аны берәр мөселманга ылыктырудан Сиңа сыенам»[91]

٦٢ – «بِسْمِ اللَّهِ الَّذِى لاَ يَضُرُّ مَعَ اسْمِهِ شَىْءٌ فِى الأَرْضِ وَلاَ فِى السَّمَاءِ وَهُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ»

62 – /Бисмилләһилләҙи лә йәдурру мәгәсмиһи шәй'үн фил-әръдый

91 эт-Тирмизи 3529

үә лә фис-сәмә', үә һүәс-сәмигуль-галим/ (3 тапкыр әйтелә)

62 — «Аллаһ исеме белән. Аның исеме белән җирдә дә һәм күктә дә һичнәрсә зыян китерә алмый, һәм Ул — Ишетүче, Белүче»[92]

٦٣ – «رَضِيتُ بِاللَّهِ رَبًا وَبِالإِسْلاَمِ دِينًا وَبِمُحَمَّدٍ نَبِيًّا»

✓ ***63 – /Радыйтү билләһи раббән, үә бил-исләми динән, үә би Мүхәммәдин нәбийән/*** (3 тапкыр иртән һәм кич)

63 — «Мин Аллаһтан – Раббы буларак, Исламнан – дин буларак һәм Мөхәммәдтән – пәйгамбәр буларак разыймын»[93]

92 Әбү Дауыд 5088. Кем бу сүзләрне иртән һәм кичтән өчәр тапкыр әйтсә, аңа һичнәрсә дә зыян итә алмый

93 «Мүснәд» Әхмәд (кем дә кем бу сүзләрне иртән һәм кич 3 тапкыр әйтсә, Аллаһ тәгалә ул кешене Кыямәт Көнендә разый кылыр) (шәйх Шөгайб Әрънәут сахих лигайриһи диде)

٦٤ – «يَا حَيُّ يَا قَيُّومُ بِرَحْمَتِكَ أَسْتَغِيثُ أَصْلِحْ لِي شَأْنِي كُلَّهُ وَلا تَكِلْنِي إِلَى نَفْسِي طَرْفَةَ عَيْنٍ»

64 – /Йә Хәййу, йә Каййуму, бирахмәтикә әстәгыйсу әсълих ли шә'ни күлләһү үә лә тәкилни илә нәфси тарфәтә гайн/

64 — «Әй Тере! Әй барча тереклекне, яшәешне Барлап торучы! Синең рәхмәтең илә ярдәм эстим! Минем барча эшләремне төзек кыл һәм мине үз-үземә күз йомган мизгелгә генә дә калдырма»[94]

٦٥ – «أَصْبَحْنَا وَأَصْبَحَ الْمُلْكُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ اللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ خَيْرَ هَذَا الْيَوْمِ: فَتْحَهُ وَنَصْرَهُ وَنُورَهُ وَبَرَكَتَهُ وَهُدَاهُ وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ مَا فِيهِ وَشَرِّ مَا بَعْدَهُ»

65 – /Әсъбәхнә үә әсъбәхәлмүлкү лилләһи (әмсәйнә үә әмсәл-

94 эн-Нәсәи «Гамәл әл-йәүм үә әл-ләйлә», әл-Хәким, әл-Бәйһәкый «әл-әсмә үә әс-сыйфәт», «сахих әт-тәргиб үә әт-тәрһиб» 661

мүлкү лилләһи)[95] раббил-галәмин, Аллаһүммә инни әс'әлукә хайра һәҙәл-йәүми: фәтхәһү үә нәсраһү үә нүраһү үә бәракәтәһү үә һүдәһү үә әгүҙү бикә мин шәрри мә фиһи үә шәрри мә бәгьдәһү (Аллаһүммә инни әс'әлукә хайра һәҙиһил-ләйләти: фәтхәһә үә нәсраһә үә нүраһә үә бәракәтәһә үә һүдәһә үә әгүҙү бикә мин шәрри мә фиһә үә шәрри мә бәгьдәһә)[96]/

65 — «Без һәм галәмнәр Раббысы Аллаһка буйсынучы барча мөлек иртәнгә иреште[97] (кичкә иреште)[98]. Әй Аллаһ! Дөреслектә, мин Синнән бу көннең (төннең) хәерлесен сорыйм: ярдәм, җиңү, нур, бәракәт һәм

95 Җәя эчендәгесе кич белән алдагы җөмлә урынына әйтелә

96 Җәя эчендәгесе кич белән алдагы җөмлә урынына әйтелә

97 Гыйлем ияләре әйтүенчә, монда барча мөлек иртән галәмнәр Раббысы Аллаһка сабит булган кебек, кич тә барча мөлекнең Аңа сабит булуы күздә тотыла

98 Җәя эчендәгесе кич белән укыла

һидәят бир. Һәм бу көннең (төннең) явызлыгыннан вә аннан соң булган явызлыктан Сиңа сыенам»[99]

٦٦ ــ «أَصْبَحْنَا عَلَى فِطْرَةِ الإِسْلاَمِ وَعَلَي كَلِمَةِ الإِخْلاَصِ وَعَلَى دِينِ نَبِيِّنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَى مِلَّةِ أَبِينَا إِبْرَاهِيمَ حَنِيفاً مُسْلِماً وَمَا كَانَ مِنَ الْمُشْرِكِينَ»

66 – /Әсъбәхнә (әмсәйнә)[100] галә фитратиль-исләм үә галә кәлимәтиль-ихъләсъ үә галә дини нәбийинә Мүхәммәдин үә галә милләти әбийнә Ибраһимә хәнифән мүслимән үә мә кәнә минәл-мүшрикин/

66 — «Без – Ислам булган фитрый хәләтебездә, ихлас кәлимәсендә[101], Мөхәммәд ﷺ пәйгамбәребезнең диненә һәм мөшрикләрдән булмаган ә бәлки хәниф, мөселман булган атабыз Ибраһимның милләтендә

99 Әбү Дауыд 5084 (шәйх Әлбәни зәгыйфь диде)

100 Җәя эчендәгесе кич белән алдагы җөмлә урыны на әйтелә

101 Шәһәдәт кәлимәсе

иртәнгә (кичкә) ирештек»[102]

٦٧ – «سُبْحَانَ اللّٰهِ وَبِحَمْدِهِ»

67 – /СүбхәнАллаһи үә бихәмдиһ/ (100 тапкыр иртән һәм кич)

67 — «Аллаһ һәр кимчелектән пакь һәм Аңа барча мактау»[103]

٦٨ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللّٰهُ، وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ، وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ»

68 – /Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәһү лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмдү үә һүә галә күлли шәй'ин кадир/ (10 тапкыр әйтелә)

68 — «Аллаһтан башка иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау һәм Ул бар

102 «Мүснәд» Әхмәд

103 Мөслим 2692. Кем дә кем бу сүзләрне ир-тән һәм кичен йөзәр тапкыр әйтә икән, Кыямәт Көнендә ул кешедән дә яхшырак нәрсә белән килү-че булмас, иллә-мәгәр шулай ук әйтүче яки аннан да арттырып әйтүче генә

нәрсәгә кодрәтле»[104]

٦٩ ـ «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ، وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ، وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ»

69 – /Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәһү лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмдү үә һүә галә күлли шәй-‘ин кадир/ (иртән 100 тапкыр әйтелә)

69 — «Аллаһтан башка иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау һәм Ул бар нәрсәгә кодрәтле»[105]

٧٠ ـ «سُبْحَانَ اللَّهِ وَبِحَمْدِهِ عَدَدَ خَلْقِهِ وَرِضَا نَفْسِهِ وَزِنَةَ عَرْشِهِ وَمِدَادَ كَلِمَاتِهِ»

104 эн-Нәсәи «Гамәл әл-йәүм үә әл-ләйлә»

105 әл-Бохари 3293. Кем бу сүзләрне көненә йөз тапкыр әйтсә, ул 10 кол азат иткәнгә тиң була, янә аңа 100 изгелек языла һәм 100 явызлыгы җуела, янә бу сүзләр аңа көне буена кичкә кадәр шәйтаннан саклану чарасы була, һәм беркем дә моннан яхшыракны эшли алмый, иллә-мәгәр аннан арттырып кына әйтсә

70 – /СүбхәнАллаһи үә бихәмдиһи гадәдә халкыйһи үә рида нәфсиһи үә зинәтә гаршиһи үә мидәдә кәлимәтиһи/ (3 тапкыр иртән әйтелә)

70 — «Аллаһ һәр кимчелектән пакь һәм Аңа барча мактау – Аның мәхлукатлары саны кадәр, Үзенә күпме кирәк – шул кадәр, Аның гареше авырлыгы кадәр һәм Аның сүзләрен язырга кирәк булган кара кадәр»[106]

٧١ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْأَلُكَ عِلْمًا نَافِعًا وَرِزْقًا طَيِّبًا وَعَمَلاً مُتَقَبَّلاً»

71 – /Аллаһүммә инни әс'әлукә гыйлмән нәфиган үә ризкан тайибән үә гамәлән мүтәкаббәлән/ (көндә иртән)

71 — «Әй Аллаһ! Дөреслектә, мин Синнән файдалы гыйлем, хәләл ризык һәм кабул булган гамәлне

106 Мөслим 2726

сорыйм»[107]

٧٢ – «أَسْتَغْفِرُ اللهَ وأَتُوبُ إِلَيْهِ»

72 – /Әстәгъфируллаһ, үә әтүбү иләйһ/ (көндә 100 тапкыр әйтелә)

72 — «Аллаһтан ярлыкау сорыйм һәм Аңа тәүбә итәм»[108]

٧٣ – «أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ
التَّامَّاتِ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ»

73 – /Әгүҙү би кәлимәтил-ләһит-тәммәти мин шәрри мә халәкъ/ (кич белән 3 тапкыр әйтелә)

73 — «Аллаһ ﷻ халикъ кылган нәрсәләрнең явызлыгыннан, Аның

107 Ибен Мәҗәһ 925
108 әл-Бохари «әл-Фәтх» белән һәм Мөслим

камил сүзләренә[109] сыенам»[110]

«اللَّهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَى نَبِيِّنَا مُحَمَّدٍ» – ٧٤

√***74 – /Аллаһүммә салли үә сәллим галә нәбийинә Мүхәммәд/*** (көндә иртән һәм кич белән 10 тапкыр әйтелә)

74 — «Әй Аллаһ! Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә салават вә сәлам кыл»[111]

109 Кәүния һәм шәрьгыя сүзләр керә. Кәүния, мәсәлән Аллаһ бер нәрсәнең булуын теләсә, Ул аңа бул ди һәм була. Шәрьгыя, мәсәлән ул бәла-каза төшкәнче һәм төшкәннән соң мөмкин, аятел көрсине кич белән укыган кеше төне буе шәйтаннан саклана - бу, бәла төшкәнче Аллаһның аяте белән саклану, чирләгән кеше фәтихә сүрәсе белән дәвалана - бу, бәла төшкәннән соң Аның сүзе белән саклану

110 Сахих әл-Җәмигь әс-Сәгыйрь 6427. Кем бу сүзләрне кич белән 3 тапкыр әйтсә, ул төндә аңа бер хәшәрәтнең дә агуы зыян итмәс

111 Сахих әл-Җәмигь әс-Сәгыйрь 6357. Кем бу сүзләрне иртән һәм кич унышар тапкыр әйтсә, аңа Кыямәт көнендә пәйгамбәребезнең шәфәгате булыр

28 – Йоклар алдыннан укыла торган зикерләр вә догалар

75 — Йокларга ятыр алдыннан кулларны бер учка җыеп аларга бераз төкереп өрергә һәм түбәндәге сүрәләрне[112] укырга:

— әл-Ихлас —

— әл-Фәләкъ —

— ән-Нәс —

Шуннан соң, баштан, йөздән һәм тәннең алгы ягыннан башлап ике уч белән бөтен тәнне сыпырырга. Шушы тәртип буенча башта кулны учлап өреп, аннары сүрәләрне укып бөтен тәнне сыпыруны 3 тапкыр эшләргә[113]

٧٦ – «اللَّهُ لَا إِلَهَ إِلَّا هُوَ الْحَيُّ الْقَيُّومُ لَا تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلَا نَوْمٌ لَهُ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ مَنْ ذَا الَّذِي يَشْفَعُ عِنْدَهُ إِلَّا بِإِذْنِهِ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ

112 Бу сүрәләр 44-45нче биттә килә

113 әл-Бохари 5017

أَيْدِيهِمْ وَمَا خَلْفَهُمْ وَلَا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ
إِلَّا بِمَا شَاءَ وَسِعَ كُرْسِيُّهُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ وَلَا
يَئُودُهُ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ»

76 – /Аллаhү лә иләhә илла hүәл-хәййүл-каййүм, лә тә'хуҙүhү синәтүүә лә нәүүм, ләhү мә фис-сәмәүәти үә мә фил-әръд, мәң-ҙәлләҙи йәшфәгү гыйңдәhү иллә би'иҙниh, йәгьләмү мә бәйнә әйдиhим үә мә халфәhүм, үә лә йүхитунә бишәй-'им-мин гыйлмиhи иллә бимә шәә', үәсига күрсиййүhүс-сәмәүәти үәл-әръд, үә лә йә'үдүhү хифҙуhүмә үә hүәл-галиййүл-гаҙыйм/

76 — «Аллаh – Аннан башка иләh юк. Ул – мәңге Тере, Ул – яшәешне Барлап торучы. Ул беркайчан йокымсырап черем итмәс. Ул беркайчан йокыга китмәс. Күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә Аныкы. Кем Аның каршысында, Аның рөхсәтеннән башка шәфәгать кыла алыр икән? Ул һәрнәрсәнең үткәнен дә, киләчәген

дә белә. Тик алар гына, Аның гыйлеменнән, Ул Үзе теләп аларга белгерткән нәрсәдән башканы белмиләр, чолгап ала алмыйлар. Аның көрсие күкләрне һәм җирне үз эченә ала. Аларны саклау Аның өчен бер дә авырлык китерми. Ул – барнәрсәдән дә Биек һәм Бөек»[114]

٧٧ – «آمَنَ الرَّسُولُ بِمَا أُنْزِلَ إِلَيْهِ مِنْ رَبِّهِ وَالْمُؤْمِنُونَ كُلٌّ آمَنَ بِاللَّهِ وَمَلَائِكَتِهِ وَكُتُبِهِ وَرُسُلِهِ لَا نُفَرِّقُ بَيْنَ أَحَدٍ مِنْ رُسُلِهِ وَقَالُوا سَمِعْنَا وَأَطَعْنَا غُفْرَانَكَ رَبَّنَا وَإِلَيْكَ الْمَصِيرُ ۞ لَا يُكَلِّفُ اللَّهُ نَفْسًا إِلَّا وُسْعَهَا لَهَا مَا كَسَبَتْ وَعَلَيْهَا مَا اكْتَسَبَتْ رَبَّنَا لَا تُؤَاخِذْنَا إِنْ نَسِينَا أَوْ أَخْطَأْنَا رَبَّنَا وَلَا تَحْمِلْ عَلَيْنَا إِصْرًا كَمَا حَمَلْتَهُ عَلَى الَّذِينَ مِنْ قَبْلِنَا رَبَّنَا وَلَا تُحَمِّلْنَا مَا لَا طَاقَةَ لَنَا بِهِ وَاعْفُ عَنَّا وَاغْفِرْ لَنَا وَارْحَمْنَا أَنْتَ مَوْلَانَا فَانْصُرْنَا عَلَى الْقَوْمِ الْكَافِرِينَ»

114 әл-Бохари 2311 (Кем дә кем йоклар алдыннан «Аятел Көрси»не укый икән, Аллаһ аны иртәнгә кадәр барча явызлыктан саклый һәм аңа шәйтан якынлаша алмый)

77 — «Әл-Бәкара» сүрәсенең 285-286нчы аятьләре:[115]

— «Аллаһның расүле һәм мөэминнәр, Раббысыннан иңдерелгән нәрсәләргә иман китерде. Алар барысы да Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Китапларына һәм илчеләренә иман китерделәр. Алар: «Без илчеләрнең берсен дә аермыйбыз», — диделәр. Алар: «Без Синең әйткәнеңне ишеттек һәм буйсындык. Әй Раббыбыз! Безне ярлыкавыңны сорыйбыз. Ахыр чиктә, Сиңа кайту урыныбыз», — дип әйттеләр. Аллаһ беркемгә дә булдыра алмаслык эш йөкләми. Аның эшләп алган әҗерләре үзе өчен була. Эшләп җыйган гөнаһларны күтәрү аның үзенә генә кала. Әй Раббыбыз! Онытсан яисә хаталанган булсак, безне җәзага тартма. Әй Раббыбыз! Безгә кадәр булганнар-

115 әл-Бохари «әл-Фәтх» белән һәм Мөслим (кем бу ике аятьне төнлә укыса, ярдәм йөзеннән шул аңа җитәр)

га йөкләгән авыр йөкне безнең өстебезгә йөкләмә. Әй Раббыбыз! Көчебездән килмәгән нәрсәне, өстебезгә төшереп күтәртмә. Кичер безне, ярлыкагыл һәм Үз рәхмәтеңдә кыл. Син бит безнең Хуҗабыз. Син безгә кәферләр кавемен җиңәргә ярдәм ит!»

٧٨ – «بِاسْمِكَ رَبِّى وَضَعْتُ جَنْبِي وَبِكَ أَرْفَعُهُ إِنْ أَمْسَكْتَ نَفْسِى فَارْحَمْهَا وَإِنْ أَرْسَلْتَهَا فَاحْفَظْهَا بِمَا تَحْفَظُ بِهِ عِبَادَكَ الصَّالِحِينَ»

78 – /Бисмикә Рабби үәдагтү җәнби үә бикә әръфәгүһү ин әмсәктә нәфси фәръхәмһә үә ин әръсәлтәһә фәхфәзһә бимә тәхфәзу биһи гыйбәдәкәс-салихин/

78 — «Раббым, Синең исемең белән ян-ягыма яттым һәм Синең исемең белән мин торам. Әгәр Син җанымны алсаң – аңа рәхимле бул, әгәр җибәрсәң – аны изге кол-

ларыңны саклаган кебек сакла!»[116]

٧٩ – «اللَّهُمَّ قِنِى عَذَابَكَ يَوْمَ تَبْعَثُ عِبَادَكَ»

79 – /Аллаһүммә кыйни газәбәкә йәүмә тәбгәсү гыйбәдәк/ (3 тапкыр)

79 — «Әй Аллаһ! Колларыңны терелткән Көндә (Кыямәт Көнендә), мине Үзеңнең газабыңнан сакла»[117]

٨٠ – «بِاسْمِكَ اللَّهُمَّ أَمُوتُ وَأَحْيَا»

80 – /Бисмикә Аллаһүммә әмүтү үә әхйә/

80 — «Әй Аллаһ! Синең исемең белән үләм һәм тереләм»[118]

٨١ – «سبحان الله (ثلاثا وثلاثين) والحمد لله

116 әл-Бохари 6320 (ятактан торганнан соң яңадан анда ятырга теләсә изарының (киеменең) эчке ягы белән 3 тапкыр сыпырсын, чөнки ул аның артында нәрсә булуын белми, шуннан соң ошбу доганы укысын)

117 Әбү Дауыд 5045 (пәйгамбәребез ﷺ йоклар алдыннан уң якка яткач, уң кулын баш астына куеп ошбу доганы 3 тапкыр әйтә иде)

118 әл-Бохари 6324

(ثلاثا وثلاثين) والله أكبر (أربعا وثلاثين)»

81 – /СүбхәнАллаһ (33 тапкыр) ***Әлхәмдүлилләһ*** (33 тапкыр) ***Аллаһү әкбәр*** (34 тапкыр)/

81 — «Аллаһ һәр кичелектән пакь! Барча мактау Аллаһка гына! Аллаһ Бөек!»[119]

٨٢ – «يَقْرَأُ ﴿الم﴾ تَنْزِيلَ السَّجْدَةِ وَتَبَارَكَ الَّذِي بِيَدِهِ الْمُلْكُ»

82 — «әс-Сәждә» һәм «әл-Мүлк» сүрәләрен укый[120]

٨٣ – «اللَّهُمَّ أَسْلَمتُ نَفْسي إِلَيْكَ، وَوَجَّهتُ وَجْهِي إِلَيْكَ، وَفَوَّضتُ أَمْرِي إِلَيْكَ، وَأَلجأتُ ظَهري إِلَيْكَ رَغبَةً وَرَهبَةً إِلَيْكَ، لا مَلْجَأ وَلاَ مَنْجَا مِنْكَ إلاَّ إِلَيْكَ، آمنْتُ بِكِتَابِكَ الَّذِي أَنْزَلْتَ؛ وَنَبِيِّكَ الَّذِي أَرْسَلْتَ»

83 – /Аллаһүммә әсләмтү нәфси

119 әл-Бохари 3705 (кем дә кем йокларга ятыр алдыннан ошбу сүзләрне әйтсә, алар аның өчен хезмәтче яллаудан да хәерлерәк булыр)
120 әт-Тирмизи, ән-Нәсәи

иләйк, үә үәҗҗәһтү үәҗһи иләйк, үә фәүүәдьтү әмри иләйк, үә әлҗә‘тү ҙаһри иләйк, рагъбәтән үә раһбәтән иләйк, лә мәлҗә‘ә үә лә мәнҗә минкә иллә иләйк, әмәнтү би китәбикәлләҙи әнзәлтә үә би нәбийикәлләҙи әръсәлтә/

83 — «Әй Аллаһ! Мин нәфсемне Сиңа буйсындырдым, йөземне Сиңа юнәлдердем һәм эшләремне-хәлемне Сиңа тапшырдым. Синнән әҗер өмет итеп һәм газабыңнан куркып Сиңа сыендым. Синнән качу һәм котылу юк, иллә-мәгәр Сиңа гына! Мин Синең иңдергән Китабыңа һәм Син җибәргән пәйгамбәреңә иман китердем»[121]

121 әл-Бохари 7488, Мөслим 2710. Бу дога хакында пәйгамбәребез әйтте: «Хакыйкатьтә, әгәр дә син бу төнеңдә үлсәң, фитрый халәтеңдә (Аллаһка иманлы булып) үләрсең. Ә инде иртән тере булып торсаң, хәерлелекне (әҗер-савап) табырсың»

29 – Төнлә йоклый алмыйча боргаланып ятканда укыла торган дога

٨٤ ـ «لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ الْوَاحِدِ الْقَهَّارُ رَبُّ السَّمَوَاتِ
وَ الأَرْضِ وَ مَا بَيْنَهُمَا الْعَزِيزُ الْغَفَّارُ»

84 – /Лә иләһә илләАллаһүл-үәхидил-каһһәр, раббүс-сәмәүәти үәл-әръдый үә мә бәйнәһүмәл-газизүл-гаффәр/

84 — «Бердән Бер, барча нәрсәне Буйсындыручы Аллаһтан башка иләһ юк. Ул – әл-Газиз әл-Гаффәр, күкләрнең вә җирнең һәм алар арасындагы барча нәрсәнең Раббысы»[122]

122 Сахих әл-Җәмигь әс-Сәгыйрь 4693

30 – Төшендә куркучы һәм борчылучы укый торган дога

٨٥ – «أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّامَّاتِ مِنْ غَضَبِهِ وَعِقَابِهِ وَشَرِّ عِبَادِهِ وَمِنْ هَمَزَاتِ الشَّيَاطِينِ وَأَنْ يَحْضُرُونِ»

85 – /Әгүзү би кәлимәтил-ләһит-тәммәти мин гадабиһи үә гыйкабиһи үә шәрри гыйбәдиһи үә мин һәмәзәтиш-шәйәтыйни үә ән йәхдурун/

85 — «Аллаһның камил сүзләренә[123] Аның ачуыннан, җәзасыннан, колларының явызлыгыннан, шәй-

123 Кәүния һәм шәрыгыя сүзләр керә. Кәүния, мәсәлән Аллаһ бер нәрсәнең булуын теләсә, Ул аңа бул ди һәм була. Шәрыгыя, мәсәлән ул бәла-каза төшкәнче һәм төшкәннән соң мөмкин; аятел көрсине кич белән укыган кеше төне буе шәйтаннан саклана - бу бәла төшкәнче Аллаһның аяте белән саклану, чирләгән кеше «әл-Фәтихә» сүрәсе белән дәвалана - бу бәла төшкәннән соң Аның сүзе белән саклану

таннарның вәсвәсәләреннән һәм аларның минем яныма килүләреннән сыенам»[124]

31 – Начар төш күргәндә нәрсә эшләргә

86 —

а) Сул якка 3 тапкыр төкерергә.

б) Аллаһ тәгаләгә шәйтаннан һәм күргән төшнең яманлыгыннан сыеныргa (3 тапкыр)

в) Беркемгә дә сөйләмәскә.

г) Яткан ягын алыштырырга (сул якта яткан булса – уңга, һәм киресенчә)

87 — Теләсә торып намаз укырга.

32 – Витр намазындагы кунүт догасы

٨٨ – «اللَّهُمَّ اهْدِنِى فِيمَنْ هَدَيْتَ وَعَافِنِى فِيمَنْ

124 Әбү Дауыд 3893

عَافَيْتَ وَتَوَلَّنِى فِيمَنْ تَوَلَّيْتَ وَبَارِكْ لِى فِيمَا أَعْطَيْتَ وَقِنِى شَرَّ مَا قَضَيْتَ إِنَّكَ تَقْضِي وَلَا يُقْضَى عَلَيْكَ وَإِنَّهُ لَا يَذِلُّ مَنْ وَالَيْتَ وَلَا يَعِزُّ مَنْ عَادَيْتَ تَبَارَكْتَ رَبَّنَا وَتَعَالَيْتَ»

88 – /Аллаһүммәһдини фимән һәдәйт, үә гафини фимән гафәйт, үә тәүәлләни фимән тәүәлләйт, үә бәрик ли фимә әгьтайт, үә кыйни шәрра мә кадайт, иннәкә тәкъдый үә лә йүкъда галәйк, үә иннәһү лә йәҙиллү мән үәләйт, үә лә йәгиззү мән гадәйт, тәбәрактә раббәнә үә тәгаләйт/

88 — «Әй Аллаһ! Һидәятле кылган бәндәләрең кебек мине дә һидәятле кыл, барча яманлыктан сәламәт-имин кылган бәндәләрең кебек мине дә сәламәт-имин кыл, Үзең яклаган бәндәләрең кебек мине дә якла, миңа биргән нәрсәләрне бәракәтле кыл, Үзең тәкъдир-када кылган яманлыктан мине сакла, дөреслектә Син тәкъдир-када кыласың (хәл

итәсең), ә Сиңа карата бернәрсә дә хәл ителми. Хакыйкатьтә, Син яклаган кемсә – түбәнсетелми, ә Син дошман иткәне – һич гыйззәткә ирешмәс. Әй Раббыбыз! Син Мөбәрак вә Бөек булдың!»[125]

٨٩ – «اللَّهُمَّ إِيَّاكَ نَعْبُدُ، وَلَكَ نُصَلِّي وَنَسْجُدُ، وَإِلَيْكَ نَسْعَى وَنَحْفِدُ، نَرْجُو رَحْمَتَكَ وَنَخْشَى عَذَابَكَ، إِنَّ عَذَابَكَ بِالْكَافِرِينَ مُلْحَقٌ اللَّهُمَّ إِنَّا نَسْتَعِينُكَ وَنَسْتَغْفِرُكَ، وَنُثْنِي عَلَيْكَ الْخَيْرَ وَلَا نَكْفُرُكَ، وَنُؤْمِنُ بِكَ وَنَخْضَعُ لَكَ، وَنَخْلَعُ مَنْ يَكْفُرُكَ»

89 – /Аллаһүммә ийәкә нәгьбүдү үә ләкә нүсалли үә нәсҗүдү үә иләйкә нәсга үә нәхфидү нәрҗү рахмәтәкә үә нәхъшә газәбәкә иннә газәбәкә бил-кәфиринә мүлхәкъ. Аллаһүммә иннә нәстәгыйнүкә үә нәстәгьфирукә үә нүсни галәйкәл-хайра үә лә нәкфурукь, үә нү'минү бикә үә нәхъдагу ләкә үә нәхъләгу

125 Әбү Дауыд 1425

мән йәкфүрукь/

89 — «Әй Аллаһ! Сиңа гына гыйбадәт кылабыз, Сиңа гына намаз вә сәҗдә кылабыз. Сиңа таба омтылабыз вә ашыгабыз, Синең рәхмәтеңне сорыйбыз вә газабыңнан куркабыз, хакыйкатьтә, Синең газабыңа кәферләр дучар булачак. Әй Аллаһ! Дөреслектә, без Синең ярдәмеңне сорыйбыз, Синнән ярлыкау эстибез, нигъмәтең өчен Сине мактыйбыз, Сиңа көферлек кылмыйбыз, Сиңа иман китерәбез, Сиңа буйсынабыз һәм Сиңа көферлек кылучылардан баш тартабыз вә ваз кичәбез»[126]

33 – Витр намазында сәламнән соң укыла торган зикер

٩٠ – «سُبْحَانَ الْمَلِكِ الْقُدُّوسِ (ثلاث مرات

126 әл-Бәйһәкый «әс-Сүнән әл-Күбра» 3269

والثالثة يجهر بها ويمد بها صوته يقول) [رَبِّ الْمَلَائِكَةِ وَالرُّوحِ]»

90 – /Сүбхәнәл-мәликил-куддүс 3 тапкыр әйтелә, өченчесе тавыш белән сузып әйтелә һәм шуннан соң болай ди:

Раббиль-мәлә'икәти үәр-рух/

90 — «Мөкаддәс вә Патша (булган Аллаһ) барча кимчелекләрдән пакь! Ул, фәрештәләрнең һәм Рухның (Җәбраилнең) Раббысы»[127]

34 – Тынычсызлык һәм ямансу биләп алганда укыла торган дога

٩١ – «اللَّهُمَّ إِنِّى عَبْدُكَ وَابْنُ عَبْدِكَ وَابْنُ أَمَتِكَ نَاصِيَتِى بِيَدِكَ مَاضٍ فِيَّ حُكْمُكَ عَدْلٌ فِيَّ قَضَاؤُكَ أَسْأَلُكَ بِكُلِّ اسْمٍ هُوَ لَكَ سَمَّيْتَ بِهِ نَفْسَكَ أَوْ أَنْزَلْتَهُ فِى كِتَابِكَ أَوْ عَلَّمْتَهُ أَحَداً مِنْ خَلْقِكَ أَوِ اسْتَأْثَرْتَ بِهِ فِى عِلْمِ الْغَيْبِ عِنْدَكَ أَنْ

127 ән-Нәсәи 1699, 1732

تَجْعَلَ الْقُرْآنَ رَبِيعَ قَلْبِى وَنُورَ صَدْرِى وَجَلَاءَ
حُزْنِى وَذَهَابَ هَمِّى»

91 – /Аллаһүммə инни габдук, үəбнү габдик, үəбнү əмəтик, нəсыяти биядик, мəдыйн фийə хүкмүк, гадлүн фийə када‘ук, əс‘əлүкə бикүллисмин һүə лəк, сəммəйтə биһи нəфсəк, əү əнзəлтəһү фи китəбик, əү галлəмтəһү əхəдəн мин халькыйкь, əүистə‘ҫəртə биһи фи гыйлмил-гайби гыйндəк, əн тəҗгалəл-Куръəнə рабигə калби үə нүра садри үə җəлə‘ə хүзни үə ҙəһəбə һəмми/

91 — «Əй Аллаһ! Хакыйкатьтə, мин Синең колың, Синең колың булган ир-атның угълы һəм Синең колың булган хатын-кызның угълы. Мин тулысынча Синең кулында, Синең хөкемең минем өчен мəҗбүри тиешле, ə Синең миңа билгелəгəн карарың гадел. Мин Синнəн, Үзеңə Үзең исемлəгəн яки Китабыңда

индергән яки мәхлукларыңның берсенә белгерткән яки Үзеңдә яшереп калдырган һәрбер исемең белән сорыйм; Коръәнне минем калебемнең язы ит, күкрәгемнең нуры ит, кайгымның бетү сәбәбе ит һәм тынычсызлыгымның китүе ит!»[128]

٩٢ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْهَمِّ وَالْحَزَنِ وَالْعَجْزِ وَالْكَسَلِ وَالْبُخْلِ وَالْجُبْنِ وَضَلَعِ الدَّيْنِ وَغَلَبَةِ الرِّجَالِ»

92 – /Аллаһүммә инни әгүҙү бикә минәл-һәмми үәл-хәзәни үәл-гаҗзи үәл-кәсәли үәл-бүхъли үәл-җүбни үә даләгыйд-дәйни үә галәбәтир-риҗәл/

92 — «Әй Аллаһ! Мин, тынычсызлыктан һәм кайгыдан, гаҗизлектән һәм ялкаулыктан, саранлыктан һәм куркаклыктан,

128 Әхмәд «Мүснәд». Кем бу доганы укыса, һичшиксез Аллаһ аның ямансуын, тынычсызлыгын бетерер һәм шатлык китерер

бурычның авырлыгыннан һәм кешеләрнең золым кылуларыннан, Сиңа сыенам»[129]

35 – Олы кайгы килгәндә укыла торган дога

٩٣ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ الْعَظِيمُ الْحَلِيمُ، لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ رَبُّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ، لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ رَبُّ السَّمَوَاتِ، وَرَبُّ الأَرْضِ، وَرَبُّ الْعَرْشِ الْكَرِيمِ»

93 – /Лә иләһә илләАллаһүл-газыймүл-хәлим, лә иләһә илләАллаһү раббүл-гаршил-газыйм, лә иләһә илләАллаһү раббүс-сәмәүәти үә раббүл-әрьдый үә раббүл-гаршил-кәрим/

93 — «әл-Хәлим әл-Газыйм булучы Аллаһтан башка иләһ юк! Бөек гарешнең раббысы булган Аллаһтан башка иләһ юк! Күкләрнең, җирнең һәм кәрим көрсинең Раббысы бул-

129 әл-Бохари 2893. Пәйгамбәребез ﷺ бу доганы күп укый торган иде

ган Аллаһтан башка иләһ юк!»[130]

٩٤ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ سُبْحَانَكَ إِنِّى كُنْتُ مِنَ الظَّالِمِينَ»

94 – /Лә иләһә иллә әнтә сүбхәнәкә инни күнтү минәҙ-ҙалимин/

94 — «Синнән башка иләһ юк, Син барча кимчелектән пакь! Дөреслектә, мин залимнәрдән булдым»[131]

36 – Дошман яки гаделсез хөкемдарлар белән очрашудан курыкканда укыла торган дога

٩٥ – «اللَّهُمَّ إِنَّا نَجْعَلُكَ فِى نُحُورِهِمْ وَنَعُوذُ بِكَ مِنْ شُرُورِهِمْ»

95 – /Аллаһүммә иннә нәҗгалүкә фи нүхүриһим үә нәгүҙү бикә мин

130 әл-Бохари 2893

131 әт-Тирмизи 3505 (кем дә кем ошбу сүзләр белән дога кылса, Аллаһ һичшиксез аның догасына җавап бирер)

шуруриһим/

95 — «Әй Аллаһ! Дөреслектә, без Синнән аларны җиңәргә ярдәмеңне эстибез һәм аларның явызлыгыннан Сиңа сыенабыз»[132]

٩٦ – «حَسْبُنَا اللهُ وَنِعْمَ الْوَكِيلُ»

96 – /Хәсбүнә Аллаһү үә нигьмәл-үәкил/

96 — «Безгә Аллаһ җитә, һәм Ул – ни хуш әл-Вәкил! (яклаучы)»[133]

37 – Патша золымыннан куркучы укый торган дога

٩٧ – «اللَّهُمَّ رَبَّ السَّمَوَاتِ السَّبْعِ وَرَبَّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ كُنْ لِي جَاراً مِنْ فُلانِ بْنِ فُلانٍ وَأَحْزَابِهِ مِنْ خَلَائِقِكَ أَنْ يَفْرُطَ عَلَيَّ أَحَدٌ مِنْهُمْ أَوْ يَطْغَى عَزَّ جَارُكَ وَجَلَّ ثَنَاؤُكَ وَلَا إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ»

97 – /Аллаһүммә, Раббәс-

132 Әбү Дауыд 1537
133 әл-Бохари 4563

сәмәүәтис-сәбги үә Раббәл-гаршил-газыйм. Күн ли җәран мин (фүләнибни фүлән)[134] *үә әхзәбиhи мин халә'икыйкә ән йәфрута галәййә әхәдун минhүм әү йәтъга. Газзә җәрукә үә җәллә сәнә'үкә үә лә иләhә иллә әнт/*

97 — «Әй Аллаh! Син җиде күкләрнең Раббысы, һәм бөек гарешнең Раббысы. Син миңа (фәлән улы фәләннән) вә Синең мәхлукатларың булган ул бәндәнең иярченнәреннән, аларның берәрсе мине рәнҗетүеннән яки җәберләвеннән, ярдәмче вә саклаучы бул! Син саклаган кемсә генә гыйззәтле! Сиңа олуг мактау һәм Синнән башка иләһ юк!»[135]

134 Җәя эчендәге сүз урынына, кемнән курыккан булса, шул кешенең исеме әйтелә

135 әл-Бохари «әл-Әдәб әл-Мүфрад» 707

38 – Дошманга каршы укыла торган дога

٩٨ – «اللَّهُمَّ مُنْزِلَ الْكِتَابِ سَرِيعَ الْحِسَابِ، اللَّهُمَّ اهْزِمِ الأَحْزَابَ، اللَّهُمَّ اهْزِمْهُمْ وَزَلْزِلْهُمْ»

98 – /Аллаһүммә мүнзиләл-китәби сәригаль-хисәб, Аллаһүм-мәһзимил-әхзәб, Аллаһүммәһзим-һүм үә зәлзилһүм/

98 — «Әй Китап (Коръән) иңдерүче вә тиз хисаб кылучы Аллаһ! Әй Аллаһ! Берләшкән дошман төркемнәрен тар-мар ит! Әй Аллаһ! Аларны тар-мар ит һәм тетрәт!»[136]

39 – Берәр кешедән курыкканда укыла торган дога

٩٩ – «اللَّهُمَّ اكْفِنِيهِمْ بِمَا شِئْتَ»

99 – /Аллаһүммәкфиниһим бимә

136 әл-Бохари 2933

ши‘тә/

99 — «Әй Аллаһ! Мине болардан Үзең теләгәнчә (аларны газаплап) коткар!»[137]

40 – Иманында шикләнүче кеше укый торган дога

100 — Бу очракта:

а) Аллаһка сыена һәм болай ди:

«أَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ»

– */Әгүҙү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим/*

— «Ләгънәт кылынган шәйтаннан Аллаһка сыенам»[138]

б) Шикләнгән нәрсәләрне калдырырга кирәк[139]

١٠١ – «آمَنْتُ بِاللَّهِ وَرُسُلِهِ»

137 Мөслим 3005

138 әл-Бохари «әл-Фәтх» белән, Мөслим

139 әл-Бохари «әл-Фәтх» белән, Мөслим

101 – /Әмәнтү билләһи үә русүлиһи/ – дип әйтә

101 — «Аллаһка һәм Аның расүлләренә иман китердем» — дип әйтә[140]

١٠٢ – «هُوَ الْأَوَّلُ وَالْآخِرُ وَالظَّاهِرُ وَالْبَاطِنُ وَهُوَ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمٌ»

— «әл-Хәдид» сүрәсенең 3нче аятен укый:

102 — «Ул – Әүвәлге вә Ахыргы, Җиңүче вә Яшерен һәм Ул бар нәрсәне белүче»[141]

41 – Бурычларны түләү өчен ярдәм сорап укыла торган дога

١٠٣ – «اللَّهُمَّ اكْفِنِى بِحَلاَلِكَ عَنْ حَرَامِكَ وَأَغْنِنِى بِفَضْلِكَ عَمَّنْ سِوَاكَ»

140 Мөслим
141 Әбү Дауыд 5110

103 – /Аллаһүммәкфини бихәләликә ган хәрамик, үә әгънини бифадъликә гаммән сиуәк/

103 — «Әй Аллаһ! Синең хәләлең миңа җитеп Син хәрам кылган нәрсәгә керүдән котылдыр, һәм Үзеңнең фазыйләтең белән Синнән башкага мохтаҗ булудан коткар!»[142]

١٠٤ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْهَمِّ وَالْحَزَنِ وَالْعَجْزِ وَالْكَسَلِ وَالْبُخْلِ وَالْجُبْنِ وَضَلَعِ الدَّيْنِ وَغَلَبَةِ الرِّجَالِ»

104 – /Аллаһүммә инни әгүзү бикә минәл-һәмми үәл-хәзәни үәл-гаҗзи үәл-кәсәли үәл-бүхли үәл-җүбни үә даләгыйд-дәйни үә галәбәтир-риҗәл/

104 — «Әй Аллаһ! Мин, тынычсызлыктан һәм кайгыдан, гаҗизлектән һәм ялкаулыктан, саранлыктан һәм куркаклыктан, бурычның авыр-

142 эт-Тирмизи 3563. Әгәр синең тау кадәр бурычың булса да, Аллаһ сиңа аны түләргә ярдәм итәчәк

лыгыннан һәм кешеләрнең золым кылуларыннан, Сиңа сыенам»[143]

42 – Намаз һәм Коръән укыганда шәйтан вәсвәсәсеннән саклану догасы

١٠٥ – «أَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ»

105 – /Әгүҙү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим/ (бу сүзләрне әйткәч 3 тапкыр сул якка төкерергә кирәк)

105 — «Ләгънәт кылынган шәйтаннан Аллаһка сыенам»[144]

143 әл-Бохари 2893. Пәйгамбәребез ﷺ бу доганы күп укый торган иде
144 Мөслим

43 – Кешегә бирәр эш авыр күренгәндә укыла торган дога

١٠٦ – «اللَّهُمَّ لا سَهْلَ إِلَّا مَا جَعَلْتَهُ سَهْلاً وَأَنْتَ
تَجْعَلُ الْحَزْنَ إذا شِئْتَ سَهْلاً»

106 – /Аллаһүммә лә сәһлә иллә мә җәгалтәһү сәһлә, үә әнтә тәҗгалүл-хәзнә иҙә ши'тә сәһлә/

106 — «Әй Аллаһ! Син җиңел кылган нәрсәдән башка җиңел һичнәрсә юк, һәм әгәр Син теләсәң кайгыны җиңел итәсең»[145]

44 – Гөнаһ кылган кеше нәрсә эшләргә һәм укырга тиеш

107 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә кешеләрдән берсе гөнаһ эшләсә, аннары тиешле рәвеш-

145 Ибен Хиббән «Сахих» 2427

тә (сөннәтләре белән) таһәрат алып ике ракәгать намаз укыса һәм соңыннан Аллаһтан ярлыкауны сораса, Аллаһ тәгалә аны гафу итәр»[146]

45 – Шәйтанны һәм аның вәсвәсәсен куа торган дога

108 — Аллаһка шәйтаннан сыену:

«أَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ»

– */Әгүҙү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим/*

— «Ләгънәт кылынган шәйтаннан Аллаһка сыенам»[147]

109 — Азан сүзләре[148]

110 — Аллаһны зикер итү һәм Коръән уку[149]

146 Әбү Дауыд 1521
147 Әбү Дауыд һәм әт-Тирмизи
148 әл-Бохари, Мөслим
149 Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Йортларыгызны

46 – Кешегә берәр нәрсә ошамаганда яки бернәрсә дә эшли алмаган очракта укыла торган дога

١١١ – «قَدَرُ اللَّهِ وَمَا شَاءَ فَعَلَ»

111 – /Кадәруллаhи үә мә шә' фәгалә/

111 — «Бу Аллаhның тәкъдире, hәм Ул нәрсә теләде, шуны эшләде»[150]

каберлекләргә әйләндермәгез! Дөреслектә, «әл-Бәкара» сүрәсе укылган йорттан шәйтан читләшә» (Мөслим 780)

Шулай ук, шәйтанны куа торган нәрсәләр: иртән hәм кич укыла торган зикер-догалар, йоклар алдыннан hәм торганнан соң укыла торган зикер-догалар, йортка кергәндә hәм чыкканда укыла торган зикер-догалар, мәчеткә кергәндә hәм чыкканда укыла торган зикер-догалар hәм башкалар...

150 Мөслим 2664. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Көчле мөэмин Аллаh каршында зәгыйфь мөэмингә караганда хәерлерәк hәм сөеклерәк, hәм аларның икесендә дә яхшылык бар. Сиңа файда китерә торган нәрсәгә хирыс бул hәм Аллаhтан ярдәм сора вә гаҗиз булма. Әгәр сиңа бер авырлык килсә: «Әгәр дә мин тегене hәм моны эшләгән булсамчы!», –

47 – Баласы туган кешегә котлап әйтелә торган дога

١١٢ – «جَعَلَهُ اللَّهُ مُبَارَكًا عَلَيْكَ، وَعَلَى أُمَّةِ مُحَمَّدٍ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ»

112 – /Җәгаләә Аллаһу мүбәракән галәйкә үә галә үммәти Мүхәммәд/

112 — «Аллаһ аны сиңа һәм Мөхәммәднең өммәтенә мөбәрак бала кылсын!»[151]

48 – Балаларны саклау өчен укыла торган дога

113 — Пәйгамбәребез ﷺ Хәсән белән Хөсәенне төрле яманлык вә бозыклыктан саклар өчен шундый

дип әйтмә, бәлки: «Бу Аллаһның тәкъдире, һәм Ул нәрсә теләде, шуны эшләде», – диген. Чөнки «әгәр дә» дигән сүз, шәйтан эшенең ишеген ача

151 әт-Табәраний «әд-Дуга» 945, шулай ук 946 нчы сан белән килгән әсәрдә Әюб әс-Сәхтияни баласы туган кешене шулай котлый иде дип риваять ителде

дога укыган:

«أُعِيذُكُمَا بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّامَّةِ مِنْ كُلِّ شَيْطَانٍ وَهَامَّةٍ وَمِنْ كُلِّ عَيْنٍ لاَمَّةٍ»

– /Үгыйҙүкүмә би кәлимәтил-ләһит-тәммәти мин күлли шәйтанин үә һәммәтин үә мин күлли гайнин ләәммәһ/

— «Аллаһның камил сүзләре сезне һәрбер шәйтаннан, хәшәрәттән һәм яман күздән сакласын дип, мин ул сүзләргә сыенам»[152]

49 – Авыруны зиярат кылганда укыла торган дога

١١٤ – «لاَ بَأْسَ طَهُورٌ إِنْ شَاءَ اللَّهُ»

114 – /Лә бә‘сә таһүрун иншә‘-Аллаһ/

114 — «Зарар юк, пакьланерсең Аллаһ теләсә»[153]

152 әл-Бохари 3371. Аллаһның камил сүзләренә сыену мәгънәсен 113нче дога астөшермәсеннән кара
153 әл-Бохари 3616

١١٥ – «أَسْأَلُ اللهَ الْعَظِيمَ رَبَّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ أَنْ يَشْفِيَكَ»

115 – /Әс'әлуллаһәл-газыймә раббәл-гаршил-газыйми ән йәшфийәк/ (7 тапкыр әйтелә)

115 — «Бөек гарешнең Раббысы булган Бөек Аллаһтан сине шифаландыруын сорыйм»[154]

50 – Авыруны зиярат кылуның фазыйләте

116 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Иртә белән авырган мөселманның хәлен белергә барган мөселман өчен җитмеш мең фәрештә кичкә кадәр дога кылачаклар, әгәр ул (авыру янына) кич белән барса җитмеш мең фәрештә аның өчен

154 Әбү Дауыд 3106. Мөселман, авыру булган һәм әҗәле җитмәгән кардәшенең хәлен белеп зиярат кылса, һәм 7 тапкыр ошбу доганы кабатласа, ул кешене Аллаһ тәгалә һичшиксез авыруыннан шифа кылыр

иртәнгә кадәр дога кылачаклар, ә Җәннәттә аның өчен җимешләр җыелачак»[155]

51 – Яшәү өметен югалткан авыруның догасы

١١٧ – «اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِي وَارْحَمْنِي وَأَلْحِقْنِي بِالرَّفِيقِ الأَعْلَى»

117 – /Аллаһүммәгьфирли үәръхәмни үә әлхикъни биррафикыйлъәгьлә/

117 — «Әй Аллаһ! Мине гафу ит, миңа рәхимлек кыл һәм мине әр-Рафикъ әл-Әгьлә белән кушылдыр»[156]

118 — Пәйгамбәребез ﷺ вафат булыр алдыннан кулларын сулы савытка тыгып, алар белән йөзен сыпырып болай диде:

155 әт-Тирмизи 969

156 әл-Бохари 5672. «әр-Рафикъ әл-Әгьлә» монда яки Аллаһ тәгалә, чөнки бу аның күркәм исемнәре, яки пәйгамбәрләр, тугрылар, шәһидләр һәм изгеләр

«لَا إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ، إِنَّ لِلْمَوْتِ سَكَرَاتٍ»

– /Лә иләһә иллә Аллаһ, иннә лилмәүти ләсәкәрат/

— «Аллаһтан башка иләһ юк, дөреслектә, үлемнең авырлыклары бар»[157]

١١٩ – «لَا إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ أَكْبَرُ. لَا إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ. لَا إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ. لَا إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ. لَا إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَلَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ إِلاَّ بِاللَّهِ»

119 – /Лә иләһә иллә Аллаһү үәАллаһү әкбәру, лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәхү, лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәху лә шәрикә ләһү, лә иләһә иллә Аллаһү ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмдү, лә иләһә иллә Аллаһү үә лә хәүлә үә лә куүәтә иллә билләһ/

119 — «Аллаһтан башка иләһ юк һәм Аллаһ бөек! Бер Аллаһтан башка иләһ юк! Бер Аллаһтан башка иләһ юк, Аның тиңдәше юк!

157 әл-Бохари 4449

Аллаһтан башка иләһ юк, Аңа гына барча патшалык һәм Аңа гына барча мактау! Аллаһтан башка иләһ юк, һәм Аллаһтан башка көч-куәт юк!»[158]

52 – Үлүчегә тәлкыйнь[159] кылу

120 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Кемнең ахыргы сүзләре

«لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ»

– /Лә иләһә иллә Аллаһ/

— «Аллаһтан башка иләһ юк», — дигән сүзләр булса, Җәннәткә керер»[160]

158 әт-Тирмизи 3430, ибен Мәҗәһ 3794 (кем авырган вакытта бу сүзләрне әйтсә, ә аннары вафат булып китсә, Ут аңа тимәс)
159 Үлүче кешегә, иман кәлимәсен аның янында кабатлап торып, әйтергә ярдәм итү
160 Әбү Дауыд 3116

53 – Кайгы-хәсрәткә юлыккан кеше укый торган дога

١٢١ – «إِنَّا لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ اللَّهُمَّ أْجُرْنِى فِى مُصِيبَتِى وَأَخْلِفْ لِى خَيْرًا مِنْهَا»

121 – /Иннә лилләhи үә иннә иләйhи раҗигүн, Аллаhүммә'җүрни фи мүсыйбәти үә әхълиф ли хайран минhә/

121 — «Хакыйкатьтә, без Аллаhныкы һәм Аңа кайтачакбыз. Әй Аллаһ! Бу кайгы-хәсрәтемдә мине саваплы ит, һәм миңа аннан да яхшыракны бир»[161]

54 – Мәетнең күзләрен йомдыргач укыла торган дога

161 Мөслим 918. Кем бу доганы укыса, һичшиксез Аллаһ аны кайгы-хәсрәте өчен саваплы итәр һәм анын урынына яхшыракны бирер

١٢٢ – «اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِ(فُلَانٍ بِاسْمِهِ) وَارْفَعْ دَرَجَتَهُ فِى الْمَهْدِيِّينَ وَاخْلُفْهُ فِى عَقِبِهِ فِى الْغَابِرِينَ وَاغْفِرْ لَنَا وَلَهُ يَا رَبَّ الْعَالَمِينَ وَافْسَحْ لَهُ فِى قَبْرِهِ وَنَوِّرْ لَهُ فِيهِ»

122 – /Аллаһүммәгьфир ли (...)[162] үәръфәгь дәраҗәтәһү фил-мәһдиййин, үәхълүфһү фи гакыйбиһи фил-габирин, үәгъфир ләнә үә ләһү йә раббәл-галәмин, үәфсәх ләһү фи кабриһи үә нәүүир ләһү фиһ/

122 — «Әй Аллаһ! Фәләнне (мәетнең исеме әйтелә) ярлыка һәм аның дәрәҗәсен һидәятлеләр арасында күтәр. Аннан соң калганнарга, аны икенче белән алыштыр. Әй галәмнәрнең Раббысы, безне һәм аны гафу ит! Аның каберен киң кыл һәм аңа аны нурландыр!»[163]

162 Бу урында мәетнең исеме әйтелә
163 Мөслим 920

55 – Җеназа намазы догасы

١٢٣ – «اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِحَيِّنَا وَمَيِّتِنَا وَشَاهِدِنَا وَغَائِبِنَا وَصَغِيرِنَا وَكَبِيرِنَا وَذَكَرِنَا وَأُنْثَانَا اللَّهُمَّ مَنْ أَحْيَيْتَهُ مِنَّا فَأَحْيِهِ عَلَى الإِسْلاَمِ وَمَنْ تَوَفَّيْتَهُ مِنَّا فَتَوَفَّهُ عَلَى الإِيمَانِ اللَّهُمَّ لاَ تَحْرِمْنَا أَجْرَهُ وَلاَ تُضِلَّنَا بَعْدَهُ»

123 – /Аллаһүммәгьфир лихәйинә үә мәйитинә үә шәһидинә үә гаибинә үә сагыйринә үә кәбиринә үә ҙәкәринә үә үнҫәнә, Аллаһүммә мән әхйәйтәһү миннә фә‘әхйиһи галәл-Исләми үә мән тәүәффәйтәһү миннә фәтәүәффәһү галәл-имән, Аллаһүммә лә тәхримнә әҗраһү үә лә түдыйлләнә бәгьдәһү/

123 — «Әй Аллаһ! Безнең исәннәребезне вә үлгәннәребезне, монда булучыларыбызны вә монда булмаучыларыбызны, сабыйларыбызны вә олыларыбызны, ирләребезне вә хатын-кызларыбызны гафу ит! Әй Аллаһ! Безнең ара-

дагыларның кайсысына тормыш бирсәң – аңа Ислам тормышы бир, ә безнең арадан кемне вафат кылсаң – аны Иманда вафат кылдыр! Әй Аллаһ! Безне аның савабыннан[164] мәхрүм итмә, һәм аннан соң безне адаштырма!»[165]

56 – Сабый баланың җеназасында укыла торган дога

١٢٤ – «اللَّهُمَّ أَعِذْهُ مِنْ عَذَابِ الْقَبْرِ»

124 – /Аллаһүммә әгыйҙһү мин газәбил-кабр/

124 — «Әй Аллаһ! Аны кабер газабыннан сакла!»[166]

١٢٥ – «اللَّهُمَّ اجْعَلْهُ لَنَا فَرَطًا وَسَلَفًا وَأَجْرًا»

125 – /Аллаһүммәҗгалһү ләнә фәратан үә сәләфән үә әҗра/

164 Ягъни, бу кеше вафат булганнан соң сабырлык күрсәткән өчен безне савабтан мәхрүм итмә

165 Ибен Мәҗәһ 1498

166 Мәлик «әл-Мүәтта'»

125 — «Әй Аллаһ! Аны Җәннәткә бездән алда узучы ит, бездән әлгәре булсын һәм безгә килгән кайгыда сабырлыгыбыз өчен әҗер-савап булсын!»[167]

57 – Тәгъзия[168] догасы

١٢٦ – «إِنَّ لِلَّهِ مَا أَخَذَ وَلَهُ مَا أَعْطَى وَكُلُّ شَيْءٍ عِنْدَهُ بِأَجَلٍ مُسَمًّى ... فَلْتَصْبِرْ وَلْتَحْتَسِبْ»

126 – /Иннә лиләһи мә әхаҙә үә ләһү мә әгьта үә күллү шәй'ин гыйндәһү би әҗәлин мүсәммә ... фәлтәсъбир үәлтәхтәсиб/

126 — «Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә алганы да, биргәне дә – Аныкы, һәм һәрнәрсәгә Ул әҗәл-вакытын билгеләде ... Шулай булгач, сабырлык күрсәт һәм Аллаһтан әҗер-савап өмет ит!»[169]

167 әл-Бохари 65нче бәб

168 Үлгән кешенең якыннарының һәм туганнарының кайгысын уртаклашу, юату

169 әл-Бохари 1284

۞ Әгәр ошбу доганы укыса, яхшы була:

«أَعْظَمَ اللهُ أَجْرَكَ وَأَحْسَنَ
عَزَاءَكَ وَغَفَرَ لِمَيِّتِكَ»

– /Әгъҙамә Аллаһү әҗракә үә әхсәнә газә'әкә үә гафәра лимәййтикә/

— «Аллаһ синең әҗереңне зурайтсын, күркәм юаныч бирсен һәм вафат булган кешеңне ярлыкасын!»[170]

58 – Мәетне кабергә куйганда укыла торган дога

١٢٧ – «بِسْمِ اللَّهِ وَعَلَى مِلَّةِ رَسُولِ اللَّهِ»

127 – /Бисмилләһ, үә галә милләти расүлилләһ/

127 — «Аллаһ исеме белән, һәм Аллаһ расүленең милләтенә муафыйк итеп»[171]

170 ән-Нәүәуи «әл-Әзкәр»
171 Ибен Мәҗәһ 1550

59 – Мәетне җирләгәч укыла торган дога

١٢٨ – «اللَّهُمَّ اغْفِرْ لَهُ اللَّهُمَّ ثَبِّتْهُ»

128 – /Аллаһүммәгъфир ләһү, Аллаһүммә çәббитһү/

128 — «Әй Аллаһ! Аның гөнаһларын ярлыка! Әй Аллаһ! Аны сабит кыл!»[172]

60 – Каберләрне зиярат кылганда укыла торган дога

١٢٩ – «السَّلاَمُ عَلَيْكُمْ أَهْلَ الدِّيَارِ مِنَ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُسْلِمِينَ وَإِنَّا إِنْ شَاءَ اللَّهُ لَلاَحِقُونَ أَسْأَلُ اللَّهَ لَنَا وَلَكُمُ الْعَافِيَةَ»

129 – /Әссәләмү галәйкүм әһләд-дийәри минәл-мү'мининә үәл-мүслимин, үә иннә иншә'Аллаһү

172 Әбү Дауыд 3221. Пәйгамбәребез ﷺ мәетне җирләгәннән соң, кабер янына басты һәм: «Кардәшегезгә ярлыкау һәм ныклык сорагыз, хакыйкатьтә, ул хәзер сорала», – диде

ләләһикун, әс‘әлүллаһә ләнә үә ләкүмүл-гафийәһ/

129 — «Мөэмин вә мөселман булган кабер әһелләренә сәлам булсын! Хакыйкатьтә, Аллаһ теләсә без дә сезгә кушылырбыз. Үзебезгә һәм сезгә Аллаһтан иминлек сорыйм»[173]

61 – Җил чыкканда укыла торган дога

١٣٠ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْأَلُكَ خَيْرَهَا وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهَا»

130 – /Аллаһүммә инни әс‘әлүкә хайраһә үә әгүҙү бикә мин шәрриһә/

130 — «Әй Аллаһ! Хакыйкатьтә, мин Синнән бу җилнең яхшылыгын сорыйм һәм Сиңа аның явызлыгыннан сыенам»[174]

173 Мөслим 975

174 Әбү Дауыд, ибен Мәҗәһ

62 – Күк күкрәгәндә укыла торган дога

١٣١ – «سُبْحَانَ الَّذِى يُسَبِّحُ الرَّعْدُ بِحَمْدِهِ وَالْمَلاَئِكَةُ مِنْ خِيفَتِهِ»

131 – /Сүбхәнәлләҙи йүсәббихүр-рагьдү бихәмдиһи үәл-мәлә'икәтү мин хыйфәтиһи/

131 — «Күкрәү һәм фәрештәләр Аннан куркып мактау тәсбихләре әйткән Аллаһ, һәркимчелектән пакь!»[175]

63 – Яңгыр сораганда укыла торган дога

١٣٢ – «اللَّهُمَّ اسْقِنَا غَيْثًا مُغِيثًا مَرِيئًا مَرِيعًا نَافِعًا غَيْرَ ضَارٍّ عَاجِلاً غَيْرَ آجِلٍ»

132 – /Аллаһүммәскыйнә гайҫән мүгыйҫән мәри'ән мәриган, нәфиган гайра даррин, гаҗилән гайра әҗилин/

175 әл-Муәтта 3641

132 — «Әй Аллаһ! Безне, коткаручы, шатлыклы, үндырышлы, зарарлы түгел ә файдалы, соңга калмый торган ә тиз булучы яңгыр белән сугар!»[176]

١٣٣ – «اللَّهُمَّ أَغِثْنَا، اللَّهُمَّ أَغِثْنَا، اللَّهُمَّ أَغِثْنَا»

133 – /Аллаһүммә әгыйҫнә, Аллаһүммә әгыйҫнә, Аллаһүммә әгыйҫнә/

133 — «Әй Аллаһ! Безгә (яңгыр белән) ярдәм ит! Әй Аллаһ! Безгә (яңгыр белән) ярдәм ит! Әй Аллаһ! Безгә (яңгыр белән) ярдәм ит!»[177]

١٣٤ – «اللَّهُمَّ اسْقِ عِبَادَكَ وَبَهَائِمَكَ وَانْشُرْ رَحْمَتَكَ وَأَحْيِ بَلَدَكَ الْمَيِّتَ»

134 – /Аллаһүммәскый гыйбәдәкә үә бәһә'имәкә үәншүр рахмәтәкә үә әхйи бәләдәкәл-мәйит/

134 — «Әй Аллаһ! Үзеңнең кол-

176 Әбү Дауыд 1169
177 эл-Бохари 1014

ларыңны һәм хайваннарыңны сугар. Үзеңнең рәхмәтеңне җәй һәм мәет булган җиреңне терелт!»[178]

64 – Яңгыр яуганда укыла торган дога

١٣٥ – «اللَّهُمَّ صَيِّبًا نَافِعًا»

135 – /Аллаһүммә сайибән нәфиган/

135 — «Әй Аллаһ! Бу яңгыр файдалы булсын!»[179]

65 – Яңгыр яуганнән соң укыла торган дога

١٣٦ – «مُطِرْنَا بِفَضْلِ اللَّهِ وَرَحْمَتِهِ»

136 – /Мүтыйрнә бифәдълилләһи үә рахмәтиһ/

136 — «Аллаһның фазыйләте вә рәхмәте илә безгә яңгыр яуды»[180]

178 Әбү Дауыд 1169
179 әл-Бохари 1032
180 әл-Бохари 846

66 – Берөзлексез яуган яңгырны туктатуны сорап укыла торган дога

١٣٧ – «اللَّهُمَّ حَوَالَيْنَا وَلاَ عَلَيْنَا، اللَّهُمَّ عَلَى الآكَامِ وَالظِّرَابِ وَبُطُونِ الأَوْدِيَةِ وَمَنَابِتِ الشَّجَرِ»

137 – /Аллаһүммә хәүәлинә үә лә галәйнә, Аллаһүммә галәл-әкәми үәҙҙыйраби үә бүтунил-әүдияти үә мәнәбитиш-шәҗәр/

137 — «Әй Аллаһ! Безгә түгел, ә тирә-юньгә яудыр. Әй Аллаһ! Калкулыкларга һәм тауларга, үзәнлекләргә һәм агачлар үскән җирләргә яудыр!»[181]

67 – Яңа туган ай күргәндә укыла торган дога

١٣٨ – «اللَّهُمَّ أَهْلِلْهُ عَلَيْنَا بِالْيُمْنِ وَالإِيمَانِ وَالسَّلاَمَةِ وَالإِسْلاَمِ رَبِّى وَرَبُّكَ اللَّهُ»

181 әл-Бохари 1013

138 – /Аллаһүммә әһлилһү галәйнә бил-йүмни үәл-имәни үәс-сәләмәти үәл-исләм, раббиүә раббүкә Аллаһ/

138 — «Әй Аллаһ! Бу айны безнең өстебезгә иминлек һәм Иман белән, сәламәтлек һәм Ислам белән китер. Минем Раббым һәм синең Раббың – Аллаһ!»[182]

68 – Авыз ачканда укый торган дога

١٣٩ – «ذَهَبَ الظَّمَأُ وَابْتَلَّتِ الْعُرُوقُ وَثَبَتَ الأَجْرُ إِنْ شَاءَ اللَّهُ»

139 – /Ҙәһәбәҙ-ҙамә'ү үәбтәлләтил-гуруку үә ҫәбәтәл-әҗру иншә'-Аллаһ/

139 — «Сусау китте, кан тамырлары юешләнде һәм әҗер-савап та булды иншә'Аллаһ»[183]

182 әт-Тирмизи 3451

183 Әбү Дауыд 2357

١٤٠ ـ «اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْأَلُكَ بِرَحْمَتِكَ الَّتِى وَسِعَتْ كُلَّ شَىْءٍ أَنْ تَغْفِرَ لِى»

140 – /Аллаһүммә инни әс‘әлүкә бирахмәтикәлләти үәсигать күллә шәй‘ин ән тәгъфира ли/

140 — «Әй Аллаһ! Дөреслектә, бар нәрсәне үзенә алган Синең рәхмәтең илә, мине гафу итүеңне сорыйм»[184]

69 – Ашар алдыннан укый торган дога

141 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Ашый башлаганчы сезнең һәркайсыгыз: بِسْمِ اللهِ ***/Бисмилләһ/*** — дип, Аллаһның исемен искә алсын, әгәр ул Аллаһ тәгаләнең исемен искә алырга онытса:

«بِسْمِ اللهِ فِى أَوَّلِهِ وَآخِرِهِ»

— /Бисмилләһи фи әүүәлиһи үә әхыйриһи!/

184 Ибен Мәҗәһ 1753 (шәйх Әлбәни зәгыйфь диде)

— Әүвәлдә һәм ахырда Аллаһ исеме белән! — дисен».[185]

142 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Кемне Аллаһ ашау ризыгы белән ашатса, болай дисен:

«اللَّهُمَّ بَارِكْ لَنَا فِيهِ وَأَطْعِمْنَا خَيْرًا مِنْهُ»

— /Аллаһуммә бәрик ләнә фиһи үә әтъгыймнә хайран минһү/

— «Әй Аллаһ! Безгә аны бәракәтле кыл һәм моннан да яхшырак белән ризыкландыр!»

Ә кемне Аллаһ сөт эчертсә, болай дисен:

«اللَّهُمَّ بَارِكْ لَنَا فِيهِ وَزِدْنَا مِنْهُ»

— /Аллаһуммә бәрик ләнә фиһи үә зиднә минһү/

— «Әй Аллаһ! Безгә аны бәракәтле кыл һәм арттыр»[186]

185 әт-Тирмизи 1858

186 әт-Тирмизи 3455

70 – Ашаганнан соң укыла торган дога

١٤٣ – «الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي أَطْعَمَنِي هَذَا وَرَزَقَنِيهِ مِنْ غَيْرِ حَوْلٍ مِنِّي وَلاَ قُوَّةٍ»

143 – /Әлхәмдүлилләһил-ләҙи әтъгәмәни һәҙә үә разәканиһи мин гайри хәүлин минни үә лә куүәһ/

143 — «Минем хәлем һәм көчем кулланылмыйча, мине моның белән ашатучы һәм ризыкландыручы Аллаһка барча мактау булсын!»[187]

71 – Кунакның мәҗлес хуҗасы өчен укый торган догасы

١٤٤ – «اللَّهُمَّ بَارِكْ لَهُمْ فِي مَا رَزَقْتَهُمْ وَاغْفِرْ لَهُمْ وَارْحَمْهُمْ»

144 – /Аллаһүммә бәрик ләһүм

187 әт-Тирмизи 3458 (Ашаганнан соң бу доганы укучының алдагы гөнаһлары гафу ителә)

фи мә разәкътәһүм үәгьфир ләһүм үәръхәмһүм/

144 — «Әй Аллаһ! Син аларны ризыкландырган нәрсәләргә бәракәт бир, һәм аларны ярлыка вә аларга рәхимлек кыл»[188]

72 – Су эчеручегә яки су эчерергә теләүчегә карата укыла торган дога

١٤٥ – «اللَّهُمَّ أَطْعِمْ مَنْ أَطْعَمَنِى وَأَسْقِ مَنْ أَسْقَانِى»

145 – /Аллаһүммә әтъгыйм мән әтъгамәни үә әскый мән әскани/

145 — «Әй Аллаһ! Миңа ризык ашатучыны – ашат һәм миңа су эчеручене – эчерт»[189]

188 Мөслим 2042
189 Мөслим 2055

73 – Авыз ачучы мәҗлес хуҗасына карата укый торган дога

١٤٦ ـ «أَفْطَرَ عِنْدَكُمُ الصَّائِمُونَ وَأَكَلَ طَعَامَكُمُ الأَبْرَارُ وَصَلَّتْ عَلَيْكُمُ الْمَلاَئِكَةُ»

146 – /Әфтара гыйндәкумус-са'имүнә үә әкәлә тагамәкумүл-әбрару үә салләт галәйкүмүл-мәлә'икәтү/

146 — «Ураза тотучылар сездә авыз ачсын, сезнең ашларыгызны игелекле кешеләр ашасын һәм сезгә фәрештәләр салават-догалар кылсын!»[190]

190 Әбү Дауыд 3854

74 – Әгәр ризык китерсәләр, ә ураза тотучы уразасын өзергә теләмәсә нинди дога укырга тиеш

147 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Берәрегез (мәҗлескә) чакырылса – чакыруны кабул итсен, әгәр ул уразада булса – (алар өчен) дога кылсын, ә инде уразада булмаса – ашасын!»[191]

75 – Әгәр ураза тотучыны берәү сүксә, ул нәрсә әйтергә тиеш

١٤٨ — «إِنِّى صَائِمٌ إِنِّى صَائِمٌ»

148 – /Инни са‘им, инни са‘им/

148 — «Дөреслектә, мин ураза тотучы! Дөреслектә, мин ураза тотучы!»[192]

191 Мөслим 1431

192 әл-Бохари 1894

76 – Беренче өлгергән җимешләрне күргәч укыла торган дога

١٤٩ – «اللَّهُمَّ بَارِكْ لَنَا فِى ثَمَرِنَا وَبَارِكْ لَنَا فِى مَدِينَتِنَا وَبَارِكْ لَنَا فِى صَاعِنَا وَبَارِكْ لَنَا فِى مُدِّنَا»

149 – /Аллаһүммә бәрик ләнә фи ҫәмәринә үә бәрик ләнә фи мәдинәтинә үә бәрик ләнә фи сагыйнә үә бәрик ләнә фи мүддинә/

149 — «Әй Аллаһ! Безнең җимешләребезне бәракәтле кыл, һәм безнең шәһәребезне бәракәтле кыл, һәм безнең сагьларыбызны[193] бәракәтле кыл, һәм безнең мүдләребезне[194] бәракәтле кыл!»[195]

193 Үлчәү күләме
194 Үлчәү күләме
195 Мөслим 1373

77 – Төчкергәннән соң укыла торган дога

150 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә берәрегез төчкерсә: «Аллаһ тәгаләгә мактау булсын!» اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ **/Әлхәмдүлилләһ/** — дип әйтсен, һәм аның кардәше яки аның юлдашы аңа: «Сине Аллаһ ярлыкасын!» يَرْحَمُكَ اللهُ **/ЙәрхәмүкәАллаһ!/** — дисен. Ә әгәр ул аңа: «Аллаһ сине ярлыкасын!» يَرْحَمُكَ اللهُ /ЙәрхәмүкәАллаһ!/ — дип әйтсә, төчкерүче аңа җавап итеп: «Аллаһ сезгә һидәять бирсен һәм барлык эшләрегезне яхшыртсын!» يَهْدِيكُمُ اللهُ وَيُصْلِحُ بَالَكُمْ ***/Йәһдикүмуллаһү үә йуслих бәләкүм!/*** — дип әйтсен»[196]

196 әл-Бохари 6224

78 – Әгәр кәфер төчкерсә һәм Аллаһны мактаса, аңа нәрсә әйтелергә тиеш

١٥١ – «يَهْدِيكُمُ اللَّهُ وَيُصْلِحُ بَالَكُمْ»

151 – /Йәһдикүмуллаһү үә йуслих бәләкүм!/

151 — «Аллаһ сезгә һидәять бирсен һәм барлык эшләрегезне яхшыртсын!»[197]

79 – Яңа өйләнгәннәрне котлап укыла торган дога

١٥٢ – «بَارَكَ اللَّهُ لَكَ وَبَارَكَ عَلَيْكَ وَجَمَعَ بَيْنَكُمَا فِى خَيْرٍ»

152 – /БәракАллаһү ләкә үә бәрәкә галәйкә үә җәмәга бәйнәкүмә фи хайр/

152 — «Аллаһ сиңа бәракәт бирсен вә бәракәт индерсен, һәм сезне

197 әт-Тирмизи, Әхмәд, Әбү Дауыд

хәере белән берләштерсен!»[198]

80 – Өйләнгән кеше һәм хайван сатып алучы укый торган дога

153 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә берәрегез өйләнсә яки хезмәтче сатып алса, болай дип дога кылсын:

«اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْأَلُكَ خَيْرَهَا وَخَيْرَ مَا جَبَلْتَهَا عَلَيْهِ وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهَا وَمِنْ شَرِّ مَا جَبَلْتَهَا عَلَيْهِ»

– /Аллаһүммә инни әс‘әлүкә хайраһә үә хайра мә җәбәлтәһә галәйһи үә әгүҙү бикә мин шәрриһә үә шәрри мә җәбәлтәһә галәйһи/

— «Әй Аллаһ! Мин Синнән аның яхшылыгын вә аңарда Син халикъ кылган яхшылыкны сорыйм, һәм

198 Әбү Дауыд 2130

аның яманлыгыннан вә аңарда Син халикъ кылган яманлыктан Сиңа сыенам»

Әгәр дөя сатып алса, аның өркәченнән тотып шушы ук доганы укый[199]

81 – Хатын белән җенси якынлык кылыр алдыннан укый торган дога

١٥٤ – «بِسْمِ اللَّهِ اللَّهُمَّ جَنِّبْنَا الشَّيْطَانَ وَجَنِّبِ الشَّيْطَانَ مَا رَزَقْتَنَا»

154 – /Бисмилләһ, Аллаһүммә җәннибнәш-шәйтанә үә җәннибиш-шәйтанә мә разәкътәнә/

154 — «Әй Аллаһ! Бездән шәйтанны ерагайт, һәм безгә биргән баладан шәйтанны ерагайт!»[200]

199 Ибен Мәҗәһ, Әбү Дауыд 2160. Маңгай чәченнән тотып бәракәт эсти яки шушы доганы укый

200 әл-Бохари 6388. Алар ошбу женси якынлашуларыннан балага узса, ул балага шәйтан беркайчан да зыян итә алмый

82 – Ачуланганда укыла торган дога

١٥٥ – «أَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ»

155 – /Әгуҙү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим/

155 — «Барча рәхмәттән сөрелмеш шәйтаннан, Аллаһка сыенам»[201]

83 – Бәла-казага ирешүчене күргәндә укыла торган дога

١٥٦ – «الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِى عَافَانِى مِمَّا ابْتَلاَكَ بِهِ وَفَضَّلَنِى عَلَى كَثِيرٍ مِمَّنْ خَلَقَ تَفْضِيلاً»

156 – /Әлхәмдүлилләһилләҙи гафәни миммәбтәләкә биһи үә фәдъдаләни галә кәҫирим-миммән халәка тәфдыйлә/

156 — «Сине сынаган нәрсәдән мине саклап калган һәм күп кенә мәхлукатларга караганда миңа

201 әл-Бохари 6515

өстенлек күрсәткән Аллаһка барча мактаулар булсын!»[202]

84 – Нинди дә булса җыенда яки мәҗлестә укыла торган дога

157 — Габдуллаһ бин Гомәр ﷺ әйтте:

— Пәйгамбәребез ﷺ берәр җыенда яки мәҗлестә булса, аннан торып киткәнче ошбу доганы 100 тапкыр әйтә иде:

«رَبِّ اغْفِرْ لِى وَتُبْ عَلَىَّ إِنَّكَ أَنْتَ التَّوَّابُ الْغَفُورُ»

– /Раббигьфир ли үә түб галәййә иннәкә әнтәт-тәүүәбүл-гафүръ/

— «Әй Раббым! Мине гафу ит һәм тәүбәмне кабул ит, хакыйкатьтә,

202 әт-Тирмизи 3431 (Кем, бәла ирешкән кешене күргәннән соң ошбу доганы укыса, аңа бу бәла ирешмәс)

Син тәүбәләрне кабул итүче һәм ярлыкаучы»[203]

85 – Җыен яки мәҗлес ахырында укыла торган дога

١٥٨ – «سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ وَبِحَمْدِكَ أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ أَسْتَغْفِرُكَ وَأَتُوبُ إِلَيْكَ»

158 – /СүбхәнәкәАллаһүммә үә бихәмдик, әшһәдү әллә иләһә иллә әнт, әстәгьфирукә үә әтүбү иләйк/

158 — «Әй Аллаһ! Син барча кимчелектән пакьсең һәм Сиңа барча мактау! Синнән башка иләһ юк дип шәһидлек кылам. Синнән ярлыкау сорыйм һәм Сиңа тәүбә итәм!»[204]

203 әт-Тирмизи 3434

204 Әбү Дауыд 4859 Бу дога җыен яки мәҗлестәге гөнаһлар өчен йолу (кәффәрат). Гаишә әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ нинди генә мәҗлестә булса да, Коръән укыса яки намаз укыса, иллә-мәгәр ошбу дога белән тәмамлый торган иде» (ән-Нәсәи «Гамәл әл-йәүм үә әл-ләйләһ», Әхмәд)

86 – «Аллаһ сине ярлыкасын», /ГафәрАллаһү ләк/ «غَفَرَ اللَّهُ لَكَ» — диючегә әйтелә

١٥٩ – «وَلَكَ»

159 – /Үә ләкә/

159 — «Сине дә!»[205]

87 – Сиңа яхшылык эшләгән кешегә әйтелә торган дога

١٦٠ – «جَزَاكَ اللَّهُ خَيْرًا»

160 – /ҖәзәкәАллаһү хайра/

160 — «Аллаһ сиңа хәерле бәясен бирсен!»[206]

88 – Аллаһ мөселманны Дәҗҗәлдән саклый торган дога-зикерләр

205 Әхмәд, эн-Нәсәи «Гамәл әл-йәүм үә әл-ләйләһ»
206 әт-Тирмизи 2035

161 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Кем дә кем «әл-Кәһф» сүрәсенең беренче ун аятен ятласа, Дәҗҗәлдән сакланыр»[207]

Шулай ук, һәр намазда ахыргы тәшәһһүдне укыганнан соң, аның фетнәсеннән сакланып Аллаһка сыенырга кирәк[208]

89 – «Дөреслектә, мин сине Аллаһ өчен яратам», / Үхиббүкә филләһ/ «أُحِبُّكَ فِي اللَّهِ» — дигән кешегә карата укыла торган дога

١٦٢ – «أَحَبَّكَ الَّذِى أَحْبَبْتَنِى لَهُ»

162 – /Әхәббәкәлләҙи әхбәбтәни ләһү/

162 — «Кем өчен син мине яраттсаң, Ул да сине яратсын!»[209]

207 Мөслим 809

208 Бу китаптагы 36нчы дога

209 Әбү Дауыд 5125

90 – Сиңа үзенең акча-байлыгын тәкъдим итүче кешегә укыла торган дога

١٦٣ – «بَارَكَ اللَّهُ لَكَ فِى أَهْلِكَ وَمَالِكَ»

163 – /БәракәАллаһү ләкә фи әһликә үә мәлик/

163 — «Аллаһ синең гаиләңдә дә, байлыгыңда да бәракәт бирсен!»[210]

91 – Бурычны кайтарганда укыла торган дога

١٦٤ – «بَارَكَ اللَّهُ لَكَ فِى أَهْلِكَ وَمَالِكَ إِنَّمَا جَزَاءُ السَّلَفِ الْحَمْدُ وَالأَدَاءُ»

164 – /БәракәАллаһү ләкә фи әһликә үә мәлик, иннәмә җәзә'үс-сәләфил-хәмдү үәл-әдә'/

164 — «Аллаһ синең гаиләңдә дә, байлыгыңда да бәракәт бирсен! Хакыйкатьтә, бурычка бирүне

210 әл-Бохари 2049

бәяләү — мактау һәм бурычны кайтару беләнˮ[211]

92 – Ширектән курыкканда укыла торган дога

١٦٥ – «اللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ أَنْ أُشْرِكَ بِكَ وَأَنَا أَعْلَمُ وَأَسْتَغْفِرُكَ لِمَا لَا أَعْلَمُ»

165 – /Аллаһүммә инни әгүҙү бикә ән үшрикә бикә үә әнә әгьләм, үә әстәгьфирукә лимә лә әгьләм/

165 — «Әй Аллаһ! Хакыйкатьтә, белә торып Сиңа ширек кылудан Сиңа сыенам, һәм белми торган нәрсәләрдән Синнән гафу үтенәм!»[212]

211 эн-Нэсэи 4683
212 Сахих эл-Җәмигь әс-Сагыйрь 3731

93 – Әгәр дә берәү: «Аллаһ сиңа бәракәт бирсен!» /БәракәАллаһү фик/ «بَارَكَ اللَّهُ فِيكَ» — дисә, ничек җавап бирелә

١٦٦ – «وَفِيكَ بَارَكَ اللَّهُ»

166 – /Үә фикә бәрәкәАллаһ/

166 — «Сиңа да Аллаһ бәракәт бирсен!»[213]

94 – Хорафатларга ышанмауны вә яратмауны белдереп укыла торган дога

١٦٧ – «اللَّهُمَّ لا طَيْرَ إلاَّ طَيْرُكَ، ولا خَيْرَ إلاَّ خَيْرُكَ، وَلاَ إِلَهَ غَيْرُكَ»

167 – /Аллаһүммә лә тайра иллә тайрукь, үә лә хайра иллә хайрукь, үә лә иләһә гайрукь/

167 — «Әй Аллаһ! Синең кошла-

213 Ибен әс-Сүнни

рыңнан башка кош юк, Синең яхшылыгыңнан башка яхшылык юк һәм Синнән башка иләһ юк!»[214]

95 – Машинага, атка яки нәрсәгә булса да утырганда укыла торган дога

١٦٨ – «بِسْمِ اللَّهِ، الْحَمْدُ لِلَّهِ، سُبْحَانَ الَّذِى سَخَّرَ لَنَا هَذَا وَمَا كُنَّا لَهُ مُقْرِنِينَ وَإِنَّا إِلَى رَبِّنَا لَمُنْقَلِبُونَ، الْحَمْدُ لِلَّهِ (ثَلاَثَ مَرَّاتٍ) اللَّهُ أَكْبَرُ (ثَلاَثَ مَرَّاتٍ) سُبْحَانَكَ إِنِّى ظَلَمْتُ نَفْسِى فَاغْفِرْ لِى فَإِنَّهُ لاَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلاَّ أَنْتَ»

168 – /Бисмилләһ, әлхәмдүлилләһ, сүбхәнәлләҙи сәххара ләнә һәҙә үә мә күннә ләһү мукърինин, үә иннә илә раббинә ләмүнкалибүн, әлхәмдүлилләһ, әлхәмдүлилләһ,

214 Әхмәд, ибен әс-Сүнни (Исламга кадәр кошларның очышына карап яхшылыкка яки яманлыкка юрыйлар иде. Безнең чорда кайберәүләр кара мәчегә яки башка нәрсәгә карап юрыйлар, болар һәммәсе дә ярамый торган нәрсәләр)

әлхәмдүлилләһ, Аллаһү әкбәръ, Аллаһү әкбәръ, Аллаһү әкбәръ, сүбхәнәкә инни ҙаләмтү нәфси фәгьфирли фә‘иннәһү лә йәгъфируҙҙүнүбә илло әнт/

168 — «Аллаһ исеме белән. Барча мактау Аллаһка! Безгә моны буйсындырган Аллаһ һәр кимчелектән пакь, без бит үзебез аны булдыра ала торган түгел. Хакыйкатьтә, без Раббыбызга кайтачакбыз![215] Барча мактау Аллаһка! Барча мактау Аллаһка! Барча мактау Аллаһка! Аллаһ бөек! Аллаһ бөек! Аллаһ бөек! Син һәр кимчелектән пакь! Әй Аллаһ! Хакыйкатьтә, мин үземә золым кылдым, мине ярлыка. Хакыйкатьтә, Синнән башка гөнаһларны ярлыкаучы юк!»[216]

215 әз-Зүхруф 13-14
216 Әбү Дауыд 2602

96 – Сәфәр догасы

١٦٩ – «اللَّهُ أَكْبَرُ، اللَّهُ أَكْبَرُ، اللَّهُ أَكْبَرُ، سُبْحَانَ الَّذِى سَخَّرَ لَنَا هَذَا وَمَا كُنَّا لَهُ مُقْرِنِينَ وَإِنَّا إِلَى رَبِّنَا لَمُنْقَلِبُونَ، اللَّهُمَّ إِنَّا نَسْأَلُكَ فِى سَفَرِنَا هَذَا الْبِرَّ وَالتَّقْوَى وَمِنَ الْعَمَلِ مَا تَرْضَى اللَّهُمَّ هَوِّنْ عَلَيْنَا سَفَرَنَا هَذَا وَاطْوِ عَنَّا بُعْدَهُ اللَّهُمَّ أَنْتَ الصَّاحِبُ فِى السَّفَرِ وَالْخَلِيفَةُ فِى الأَهْلِ اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنْ وَعْثَاءِ السَّفَرِ وَكَآبَةِ الْمَنْظَرِ وَسُوءِ الْمُنْقَلَبِ فِى الْمَالِ وَالأَهْلِ»

169 – /Аллаһү әкбәръ, Аллаһү әкбәръ, Аллаһү әкбәръ! Сүбхәнәлләҙи сәххара ләнә һәҙә үә мә күннә ләһү мукъринин, үә иннә илә раббинә ләмүнкалибүн! Аллаһүммә, иннә нәс‘әлүкә фи сәфәринә һәҙәлбирра үәт-тәкъүә үә минәл-гамәли мә тәръда. Аллаһүммә, һәүүин галәйнә сәфәранә һәҙә, үәтуи ганнә бүгдәһ! Аллаһүммә әнтәс-сахибү фис-сәфәр, үәл-халифәтү фил-әһл. Аллаһүммә инни әгүҙү бикә мин

үәгçә‘ис-сәфәр, үә кәәбәтил-мәнҙар, үә сү‘ил-мүнкаләби фил-мәли үәл-әһл/

169 — «Аллаһ бөек! Аллаһ бөек! Аллаһ бөек! Безгә моны буйсындырган Аллаһ һәр кимчелектән пакь, без бит үзебез аны булдыра ала торган түгел. Хакыйкатьтә, без Раббыбызга кайтачакбыз! Әй Аллаһ! Дөреслектә, без Синнән бу сәфәребездә изгелек һәм тәкъвалык, шулай ук Син риза булырлык гамәлләрне үтәүне сорыйбыз! Әй Аллаһ! Бу сәфәребезне безнең өчен җиңеләйт һәм аның ераклыгын безнең өчен кыскарт! Әй Аллаһ! Син бу сәфәрдә юлдаш һәм гаиләнең халифе. Әй Аллаһ! Дөреслектә, мин сәфәрнең авырлыкларыннан, күреп төшенкелеккә китерә торган нәрсәләрдән, мал һәм гаилә белән була ала торган барлык начарлыктан Сиңа сыенам!»

Кайтканда исә ул шушы сүзләргә

түбәндәгене өстәп әйтә:

«آيِبُونَ تَائِبُونَ عَابِدُونَ لِرَبِّنَا حَامِدُونَ»

– ***/Әйибүнә тә‘ибүнә габидүн, лираббинә хәмидүн/***

— «Без кайтабыз, тәүбә итәбез, гыйбадәт кылабыз һәм Раббыбызны мактыйбыз!»[217]

97 – Шәһәргә яки авылга кергәндә укыла торган дога

١٧٠ – «اللَّهُمَّ رَبَّ السَّمَاوَاتِ السَّبْعِ وَمَا أَظْلَلْنَ، وَرَبَّ الأَرَضِينَ السَّبْعِ وَمَا أَقْلَلْنَ، وَرَبَّ الشَّيَاطِينِ وَمَا أَضْلَلْنَ، وَرَبَّ الرِّيَاحِ وَمَا ذَرَيْنَ، أَسْأَلُكَ خَيْرَ هَذِهِ الْقَرْيَةِ، وَخَيْرَ أَهْلِهَا، وَخَيْرَ مَا فِيهَا، وَنَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهَا، وَشَرِّ أَهْلِهَا، وَشَرِّ مَا فِيهَا»

170 – /Аллаһүммә раббәс-сәмәүәтис-сәбги үә мә әҙъләлнә үә раббәл-әрадыйнәс-сәбги үә мә әкъләлнә үә раббәш-шәйәтыйни үә

217 Мөслим 1342

мә әдъләлнә үә раббәр-рияхи үә мә ҙәрайнә. Әс'әлукә хайра һәҙиһил-карьяти үә хайра әһлиһә үә хайра мә фиһә, үә әгүҙү бикә мин шәрриһә үә шәрри әһлиһә үә шәрри мә фиһә/

170 — «Әй Аллаһ! Син, җиде кат күкләрнең һәм алар каплаган нәрсәләрнең Раббысы. Син, җиде кат җирләрнең һәм алар күтәреп торган нәрсәләрнең Раббысы. Син, шәйтаннарның һәм алар адаштырганнарның Раббысы. Син, җилләрнең һәм алар очырткан-туздырган нәрсәләрнең Раббысы. Мин, Синнән бу авылның яхшылыгын, аның яшәүчеләрнең яхшылыгын һәм аның эчендәге яхшылыкны сорыйм. һәм бу авылның яманлыгыннан, аның яшәүчеләренең яманлыгыннан һәм аның эчендәге яманлыктан Сиңа сыенам!»[218]

218 әл-Хәким «әл-Мүстәдрак»

98 – Базарга кергәндә укыла торган дога

١٧١ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ يُحْيِى وَيُمِيتُ وَهُوَ حَىٌّ لاَ يَمُوتُ بِيَدِهِ الْخَيْرُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَىْءٍ قَدِيرٌ»

171 – /Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәху лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмд, йүхйи үә йүмиту үә һүә хййүн лә йәмүт, биядиһил-хайр, үә һүә галә күлли шәй'ин кадир/

171 — «Аллаһтан башка иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк! Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау! Ул терелəндерә вә үлеләндерә һәм Ул даими тере вә үлми, яхшылык Аның кулында һәм Ул бар нәрсәгә кадир!»[219]

219 әт-Тирмизи 3429. Кем базарга кергәндә ошбу доганы укыса, ул кешегә Аллаһ тәгалә бер миллион изгелек яза, һәм аннан бер миллион яманлыкны жуя һәм аңа Җәннәттә йорт булдыра

99 – Менге ат кебек атланып йөри торган хайван абынса укыла торган дога

«بِسْمِ اللّٰهِ» – ١٧٢

172 – /Бисмилләһ/

172 — «Аллаһ исеме белән»[220]

100 – Мөсафирның мөкыймга[221] укый торган догасы

«أَسْتَوْدِعُكَ اللَّهَ الَّذِى لاَ تَضِيعُ وَدَائِعُهُ» – ١٧٣

173 – /ӘстәүдигукәАллаһ, әлләҙи лә тәдыйгу үәдә'игуһ/

173 — «Мин сине Аллаһка тапшырам! Аңарда сакларга тапшырылган нәрсә югалмый»[222]

220 Әбү Дауыд 4982
221 Юлчының өйдә калучыга укый торган догасы
222 Ибен Мәҗәһ 2825

101 – Мөкыймның мөсафирга укый торган догасы

١٧٤ – «أَسْتَوْدِعُ اللَّهَ دِينَكَ وَأَمَانَتَكَ وَخَوَاتِيمَ عَمَلِكَ»

174 – /Әстәүдигуллаһә динәкә үә әмәнәтәкә үә хаүәтимә гамәлик/

174 — «Мин Аллаһка синең динеңне, әманәтеңне һәм эшеңнең ахыр нәтиҗәләрен тапшырам»[223]

١٧٥ – «زَوَّدَكَ اللَّهُ التَّقْوَى وَغَفَرَ ذَنْبَكَ وَيَسَّرَ لَكَ الْخَيْرَ حَيْثُمَا كُنْتَ»

175 – /ЗәүүәдәкәАллаһүт-тәкъүә үә гафәра ҙәнбәк, үә йәссәра ләкәл-хайра хәйҫүмә күнтә/

175 — «Аллаһ синең тәкъвалыгыңны арттырсын, гөнаһыңны ярлыкасын һәм кайда гына булсаң да сиңа изгелекне җиңеләйтсен»[224]

223 Әбү Дауыд 2600
224 әт-Тирмизи 3444

102 – Сәфәрдә тәкбир һәм тәсбих

176 — Җәбир ﷺ әйтте:

— «Без, калкулыкка менгән кебек өскә таба менгәндә: اللهُ أَكْبَرُ / *Аллаһү әкбәръ/* «Аллаһ һәрнәрсәдән бөек», — дип әйтә идек, ә аска таба төшкәндә: سُبْحَانَ اللهِ */СүбхәнәАллаһ/* «Аллаһ барча кимчелектән пакь», — дип әйтә идек»[225]

103 – Мөсафирның таң алдыннан укый торган догасы

١٧٧ – «سَمَّعَ سَامِعٌ بِحَمْدِ اللَّهِ وَحُسْنِ بَلاَئِهِ عَلَيْنَا رَبَّنَا صَاحِبْنَا وَأَفْضِلْ عَلَيْنَا عَائِذًا بِاللَّهِ مِنَ النَّارِ»

177 – /Сәмига (сәммәга) сәмигун бихәмдилләһи үә хүсни бәлә‘иһи

225 әл-Бохари 2993

галәйнә, Раббәнә сахибнә үә әфдыйл галәйнә га‘иҙән билләһи минән-нәр/

177 — «Бу сүзләрне ишетүче һәркем, безнең Аллаһка хәмд-сәнә кылганыбызны һәм безгә Аның сынауы күркәм икәнлеге хакында башкаларга ирештерсен (шәһидлек кылсын). Раббыбыз! Безне ташлама һәм безгә шәфкатьлек кыл! Бу сүзләрне, Аллаһка Уттан сыенып әйтәм!»[226]

104 – Сәфәрдә чакта яки башка вакытта берәр өйдә тукталганда укыла торган дога

١٧٨ – «أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ
التَّامَّاتِ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ»

178 – /Әгүҙү би кәлимәтилләһиттәммәти мин шәрри мә халәкъ/

226 Мөслим 2718

178 — «Аллаһ ﷻ халикъ кылган нәрсәләрнең явызлыгыннан, Аның камил сүзләренә[227] сыенам»[228]

105 – Сәфәрдән кайтканда укыла торган дога

179 — Өенә кайтучы һәрбер калкулыкка менгәндә 3 тапкыр اللهُ أَكْبَرُ / ***Аллаһү әкбәръ/*** «Аллаһ һәрнәрсәдән бөек», — дип, тәкбир әйтә, аннары ошбу доганы укый:

«لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ

227 Кәүния һәм шәрьгыя сүзләр керә. Кәүния, мәсәлән Аллаһ бер нәрсәнең булуын теләсә, Ул аңа бул ди һәм була. Шәрьгыя, мәсәлән ул бәлаказа төшкәнче һәм төшкәннән соң мөмкин; аятел көрсине кич беләп укыган кеше төне буе шәйтаннан саклана - бу бәла төшкәнче Аллаһның аяте белән саклану, чирләгән кеше фәтихә сүрәсе белән дәвалана - бу бәла төшкәннән соң Аның сүзе б[illegible] саклану

228 Мөслим 2708. Әгәр кеше нинди дә булса өйдә тукталса һәм ошбу доганы укыса, бу өйдән киткәнгә кадәр аңа бернәрсә дә зыян китермәс

الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ آيِبُونَ تَائِبُونَ عَابِدُونَ لِرَبِّنَا حَامِدُونَ صَدَقَ اللَّهُ وَعْدَهُ وَنَصَرَ عَبْدَهُ وَهَزَمَ الأَحْزَابَ وَحْدَهُ»

– /Лә иләһә илла Аллаһү үәхдәху лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлку үә ләһүл-хәмду үә һүә галә күлли шәй'ин кадир. Әйибүнә тә'ибүнә габидүн, лираббинә хәмидүн. СадәкАллаһү үәгьдәһү үә нәсара габдәһү үә һәзәмәл-әхзәбә үәхдәһү/

— «Аллаһтан башка һич иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк! Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау, һәм Ул бар нәрсәгә кадир! Без кайтабыз, тәүбә итәбез, гыйбадәт кылабыз һәм Раббыбызны мактыйбыз! Аллаһ Үзенең вәгъдәсен тотты, Үзенең колына ярдәм итте һәм Ул бер Үзе берләшкән төркемнәрне җиңде!»[229]

229 әл-Бохари 1797

106 – Берәр нәрсәгә шатланганда яки берәр нәрсә ошамаганда укыла торган дога

180 — Пәйгамбәребез ﷺ берәр нәрсәгә сөенсә болай дип әйтә иде:

«الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِى بِنِعْمَتِهِ تَتِمُّ الصَّالِحَاتُ»

– ***/Әлхәмдулилләһил-ләҙи бинигь-мәтиһи тәтиммүс-салихәт/***

— «Аллаһка барча мактау! Аның нигъмәте белән изгелекләр эшләнә»

Ә инде пәйгамбәребезгә берәр нәрсә ошамаса, болай дип әйтә торган иде:

«الْحَمْدُ لِلَّهِ عَلَى كُلِّ حَالٍ»

– ***/Әлхәмдулилләһи галә күлли хәл/***

— «Нәрсә генә булса да, Аллаһка барча мактау!»[230]

230 Ибен Мәҗәһ 3803

107 – Пәйгамбәргә ﷺ салават әйтүнең фазыйләте

181 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Миңа бер тапкыр салават кылучыга, Аллаһ аңа ун тапкыр салават кыла»[231]

182 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Минем каберемне бәйрәм урыны итмәгез, ә миңа салават кылыгыз! Хакыйкатьтә, кайда гына булсагыз да сезнең салаватларыгыз миңа ирешә»[232]

183 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Саран шул кеше, аның янында мине искә алып та миңа салават кылмаучы»[233]

184 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Дөреслектә, Аллаһның җирдә сәяхәт кылучы фәрештәләре бар, Алар өммәтемнең сәламнәрен миңа

231 Мөслим 384

232 Әбү Дауыд 2042

233 Тирмизи 3546

җиткерәләр»[234]

185 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Кем дә кем миңа сәлам әйтә икән, һичшиксез, аңа җавап бирер өчен, Аллаһ миңа җанымны кайтарачак»[235]

108 – Сәламләшү

«السَّلاَمُ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَةُ اللَّهِ وَبَرَكَاتُهُ»

– ***/Әссәләмү галәйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ/***

— «Сезгә Аллаһның сәламе, рәхмәте һәм бәракәте булсын!»

186 — Гыймран бин Хусайн ؓ әйтте: «Бер кеше пәйгамбәребез ﷺ янына килде дә: «Әссәләмү галәйкүм!», — диде, һәм пәйгамбәребез ﷺ аның сәламенә җавап бирде, шуннан соң ул утырды, ә пәйгамбәр ﷺ : **«Ун»**, — диде. Аннан соң икенче кеше килде дә: «Әссәләмү галәйкүм

234 ән-Нәсәи 1282
235 Әбү Дауыд 2041

вә рахмәтуллаһ!», — дип әйтте. Пәйгамбәребез ﷺ аның сәламенә җавап бирде, аннан соң ул утырды, ә пәйгамбәр ﷺ : **«Егерме»**, — диде. Аннан соң өченче кеше килде һәм: «Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ!», — дип әйтте, һәм пәйгамбәребез ﷺ аның сәламенә җавап бирде, шуннан соң теге утырды, ә пәйгамбәр ﷺ : **«Утыз»**, — диде»[236]

187 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Иман китермичә сез Җәннәткә керә алмассыз, ә инде бер-берегезне яратканга кадәр иманлы булмассыз. Сезгә бер-берегезне яратуга китерә торган нәрсәне әйтергәме? Бер-берегез белән ешрак сәламләшегез!»[237]

188 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Үзендә 3 сыйфатны булдыручы гына тулы иманлы була: үз-үзенә карата инсафлы булучы, барча

236 Әбү Дауыд 5195
237 Мөслим 54

очраткан кешеләрне дә сәламләүче һәм фәкыйрь чагында малын (садәка итеп) сарыф итүче»[238]

189 — Габдуллаһ бин Гамр ﷺ әйтте: Пәйгамбәребездән ﷺ бер кеше сорады: Исламның иң хәерлесе нинди була? Пәйгамбәр ﷺ аңа болай диде:

— «Кешеләрне ашату һәм белгән кешеңә дә вә белмәгәнгә дә сәлам бирү»[239]

109 – Кәфернең сәламенә ничек җавап бирергә[240]

190 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә сезгә китап әһелләре[241] сәлам бирсә, аларга: «Сезгә дә», — дип җавап бирегез»[242]

238 әл-Бохари 20нче бәб
239 әл-Бохари 12
240 Китап әһеле «әссәләмүгаләйкүм» дисә
241 Яһүдләр һәм нәсаралар
242 әл-Бохари 6258

110 – Әтәч кычкырганда яки ишәк акырганда укыла торган дога

191 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә әтәч кычкырганын ишетсәгез, Аллаһтан шәфкатьлек сорагыз, чөнки, хакыйкатьтә, ул әтәч фәрештәне күрде. Әгәр ишәк акырганын ишетсәгез, шәйтаннан Аллаһка сыеныгыз, чөнки, хакыйкатьтә, ул ишәк шәйтанны күрде»[243]

111 – Төнлә эт өргәндә укыла торган дога

192 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә төнлә эт өргәнен яки ишәк кычкырганын ишетсәгез, алардан Аллаһка сыеныгыз, чөнки, хакыйкатьтә, алар сез күрмәгән

243 әл-Бохари 3303

нәрсәне күрәләр»[244]

112 – Синең тарафтан рәнҗетелгән кешегә карата укыла торган дога

١٩٣ – «اللَّهُمَّ فَأَيُّمَا مُؤْمِنٍ سَبَبْتُهُ فَاجْعَلْ ذَلِكَ لَهُ قُرْبَةً إِلَيْكَ يَوْمَ الْقِيَامَةِ»

193 – /Аллаһүммә фә'әйүмә мү'минин сәбәбтүһү фәҗгал ҙәликә ләһү куръбәтән иләйкә йәүмәл-кыйәмәһ/

193 — «Әй Аллаһ! Мин берәр мөэминне рәнҗеткән булсам, бу рәнҗетүне аның өчен Кыямәт Көнендә Сиңа якынаю сәбәбе ит»[245]

244 Әбү Дауыд 5103
245 әл-Бохари 6361

113 – Бер мөселман икенче мөселманны мактаганда укыла торган дога

194 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә берәрегезгә дустын мактарга туры килсә, болай дип әйтсен:

«أَحْسِبُ فُلاَنًا وَاللَّهُ حَسِيبُهُ وَلاَ أُزَكِّى عَلَى اللَّهِ أَحَدًا»

– */Әхсибү фүләнән үәАллаһү хәсибүһү үә ләә үзәкки галәллаһи әхәдә/*

— «Мин фәлән кешене мондый дип саныйм, Аллаһ аны Үзе хисап кылучы, ләкин мин Аллаһ каршында беркемне дә мактамыйм» чынлап та аны белә торган булса, мин аны шундый-шундый дип саныйм, дип әйтеп уза[246]

246 әл-Бохари 2662

114 – Әгәр мөселманны мактасалар, макталган мөселман укый торган дога

١٩٥ – «اللَّهُمَّ لَا تُؤَاخِذْنِي بِمَا يَقُولُونَ، وَاغْفِرْ لِي مَا لَا يَعْلَمُونَ، وَاجْعَلْنِي خَيْراً مِمَّا يَظُنُّونَ»

195 – /Аллаһүммә лә түʻәхыйҙни бимә йәкулүн, үәгьфир ли мә лә йәгьләмүн, үәҗгални хайран миммә йәҙуннүн/

195 — «Әй Аллаһ! Алар әйткән сүзләр өчен мине җәзалама, алар белмәгән нәрсәләремне миңа ярлыка һәм алар уйлаганнан мине яхшырак кыл»[247]

247 «әл-Әдәб әл-Мүфрад» 761

хәсәнәтән үә фил-әхыйрати хәсәнәтән үә кыйнә газәбән-нәр/

198 — «Әй Раббыбыз! Безгә дөньяда да, ахирәттә дә яхшылык бир һәм безне Ут газабыннан сакла!»[251]

118 – Сафә һәм Мәръвә калкулыкларында басып торганда укыла торган дога

199 — «Пәйгамбәребез ﷺ Сафә калкулыгына якынайгач, ошбу сүзләрне укый иде:

«﴿إِنَّ الصَّفَا وَالْمَرْوَةَ مِنْ شَعَائِرِ اللَّهِ﴾ أَبْدَأُ بِمَا بَدَأَ اللَّهُ بِهِ»

– /۞Иннәс-Сафә үәл-Мәръүәтә мин шәга‘ириллә۞ Әбдә‘ү бимә бәдә‘Аллаһү биһи/

— «۞ Дөреслектә, Сафә һәм Мәръвә Аллаһның шигарьләреннән (бил-

251 әбү Дауыд 1892 (әл-Бәкара 201)

гелəреннəн)۞ [252] Аллаһ нəрсəдəн башлады, мин дə шуннан башлыйм»

Һəм ул ﷺ Сафə калкулыгыннан башлады. Калкулыкка Кəгъбəтуллаһ күренə башлаганчы менде, Кыйблага таба юнəлде, һəм: ***/Лə илəһə иллəАллаһ, Аллаһү əкбəръ/*** «Аллаһтан башка илəһ юк, Аллаһ бөек» — диде, аннары болай дип дəвам итте:

«لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَىْءٍ قَدِيرٌ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ أَنْجَزَ وَعْدَهُ وَنَصَرَ عَبْدَهُ وَهَزَمَ الأَحْزَابَ وَحْدَهُ»

– /Лə илəһə иллə Аллаһү үəхдəхү лə шəрикə лəһ, лəһүл-мүлкү үə лəһүл-хəмдү үə һүə галə күлли шəй'-ин кадир. Лə илəһə иллə Аллаһү үəхдəхү, əнҗəзə үəгьдəһү үə нəсара габдəһү үə һəзəмəл-əхзəбə үəхдəһү/

— «Аллаһтан башка илəһ юк һəм

252 əл-Бəкара 158

Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк! Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау, һәм Ул бар нәрсәгә кадир! Аллаһтан башка иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә! Аллаһ Үзенең вәгъдәсен тотты, Үзенең колына ярдәм итте һәм Ул бер Үзе берләшкән төркемнәрне җиңде!»

Хәдистә риваять ителгәнчә, пәйгамбәребез ﷺ бу сүзләрне 3 тапкыр әйтте һәм аларның арасында дога кылды. «Сафәдә эшләгән кебек үк, Мәрвәдә дә шуларны ук эшләде»[253]

119 – Гарафә көнендә укыла торган дога

200 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Иң яхшы дога, Гарафә көнендә укыла торган дога. Ә мин һәм миңа кадәр булган пәйгамбәрләр әйткән сүзләрдән иң яхшылары, ошбу сүз-

253 Мөслим 1218

ләр булып тора:

«لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَىْءٍ قَدِيرٌ»

– /Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәху лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмдү үә һүә галә күлли шәй‘ин кадир/

— «Аллаһтан башка һич иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк! Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау, һәм Ул бар нәрсәгә кадир!»[254]

120 – «әл-Мәшгар әл-Хәрам»[255] дигән урында укыла торган зикер-догалар

201 — Пәйгамбәребез ﷺ «әл-Касъ-үә‘» исемле дөясенә утырып «әл-

254 әт-Тирмизи 3585

255 Бу урынга Мухассар үзәнлегеннән башка, барча Мөздәлифә үзәнлеге керә

Мәшгар әл-Хәрам» урынына җиткәч Кыйблага таба юнәлеп Аллаһка дога кылды, **«Аллаһү әкбәръ»** – дип тәкбир әйтте, **«Лә иләһә иллә Аллаһ»** – дип тәһлил әйтте һәм **«Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәху лә шәрикә ләһү»** – дип Аның берлеген белдерде. Пәйгамбәр ﷺ шушылай яктырганчы эшләде, аннары кояш чыкканчы Минага таба юнәлде»[256]

121 – Баганага таш атканда, һәрбер таш белән тәкбир әйтү

202 — Пәйгамбәребез ﷺ һәр 3 баганага таш атканда, һәрбер таш ату белән **«Аллаһү әкбәръ»** – дип тәкбир әйтә иде. Беренче һәм икенче баганаларга таш атканнан соң, ул бераз алга китеп, туктап, Кыйбла тарафына юнәлеп, кулларын

256 Мөслим 1218

күтәреп дога кыла иде. Ә өченче баганага таш атканда, ул шулай ук һәр таш аткан саен тәкбир әйтә иде һәм аның янында туктап тормыйча китеп бара иде[257]

122 – Гаҗәпләнгәндә яки шатланганда әйтелә торган сүзләр

٢٠٣ – «سُبْحَانَ اللَّهِ»

203 – /СүбхәнәАллаһ/

203 — «Аллаһ һәр кимчелектән пакь»[258]

٢٠٤ – «اللَّهُ أَكْبَرُ»

204 – /Аллаһү әкбәръ/

204 — «Аллаһ бөек»[259]

257 әл-Бохари, Мөслим
258 әл-Бохари, Мөслим
259 әл-Бохари

123 – Шатлык килгәндә нәрсә эшләргә

205 — «Әгәр дә пәйгамбәребезне ﷺ сөендерә торган хәл булса, ул Аллаһ тәбәракә вә тәгаләгә шөкер итеп сәҗдәгә китә иде»[260]

124 – Тәнендә авырту сизгән кеше укый торган дога

206 — Кулыңны тәнеңнең авырткан урынына куй да, өч тапкыр:

«بِسْمِ اللَّهِ»

– /Бисмилләһ/

— «Аллаһ исеме белән», — дип әйт, аннары 7 тапкыр:

«أَعُوذُ بِاللَّهِ وَقُدْرَتِهِ مِنْ شَرِّ مَا أَجِدُ وَأُحَاذِرُ»

– /Әгүҙү билләһи үә кудратиһи мин шәрри мә әҗидү үә ухәҙиру/

260 Ибен Мәҗәһ 1394

— «Мин сизгән һәм курыккан яманлыклардан Аллаһка вә Аның кодрәтенә сыенам», — диген[261]

125 – Үз күзең тиюдән курыкканда укыла торган дога

207 — «Әгәр берәрегез үзендә яки малында яки кардәшендә аны гаҗәпләндерерлек нәрсә күрсә, аңа бәракәт иңүен сорасын, чөнки күз тию – хак (дөрес)»[262]

Мәсәлән: ***/БәракәАллаһ/*** «Аллаһ бәракәт бирсен», — дисен

126 – Курыкканда әйтелә торган сүз

٢٠٨ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ»

261 Мөслим 2202

262 Сахих әл-Җәмигъ әс-Сагыйрь 556

208 – /Лә иләһә иллә Аллаһ/

208 — «Аллаһтан башка иләһ юк»[263]

127 – Мал суйганда нәрсә әйтелә

٢٠٩ – «بِسْمِ اللَّهِ وَاللَّهُ أَكْبَرُ [اللهُمَّ مِنْكَ وَلَكَ]
اللَّهُمَّ تَقَبَّلْ مِنِّي»

209 – /Бисмилләһи үәАллаһү әкбәръ [Аллаһүммә минкә үә ләкә] Аллаһүммә тәкаббәл минни/

209 — «Аллаһ исеме белән һәм Аллаһ бөек (Әй Аллаһ! Синнән һәм Сиңа) Әй Аллаһ! Миннән кабул ит!»[264]

128 – Шәйтаннарның мәкерләреннән саклану өчен укыла торган дога

٢١٠ – «أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّامَّاتِ الَّتِى لاَ

263 әл-Бохари 3346

264 әл-Бохари 5558, Мөслим, җәя эчендәгеләр әл-Бәйһәкыйныкы

يُجَاوِزُهُنَّ بَرٌّ وَلاَ فَاجِرٌ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ وَذَرَأَ وَبَرَأَ
وَمِنْ شَرِّ مَا يَنْزِلُ مِنَ السَّمَاءِ وَمِنْ شَرِّ مَا يَعْرُجُ
فِيهَا وَمِنْ شَرِّ مَا ذَرَأَ فِى الأَرْضِ وَمِنْ شَرِّ مَا
يَخْرُجُ مِنْهَا وَمِنْ شَرِّ فِتَنِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ وَمِنْ شَرِّ
كُلِّ طَارِقٍ إِلاَّ طَارِقاً يَطْرُقُ بِخَيْرٍ يَا رَحْمَنُ»

210 – /Әгүҙү би кәлимәтил-ләһит-тәммәти әлләти лә йүҗәүизүһүннә бәррун үә лә фәҗирун мин шәрри мә халәка үә ҙәра‘ә үә бәра‘ә үә мин шәрри мә йәнзилү минәс-сәмә‘и үә мин шәрри мә йәгьруҗү фиһә үә мин шәрри мә ҙәра‘ә фил-әръдый үә мин шәрри мә йәхруҗү минһә үә мин шәрри фитәнил-ләйли үән-нәһәри үә мин шәрри күлли тарикыйн иллә тарикан йәтъруку бихайрин йә Рахмән/

210 — «Аллаһ халикъ кылган, булдырган һәм бар иткән нәрсәләрнең явызлыгыннан, күктән төшкән явызлыктан вә анда менә торган явызлыктан, Ул җирдә булдырган явызлыктан вә аннан чыга торган

явызлыктан, төннең вә көннең фетнәсеннән һәм яхшылык белән килүчедән башка – әй Рахмән, һәр-бер төнлә килүченең явызлыгын-нан, Аллаһның камил сүзләренә сыенам. Ул сүзләрдән игелекле дә бозык та өстен була алмый!»[265]

129 – Истигъфар[266] һәм тәүбә

211 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Аллаһ белән ант итәм! Дөреслектә, мин көненә Аллаһка 70 тапкырдан артык истигъфар кылам һәм тәүбә итәм!»[267]

212 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әй кешеләр! Аллаһка тәүбә итегез! Дөреслектә, мин Аңа көненә 100 тапкыр тәүбә кылам!»[268]

265 «Мүснәд» Әхмәд
266 Гафу сорау, ярлыкау эстәү
267 әл-Бохари 6307
268 Мөслим 2702

213 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Кем дә кем:

«أَسْتَغْفِرُ اللَّهَ الَّذِى لاَ إِلَهَ إِلاَّ هُوَ
الْحَىُّ الْقَيُّومُ وَأَتُوبُ إِلَيْهِ»

– */Әстәгьфируллаһәлләҙи лә иләһә иллә һүәл-хәййүл-каййүмү үә әтүбү иләйһи/*

— «Аннан башка иләһ булмаган Тере, Барлап торучы Аллаһтан ярлыкау сорыйм һәм Аңа тәүбә кылам!»

— дип әйтсә, ул кеше сугыш мәйданыннан һөҗүм вакытында качса да, аның гөнаһлары кичерелер»[269]

214 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Раббының колга булган иң якын вакыты – төннең ахырында. Әгәр дә син шушы вакытта Аллаһны зикер кылучылардан була алсаң

269 Әбү Дауыд 1517

— бул!»[270]

215 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:
— «Колның Раббысына булган иң якын вакыты – ул, Аңа сәҗдәдә вакытта. Шундый вакытта күбрәк дога кылыгыз!»[271]

216 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:
— «Дөреслектә, кайвакыт минем йөрәгем каплана (гафилләнә)[272]. Һәм дөреслектә, мин көненә Аллаһтан 100 тапкыр ярлыкау сорыйм!»[273]

270 әт-Тирмизи 3579
271 Мөслим 482
272 Гадәттә расүлебез ﷺ даимән Аллаһны зикер иткән, дога кылган һәм башка изгелекләр белән шөгыльләнгән. Әгәр дә аны бу эшләрдән башка нәрсә бүлдерсә-аерса, ул гөнаһ кылдым дип уйлап, моның өчен ярлыкау сорый торган иде. Шулай итеп, «йөрәгем каплана (гафилләнә)» дигәннең мәгънәсе, пәйгамбәребезнең башка эшләр белән мәшгуль булып, зикердән читләшкән кайбер кыска вакытлары күздә тотыла. Аллаһү әгъләм
273 Мөслим 2702

130 – Тәсбих, тәхмид, тәһлил һәм тәкбир әйтүләрнең фазыйләте

217 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Кем дә кем көндә 100 тапкыр:

«سُبْحَانَ اللَّهِ وَبِحَمْدِهِ»

– */СүбхәнАллаһи үә бихәмдиһ/*

— «Аллаһ һәр кимчелектән пакь һәм Аңа барча мактау»

— дип әйтсә, аның гөнаһлары диңгездәге күбек кебек булса да гафу ителер»[274]

218 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Кем дә кем 10 тапкыр:

«لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ، وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ، وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ»

– /Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәһү лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-

274 әл-Бохари 6405

хәмдү үә һүә галә күлли шәй'ин кадир/

— «Аллаһтан башка һич иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау һәм Ул бар нәрсәгә кодрәтле»

— дип әйтсә, Исмәгыйл нәселеннән 4 кешене коллыктан азат иткән кебек була»[275]

219 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Телгә әйтергә җиңел булган, мизанда авыр булган һәм Рахмәнгә сөекле булган ике сүз бар:

«سُبْحَانَ اللهِ وَبِحَمْدِهِ، سُبْحَانَ اللهِ العظيمِ»

– /СүбхәнАллаһи үә бихәмдиһи, сүбхәнАллаһил-газыйм/

— «Аллаһ һәр кимчелектән пакь һәм Аңа барча мактау, Бөек Аллаһ һәр кимчелектән пакь»[276]

275 әл-Бохари 6404
276 әл-Бохари 6406

220 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Дөреслектә, миңа:

«سُبْحَانَ اللَّهِ، وَالْحَمْدُ لِلَّهِ، وَلَا إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ، وَاللَّهُ أَكْبَرُ»

– /СүбхәнАллаһи, үәл-хәмдү лилләһи, үә лә иләһә иллә Аллаһү, үә Аллаһү әкбәръ/

— «Аллаһ һәр кимчелектән пакь, Аллаһка барча мактау, Аллаһтан башка иләһ юк һәм Аллаһ бөек»

— дип әйтү, кояш чыккан нәрсәдән дә (ягъни, бу дөньядан да) сөйкемлерәк»[277]

221 — Пәйгамбәребез ﷺ :

— «Сезнең берәрегез көндә 1000 изгелек эшли аламы?», — дип сорады.

Анда утыручыларның берсе: «Ничек инде безнең берәребез 1000 изгелек эшли алсын?, — диде.

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «100 тапкыр тәсбих әйтсен, һәм

277 Мөслим 2695

моның өчен аңа 1000 изгелек языла вә 1000 хатасы ярлыканыр!»[278]

222 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Кем дә кем:

«سُبْحَانَ اللهِ العظيمِ وَبِحَمْدِهِ»

– ***/СүбхәнАллаһил-гаҗыйми үә бихәмдиһи/***

— «Бөек Аллаһ һәр кимчелектән пакь һәм Аңа барча мактау!»

— дип әйтсә, аңа Җәннәттә бер хөрмә агачы утыртылыр»[279]

223 — Пәйгамбәребез ﷺ:

— «Әй Габдуллаһ бин Кайс! Сиңа Җәннәт хәзинәләренең берсенә күрсәтимме?», — диде.

Мин: «Әлбәттә, әй Аллаһның расүле», — дидем.

Пәйгамбәр ﷺ әйтте:

— «Син болай дип әйт:

278 Мөслим 2698

279 әт-Тирмизи 3464, 3465

«لاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللَّهِ»

– /Лә хәүлә үә лә куүәтә иллә билләһ/

— «Аллаһтан башка берәүдән дә көч-куәт юк»[280]

224 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Аллаһка иң сөйкемле сүзләр дүртәүдер:

«سُبْحَانَ اللَّهِ، وَالْحَمْدُ لِلَّهِ، وَلاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ، وَاللَّهُ أَكْبَرُ»

– /СүбхәнАллаһи, үәл-хәмдү лилләһи, үә лә иләһә иллә Аллаһү, үә Аллаһү әкбәръ/

— «Аллаһ һәр кимчелектән пакь, Аллаһка барча мактау, Аллаһтан башка иләһ юк һәм Аллаһ бөек»

һәм кайсысыннан башласаң да, сиңа зарар итмәс»[281]

280 әл-Бохари 6409

281 Мөслим 2137

225 — Бервакыт Аллаһның илчесе ﷺ янына бер бәдәви килде дә: «Миңа, мин кабатлап әйтеп йөри ала торган сүзләрне өйрәт», — диде.

Пәйгамбәребез ﷺ аңа:

— «Син болай дип әйт:

«لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ اللَّهُ أَكْبَرُ كَبِيرًا وَالْحَمْدُ لِلَّهِ كَثِيرًا سُبْحَانَ اللَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ لاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللَّهِ الْعَزِيزِ الْحَكِيمِ»

– /Лә иләһә илләә Аллаһү үәхдәһү лә шәрикә ләһү, Аллаһү әкбәру кәбиран үәлхәмдүлилләһи кәҫиран сүбхәнАллаһи Раббил-галәминә лә хәүлә үә лә куүәтә илләә билләһил-газизил-хәким/

— «Аллаһтан башка иләһ юк, Аның тиңдәше юк. Аллаһ барча нәрсәдән дә күпкә Бөек. Аллаһка күп мактау. Галәмнәр Раббысы Аллаһ – барча кимчелектән пакь. әл-Газиз, әл-Хәким булган Аллаһтан башка берәүдән дә көч-куәт юк»

Бәдәви: «Бу минем Раббым өчен, ә миңа нәрсә соң?», — диде.

Пәйгамбәребез ﷺ аңа:

— «Син болай дип әйт», — диде:

«اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِي وَارْحَمْنِي وَاهْدِنِي وَارْزُقْنِي»

– /Аллаһүммәгьфирли үәръхәмни үәһдини үәръзүкъни/

— «Әй Аллаһ! Мине ярлыка, миңа рәхимле бул, мине һидәяткә күндер һәм мине ризыкландыр!»[282]

226 — Әгәр дә берәрсе Исламны кабул итсә, пәйгамбәребез ﷺ аны намазга өйрәтә иде, аннары ошбу сүзләр белән дога кылырга куша иде:

«اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِي وَارْحَمْنِي
وَاهْدِنِي وَعَافِنِي وَارْزُقْنِي»

– /Аллаһүммәгьфирли үәръхәмни үәһдини үә гафини үәръзүкъни/

282 Мөслим 2696

— «Әй Аллаһ! Мине ярлыка, миңа рәхимле бул, мине һидәяткә күндер, мине сәламәт-имин кыл һәм мине ризыкландыр!»[283]

227 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:
— «Дөреслектә, иң яхшы дога:

«اَلْحَمْدُ لِلَّهِ»

– ***/Әлхәмдулилләһ/***
— «Барча мактау Аллаһка!»
— «Иң яхшы зикер:

«لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ»

– ***/Лә иләһә иллә Аллаһ/***
— «Аллаһтан башка иләһ юк!»[284]

228 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:
— «Савабы калучы изге гамәлләргә ошбу керә:

283 Мөслим 2697
284 әт-Тирмизи, ибен Мәҗәһ

«سُبْحَانَ اللَّهِ، وَالْحَمْدُ لِلَّهِ، وَلاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ، وَاللَّهُ أَكْبَرُ وَلاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللَّهِ»

– /СүбхәнАллаһи, үәл-хәмдү лилләһи, үә лә иләһә иллә Аллаһү, үә Аллаһү әкбәру үә лә хәүлә үә лә куүәтә иллә билләһ/

— «Аллаһ һәр кимчелектән пакь, Аллаһка барча мактау, Аллаһтан башка иләһ юк, Аллаһ бөек һәм Аллаһтан башка берәүдән дә көч-куәт юк!»[285]

131 – Пәйгамбәребез ﷺ ничек тәсбих кыла иде

229 — Габдуллаһ бин Гамр ؓ әйтте:

— «Мин пәйгамбәребезне ﷺ тәсбих әйткәндә, аны уң кулы белән санап барганын күрдем»[286]

285 Әхмәд
286 Әбү Дауыд 1502

132 – Изгелекләр һәм гомуми әдәп төрләре

230 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә кич җитсә, балаларыгызны урамга чыгармыйча үзегезнең яныгызда тотыгыз, чөнки, хакыйкатьтә, бу вакытта шәйтаннар тарала. Ә инде күпмедер вакыт узгач, балаларыгызны яныгыздан җибәрегез һәм «Бисмилләһ» әйтеп ишекләрегезне ябыгыз, хакыйкатьтә, ябылган ишекләрне шәйтан ача алмый. «Бисмилләһ» әйтеп турсыкларыгызны[287] бәйләгез, «Бисмилләһ» әйтеп савыт-сабаларыгызны каплагыз, капларга бернәрсә дә булмаса, өстенә аркылы берәр нәрсә куегыз һәм кәндилләрегезне[288] сүндерегез!»[289]

287 Саба (су, сөт яки кымыз кебек эчемлекләр өчен тире яки күннән тар авызлы кечкенә капчыкка охшатып эшләнгән савыт, урысча «бурдюк» диелә)
288 Берничә шәм куела торган шәмдәл
289 әл-Бохари 3280

Коръән һәм Сөннәт буенча

ӨШКЕРҮ ТӘРТИБЕ

сихердән
күз тиюдән
җен кагылудан

بسم الله الرحمن الرحيم

1 — Сихердән дәвалану

Сихердән дәвалану икегә бүленә:

Беренчесе: ***Сихер ирешкәнче аннан саклану:***

1 – Аллаһ кушкан барча фарызларны үтәү, хәрамнардан читләшү һәм барча гөнаһлардан тәүбә кылу.

2 – Коръән Кәримне еш уку тиешле, хәтта көндәлек күпмедер өлешен укуны максат итеп кую кирәк.

3 – Догалар, Аллаһка ялварулар һәм пәйгамбәребездән ﷺ билгеле булган зикерләр белән саклану кирәк. Мәсәлән, иртә вә кичен өчәр тапкыр ошбу доганы әйтү:

«بِسْمِ اللَّهِ الَّذِى لاَ يَضُرُّ مَعَ اسْمِهِ شَىْءٌ فِى الأَرْضِ وَلاَ فِى السَّمَاءِ وَهُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ»

— ***/Бисмилләһилләзи лә йәдурру мәгәсмиһи шәй‘үн фил-әръдый үә лә***

фис-сәмә‘, үә һүәс-сәмигуль-галим/

— «Аллаһ исеме белән. Аның исеме белән җирдә дә һәм күктә дә һичнәрсә зыян китерә алмый, һәм Ул — Ишетүче, Белүче»[290]

Һәрбер намаздан соң, йоклар алдыннан, иртән һәм кичен «аять әл-Көрси»не[291] уку; «әл-Ихлас», «әл-Фәлакъ» һәм «ән-Нәс»[292] сүрәләрен иртән, кич һәм йоклар алдыннан өчәр тапкыр уку; көндә 100 тапкыр

«لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ، وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ، وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَىْءٍ قَدِيرٌ»

— /Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәһү лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмдү үә һүә галә күлли шәй‘ин кадир/

— «Аллаһтан башка һич иләһ юк

290 Әбү Дауыд 5088. Кем бу сүзләрне иртән һәм кичтән өчәр тапкыр әйтсә, аңа һичнәрсә дә зыян итә алмый

291 46нчы биттә килә

292 Бу сүрәләр 44-45нче битләрдә киләләр

һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау һәм Ул бар нәрсәгә кодрәтле», — дип әйтү[293]

Иртә вә кич, намаздан соң, йоклар алдыннан, йокыдан торгач, йортка кергәндә вә чыкканда, машинага-атка яки нәрсәгә булса да утырганда, мәчеткә кергәндә вә чыкканда, бәдрәфкә кергәндә-чыкканда, бәла-каза ирешкән кешене күргәндә һәм башка вакытларда аерым зикерләр әйтелә. Болар һәммәсе дә вакытына, урынына вә хәләтенә карап алдагы догалар китабында искә алынды.

Шик юк, Аллаһның теләге белән, зикер кылуга тиешле игътибар бирү сихер ирешүдән, күз тиюдән һәм

293 әл-Бохари 3293. Кем бу сүзләрне көненә йөз тапкыр әйтсә, ул 10 кол азат иткәнгә тиң була, янә аңа 100 изгелек языла һәм 100 явызлыгы җуела, янә бу сүзләр аңа көне буена кичкә кадәр шәйтаннан саклану чарасы була, һәм беркем дә моннан яхшыракны эшли алмый, иллә-мәгәр аннан арттырып әйтсә генә

җеннәрдән саклануга сәбәп булып тора. Шулай ук, мондый афәтләр һәм башка бәла-казалар кешегә ирешкәннән соң да, аларны дәвалауда зикер-догалар иң зур сәбәпләрдән санала.

4 – Мөмкинчелек булса, иртә белән ач карынга 7 гаҗүә хөрмәсе ашау. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

«مَنْ اصْطَبَحَ بِسَبْعِ تَمَرَاتٍ عَجْوَةً لَمْ يَضُرَّهُ ذَلِكَ الْيَوْمِ سُمٌّ وَلَا سِحْرٌ»

Мәгънәсе: ***«Кем дә кем иртә белән 7 гаҗүә хөрмәсе ашаса, аңа бу көнне агу да, сихер дә зыян китерә алмый»***[294]

Мөслим җыентыгында искә алынганча, бигрәк тә Мәдинәнең көнчыгыш һәм көнбатыш «хәрра» җирләре арасында үскәннәре хәерлерәк. Шәйх ибен Бәәз әйтүенчә, Мәдинә шәһәренең барча хөрмәләре дә дәвалый торган бу сыйфатны үзенә

294 әл-Бохари 5445, Мөслим 2047

ала, чөнки пәйгамбәребез ﷺ болай диде:

«مَنْ أَكَلَ سَبْعَ تَمَرَاتٍ مِمَّا بَيْنَ لاَبَتَيْهَا حِينَ يُصْبِحُ...»

Мәгънәсе: ***«Кем дә кем иртә белән Мәдинәнең лава басулары арасында үскән 7 хөрмәне ашаса...»***[295]

Шулай ук, шәйх ибен Бәәз уйлавынча, Мәдинә шәһәреннән башка урында үскән 7 хөрмә ашаучыга да шушындый ук саклану чарасы булыр дип өметле, диде.

Икенчесе: ***Сихер ирешкәннән соң дәвалану:***

1 – Урыны беленсә, сихердә кулланылган нәрсәләрне табып шәригать күрсәткәнчә юкка чыгару. Бу, сихерләнгән кешенең дәвалануында иң нәтиҗәле сәбәп.

295 Мөслим 2047

2 – Шәригать буенча өшкерү ысуллары, һәм алар түбәндәгечә:

А) Яшел сидрның[296] җиде яфрагын алып таш белән яки башка шундый нәрсә белән вакларга, аннары аларны гөсел коенырга җитәрлек су белән бутарга, һәм ошбуларны укырга:

«أَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ»

– ***/Әгүҙү билләһи минәш-шәйтан-ир-раҗим/***

— «Ләгънәт кылынган шәйтаннан Аллаһка сыенам»

«اللَّهُ لَا إِلَهَ إِلَّا هُوَ الْحَيُّ الْقَيُّومُ لَا تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلَا نَوْمٌ لَهُ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ مَنْ ذَا الَّذِي يَشْفَعُ عِنْدَهُ إِلَّا بِإِذْنِهِ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ أَيْدِيهِمْ وَمَا خَلْفَهُمْ وَلَا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلَّا بِمَا شَاءَ وَسِعَ كُرْسِيُّهُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ وَلَا يَئُودُهُ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ»

296 Урысча лотос (лотус) яки кыргый ююба

– /Аллаһү лә иләһә иллә һүәл-хәййүл-каййүм, лә тә‘хузүһү синәтү-үә лә нәүүм, ләһү мә фис-сәмәүәти үә мә фил-әръд, мәң-зәлләзи йәшфәгү гыйңдәһү иллә би‘изниһ, йәгьләмү мә бәйнә әйдиһим үә мә халфәһүм, үә лә йүхитунә бишәй‘им-мин гыйлмиһи иллә бимә шәә‘, үәсига күрсийүһүс-сәмәүәти үәл-әръд, үә лә йә‘үдүһү хифзуһүмә үә һүәл-гаделийүл-газыйм/

Мәгънәсе: **«Аллаһ - Аннан башка иләһ юк. Ул - мәңге Тере, Ул - яшәешне Барлап торучы. Ул беркайчан йокымсырап черем итмәс. Ул беркайчан йокыга китмәс. Күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә Аныкы. Кем Аның каршысында, Аның рөхсәтеннән башка шәфәгать кыла алыр икән? Ул һәрнәрсәнең үткәнен дә, киләчәген дә белә. Тик алар гына, Аның гыйлеменнән, Ул Үзе теләп аларга белгерткән нәрсәдән башканы белмиләр, чолгап ала алмыйлар. Аның көрсие**

күкләрне һәм җирне үз эченә ала. Аларны саклау Аның өчен бер дә авырлык китерми. Ул - барнәрсәдән дә Биек һәм Бөек»[297]

«وَأَوْحَيْنَا إِلَى مُوسَى أَنْ أَلْقِ عَصَاكَ فَإِذَا هِيَ تَلْقَفُ مَا يَأْفِكُونَ * فَوَقَعَ الْحَقُّ وَبَطَلَ مَا كَانُوا يَعْمَلُونَ * فَغُلِبُوا هُنَالِكَ وَانْقَلَبُوا صَاغِرِينَ * وَأُلْقِيَ السَّحَرَةُ سَاجِدِينَ * قَالُوا آمَنَّا بِرَبِّ الْعَالَمِينَ * رَبِّ مُوسَى وَهَارُونَ»

Мәгънәсе: «Без Мусага: «Таягыңны җиргә ташла», — дип вәхий кылдык, Муса таягын ташлады исә, зур елан булып сихерчеләрнең елан булып күренгән таяк вә арканнарын йотып бетерде. Хаклык өскә чыгып аларның сихергә таянып эшләгән ялган эшләре батыл булды - юкка чыкты. Шул урында сихерчеләр җиңелделәр вә хур булып кайттылар. Сихерчеләр (Мусаның могҗизасын күргәч, иман китерделәр һәм Аллаһка) сәҗдәгә

297 «әл-Бәкара» 255

егылдылар. Әйттеләр: «Бөтен галәмнәрнең Раббысына иман китердек. Ул — Муса вә Һарунның Раббысы»[298]

«وَقَالَ فِرْعَوْنُ ائْتُونِي بِكُلِّ سَاحِرٍ عَلِيمٍ * فَلَمَّا جَاءَ السَّحَرَةُ قَالَ لَهُمْ مُوسَى أَلْقُوا مَا أَنْتُمْ مُلْقُونَ * فَلَمَّا أَلْقَوْا قَالَ مُوسَى مَا جِئْتُمْ بِهِ السِّحْرُ إِنَّ اللَّهَ سَيُبْطِلُهُ إِنَّ اللَّهَ لَا يُصْلِحُ عَمَلَ الْمُفْسِدِينَ * وَيُحِقُّ اللَّهُ الْحَقَّ بِكَلِمَاتِهِ وَلَوْ كَرِهَ الْمُجْرِمُونَ»

Мәгънәсе: **«Фиргавен үзенең ярдәмчеләренә: «Барча оста сихерчеләрне җыеп миңа китерегез», - диде. Сихерчеләр бар да җыелып килгәч, Муса аларга әйтте: «Сихерләп китергән нәрсәләрегезне җиргә салыгыз!». Сихерчеләр (сихерләгән бауларын) җиргә салгач, Муса әйтте: «Сезнең бу нәрсәләрегез бар да сихер. Әлбәттә, Аллаһ сезнең сихерегезне батыл кылыр, тәхкыйк Аллаһ бозыклык кылучыларның эшен ислах-төзек кылмас!». Аллаһ Үзенең сүзе белән хак**

298 «әл-Әгъраф» 117-122

эшнең хаклыгын дөресләр, гәрчә кәферләр мәкрүһ күрсәләр дә»[299]

«قَالُوا يَا مُوسَىٰ إِمَّا أَنْ تُلْقِيَ وَإِمَّا أَنْ نَكُونَ أَوَّلَ مَنْ أَلْقَىٰ * قَالَ بَلْ أَلْقُوا فَإِذَا حِبَالُهُمْ وَعِصِيُّهُمْ يُخَيَّلُ إِلَيْهِ مِنْ سِحْرِهِمْ أَنَّهَا تَسْعَىٰ * فَأَوْجَسَ فِي نَفْسِهِ خِيفَةً مُوسَىٰ * قُلْنَا لَا تَخَفْ إِنَّكَ أَنْتَ الْأَعْلَىٰ * وَأَلْقِ مَا فِي يَمِينِكَ تَلْقَفْ مَا صَنَعُوا إِنَّمَا صَنَعُوا كَيْدُ سَاحِرٍ وَلَا يُفْلِحُ السَّاحِرُ حَيْثُ أَتَىٰ * فَأُلْقِيَ السَّحَرَةُ سُجَّدًا قَالُوا آمَنَّا بِرَبِّ هَارُونَ وَمُوسَىٰ»

Мәгънәсе: **«Сихерчеләр: «Әй, Муса син әүвәл ташлыйсыңмы таягыңны яки әүвәл без ташлыйкмы?», — диделәр. Муса әйтте: «Бәлки сез әүвәл ташлагыз!». Сихерчеләр бауларын вә таякларын җиргә салгач, аларның сихерләреннән бу нәрсәләр Мусага тиз йөрүче (тере еланнар) булып күренде. Муса шул вакытта күңелендә курку тойды. Әйттек: «Әй, Муса, курыкма!**

299 «Йунус» 79-82

Син алардан өстенсең-җиңерсең. Уң кулыңдагы (таягыңны) җиргә ташла, аларның эшләгән нәрсәләрен (сихер белән елан итеп күрсәткән бауларын вә таякларын) ялт итеп йотар. Аларның ясаган нәрсәләре фәкать сихерченең хәйләседер, ә сихерче берничек тә уңышка ирешмәс». (Мусаның таягы сихерчеләрнең бөтен нәрсәләрен ашап бетергәч), сихерчеләр (иман китерделәр вә тәүбә итеп) сәҗдәгә егылдылар һәм: «Һарун белән Мусаның Раббысына иман китердек», — диделәр»[300]

بسم الله الرحمن الرحيم

«قُلْ يَا أَيُّهَا الْكَافِرُونَ * لَا أَعْبُدُ مَا تَعْبُدُونَ * وَلَا
أَنْتُمْ عَابِدُونَ مَا أَعْبُدُ * وَلَا أَنَا عَابِدٌ مَا عَبَدْتُمْ *
وَلَا أَنْتُمْ عَابِدُونَ مَا أَعْبُدُ * لَكُمْ دِينُكُمْ وَلِيَ دِينِ»

Мәгънәсе: «Әйт: Әй кәферләр! Сез гыйбадәт кыла торган нәрсәләргә мин гыйбадәт кылмыйммын. Һәм сез дә мин гыйбадәт кыла торган Аллһка

300 «Таһә» 65-70

гыйбадәт кылмыйсыз. Мин сезнең гыйбадәт кыла торган нәрсәләргә гыйбадәт кылучы түгелмен. Һәм сез мин гыйбадәт кыла торган Аллаһка гыйбадәт кылучы түгелсез. Сезнең үзегезнең (ялган) динегез, вә минем үземнем (хак) динем!»[301]

بسم الله الرحمن الرحيم

«قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ * اللَّهُ الصَّمَدُ * لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ * وَلَمْ يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ»

Мәгънәсе: **«Әйт: Аллаһ - Бер. Аллаһ - Омтылылган Хуҗа, Мәңге. Ул тудырмады һәм тудырылмады һәм һичкем Аңа тиң булмады»[302]**

بسم الله الرحمن الرحيم

«قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ وَمِنْ شَرِّ غَاسِقٍ إِذَا وَقَبَ وَمِنْ شَرِّ النَّفَّاثَاتِ فِي الْعُقَدِ وَمِنْ شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ»

301 «әл-Кәфирун» сүрәсе
302 «әл-Ихлас» сүрәсе

Мәгънәсе: «**Әйт: Мин таңның Раббысына сыенам; Ул халикъ кылган барча нәрсәнең явызлыгыннан, караңгылыгы белән каплаган төннең явызлыгыннан, сихер-ырым төеннәренә өрүче хатыннарның явызлыгыннан һәм хөседле кешеләрнең хөсед явызлыгыннан**»[303]

بسم الله الرحمن الرحيم

«قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ النَّاسِ مَلِكِ النَّاسِ إِلَهِ النَّاسِ مِنْ شَرِّ الْوَسْوَاسِ الْخَنَّاسِ الَّذِي يُوَسْوِسُ فِي صُدُورِ النَّاسِ مِنَ الْجِنَّةِ وَالنَّاسِ»

Мәгънәсе: «**Әйт: Мин — кешеләрнең күңелләренә вәсвәсә салучы җеннәрдән һәм кешеләрдән булган, Аллаһны зикер иткәндә юкка чыгучы шәйтанның вәсвәсәсеннән — кешеләрнең Раббысына, кешеләрнең Патшасына, кешеләрнең Илаһенә сыенам**»[304]

Өстә искә алынган аятьләрне вә

303 «әл-Фәлакъ» сүрәсе

304 «ән-Нәс» сүрәсе

сүрәләрне суга укыганнан соң, 3 тапкыр аны эчәргә кирәк, ә калганы белән госел коеныла. Шушылай эшләнсә, Аллаһның теләге белән чир дәвалана. Әгәр дә, хаҗәт булса, чирдән дәвалануга ирешкәнче бу ысулны 2-3 тапкыр яки күбрәк кабатларга мөмкин. Ошбу ысул бик күп тапкырлар тәҗрибә ителде, һәм Аллаһ тәгалә аның белән файда китерә иде. Шулай ук, ир кеше сихер тәэсирендә хатын ятагында җенси көчсезлеккә дучар булса, бу ысул бик тә яхшы булып санала.

Б) – Авырткан урынга төкереп-өреп һәм уң кул белән сыпырып, өч тапкыр яки күбрәк «әл-Фәтихә» сүрәсе, «Аять әл-Көрси», «әл-Бәкара» сүрәсенең соңгы ике аятен, «әл-Ихлас», «әл-Фәлакъ» һәм «ән-Нәс» сүрәләрен укырга кирәк.

В) – Аллаһка сыенулар, өшкерүләр һәм гомуми догалар белән ялварырга кирәк:

1)

«أَسْأَلُ اللَّهَ الْعَظِيمَ رَبَّ الْعَرْشِ
الْعَظِيمِ أَنْ يَشْفِيَكَ»

– ***/Әс‘әлуллаһәл-газыйм, раббәл-гаршил-газыйм, ән йәшфийәк/*** (7 тапкыр әйтелә)

— «Бөек гарешнең Раббысы булган Бөек Аллаһтан сине шифаландыруын сорыйм»[305]

2) Кулны тәннең авырткан урынына куеп 3 тапкыр:

«بِسْمِ اللَّهِ»

– ***/Бисмилләһ/***

— «Аллаһ исеме белән», — дип әйтелә, аннары 7 тапкыр:

«أَعُوذُ بِاللَّهِ وَقُدْرَتِهِ مِنْ شَرِّ مَا أَجِدُ وَأُحَاذِرُ»

– ***/Әгүҙү билләһи үә кудратиһи***

305 Әбү Дауыд 3106. Мөселман, авыру булган һәм әҗәле җитмәгән кардәшенең хәлен белеп зиярат кылса, һәм 7 тапкыр ошбу доганы кабатласа, ул кешене Аллаһ тәгалә һичшиксез авыруыннан шифа кылыр

мин шәрри мә әҗиду үә ухәҙиру/

— «Мин сизгән һәм курыккан яманлыклардан Аллаһка вә Аның кодрәтенә сыенам», — диелә.[306]

3) «اللَّهُمَّ رَبَّ النَّاسِ، أَذْهِبِ الْبَأْسَ، وَاشْفِ أَنْتَ الشَّافِي، لاَ شِفَاءَ إِلاَّ شِفَاؤُكَ، شِفَاءً لاَ يُغَادِرُ سَقَمًا»

– /Аллаһүммә Раббәннәс, әҙһибил-б'әс, үәшфи әнтәш-шәәфи, лә шифә'ә иллә шифә'үк, шифә'ән лә йүгадиру сәкамә/

— «Әй Аллаһ! Кешеләрнең Раббысы! Бу чирне ерагайт (бетер) һәм шифаландыр! Син — Шифаландыручы, Синең шифаңнан башка шифа юк. Чир калмаслык итеп шифаландыр!»[307]

306 Мөслим 2202
307 әл-Бохари 5750, Мөслим 2191

4)

«أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّامَّةِ مِنْ كُلِّ شَيْطَانٍ وَهَامَّةٍ وَمِنْ كُلِّ عَيْنٍ لاَمَّةٍ»

– ***/Әгүҙү би кәлимәтил-ләһит-тәммәти мин күлли шәйтанин үә һәммәтин үә мин күлли гайнин ләәммәһ/***

— «Аллаһның камил сүзләренә[308] һәрбер шәйтаннан, хәшәрәттән һәм яман күздән сакласын дип сыенам»[309]

5)

«أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّامَّاتِ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ»

– ***/Әгүҙү би кәлимәтил-ләһит-тәммәти мин шәрри мә халәкъ/***

308 Кәүния һәм шәргыя сүзләр керә. Кәүния, мәсәлән Аллаһ бер нәрсәнең булуын теләсә, Ул аңа бул ди һәм була. Шәрьгыя, мәсәлән ул бәла-каза төшкәнче һәм төшкәннән соң мөмкин; аятел көрсине кич белән укыган кеше төне буе шәйтаннан саклана - бу бәла төшкәнче Аллаһның аяте белән саклану, чирләгән кеше фәтихә сүрәсе белән дәвалана - бу бәла төшкәннән соң Аның сүзе белән саклану

309 әл-Бохари 3371

— «Аллаһ ﷻ халикъ кылган нәрсәләрнең явызлыгыннан, Аның камил сүзләренә сыенам»[310]

6)

«أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّامَّاتِ: مِنْ غَضَبِهِ، وَعِقَابِهِ، وَشَرِّ عِبَادِهِ، وَمِنْ هَمَزَاتِ الشَّيَاطِينِ، وَأَنْ يَحْضُرُونِ»

– ***/Әгүҙү би кәлимәтил-ләһит-тәммәти мин гадабиһи үә гыйкабиһи үә шәрри гыйбәдиһи үә мин һәмәзәтиш-шәйәтыйни үә ән йәхдурун/***

— «Аллаһның камил сүзләренә Аның ачуыннан, җәзасыннан, колларының явызлыгыннан, шәйтаннарның вәсвәсәләреннән һәм аларның минем яныма килүләреннән сыенам»[311]

310 Мөслим 2708. Әгәр кеше нинди дә булса өйдә тукталса һәм ошбу доганы укыса, бу өйдән киткәнгә кадәр аңа бернәрсә дә зыян китермәс

311 Әбү Дауыд 3893

7)

«أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّامَّاتِ الَّتِي لَا يُجَاوِزُهُنَّ بَرٌّ وَلَا فَاجِرٌ، مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ، وَبَرَأَ، وَذَرَأَ، وَمِنْ شَرِّ مَا يَنْزِلُ مِنَ السَّمَاءِ، وَمِنْ شَرِّ مَا يَعْرُجُ فِيهَا، وَمِنْ شَرِّ مَا ذَرَأَ فِي الْأَرْضِ، وَمِنْ شَرِّ مَا يَخْرُجُ مِنْهَا، وَمِنْ شَرِّ فِتَنِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ، وَمِنْ شَرِّ كُلِّ طَارِقٍ إِلَّا طَارِقًا يَطْرُقُ بِخَيْرٍ يَا رَحْمَنُ»

– ***/Әгүҙү би кәлимәтил-ләһит-тәммәти әлләти лә йүҗәүизүһүннә бәррун үә лә фәҗирун мин шәрри мә халәка үә бәра‘ә үә ҙәра‘ә үә мин шәрри мә йәнзилү минәс-сәмә‘и үә мин шәрри мә йәгьруҗү фиһә үә мин шәрри мә ҙәра‘ә фил-әръдый үә мин шәрри мә йәхруҗү минһә үә мин шәрри фитәнил-ләйли үән-нәһәри үә мин шәрри күлли таарикыйн илләтаарикан йәтъруку бихайрин йә Рахмән/***

— «Аллаһ халикъ кылган, һәм бар иткән нәрсәләрнең явызлыгыннан, күктән төшкән явызлыктан вә ан-

да менә торган явызлыктан, Ул җирдә булдырган явызлыктан вә аннан чыга торган явызлыктан, төннең вә көннең фетнәсеннән һәм яхшылык белән килүчедән башка – әй Рахмән, һәрбер төнлә килүченең явызлыгыннан, Аллаһның камил сүзләренә сыенам. Ул сүзләрдән игелекле дә бозык та өстен була алмый!»[312]

8)

«اللَّهُمَّ رَبَّ السَّمَوَاتِ السَّبْعِ، وَرَبَّ الأَرْضِ، وَرَبَّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ، رَبَّنَا وَرَبَّ كُلِّ شَيْءٍ، فَالِقَ الْحَبِّ وَالنَّوَى، وَمُنْزِلَ التَّوْرَاةِ وَالإِنْجِيلِ وَالْفُرْقَانِ، أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ كُلِّ شَيْءٍ أَنْتَ آخِذٌ بِنَاصِيَتِهِ، أَنْتَ الأَوَّلُ فَلَيْسَ قَبْلَكَ شَيْءٌ، وَأَنْتَ الآخِرُ فَلَيْسَ بَعْدَكَ شَيْءٌ، وَأَنْتَ الظَّاهِرُ فَلَيْسَ فَوْقَكَ شَيْءٌ، وَأَنْتَ الْبَاطِنُ فَلَيْسَ دُونَكَ شَيْءٌ ...»

– /Аллаһүммә, Раббәс-сәмәүәтис-сәбги үә Раббәл-әръдый үә Раббәл-

312 «Мүснәд» Әхмәд

гаршил-гаҙыйм. Раббәнә үә Раббә күлли шәй‘ин фәликаль-хәбби үәннәүәә үә мүнзиләт-тәүрати үәлинҗили үәл-фүръкан. Әгүҙү бикә мин шәрри күлли шәй‘ин әнтә әхыйҙүн бинәсыйәтиһ. Аллаһүммә әнтәл-Әүүәлү фәләйсә каблəкә шәй‘үн үә әнтәл-Әхыйру фәләйсә бәгьдәкә шәй‘үн үә әнтәҙ-Ҙаһиру фәләйсә фәүкакә шәй‘үн үә әнтәл-Бәтыйнү фәләйсә дүнәкә шәй‘үн.../

— «Әй Аллаһ! Син җиде күкләрнең Раббысы, җирнең Раббысы, бөек гарешнең Раббысы, безнең Раббыбыз һәм барча нәрсәнең Раббысы, орлыкны вә бөртекне ярып шыттыручы, Тәүратны, Инҗилне һәм Коръәнне иңдерүче. Мин Сиңа барча нәрсәнең явызлыгыннан сыенам, чөнки алар барысы да Сиңа буйсынучы. Әй Аллаһ! Син – иң Әүвәлге һәм Сиңа кадәр һичнәрсә юк (булмады), Син – иң Ахыргы һәм Синнән соң һичнәрсә дә юк

(булмаячак), Син – Җиңүче (яки Ачык) һәм Синең өстә һичнәрсә дә юк, Син — Яшерен һәм Синнән тыш һичнәрсә юк[313]...»[314]

9)

«بِسْمِ اللهِ أَرْقِيكَ، مِنْ كُلِّ شَيْءٍ يُؤْذِيكَ، وَمِنْ شَرِّ كُلِّ نَفْسٍ أَوْ عَيْنِ حَاسِدٍ، اللهُ يَشْفِيكَ، بِسمِ اللهِ أَرقِيكَ»

– /Бисмилләһи әръкыйкә мин күлли шәй‘ин йү‘ҙикә үә мин шәрри күлли нәфсин әү гайни хәсидин, Аллаһү йәшфикә, бисмилләһи әръкыйкә/

— «Сине җәфалаган барча нәрсәдән һәм барча кешенең явызлыгыннан яки көнчелләрнең начар күзләреннән Аллаһ исеме белән сине өшкерәм! Аллаһ сине шифаландырсын! Аллаһ исеме белән сине өшкерәм!»[315]

313 Аллаһның заты мәхлукатлардан яшерен, яки Аллаһ барча яшерен нәрсәне дә белә

314 Мөслим 2713

315 Мөслим 2186

10)

«بِسْمِ اللهِ يُبْرِيكَ، وَمِنْ كُلِّ دَاءٍ يَشْفِيكَ، وَمِنْ شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ، وَمِنْ شَرِّ كُلِّ ذِي عَيْنٍ»

– /Бисмилләһи йүбрикә мин күлли дә‘ин йәшфикә үә мин шәрри хәсидин иҙә хәсәдә, үә мин шәрри күлли ҙий гайнин/

— «Аллаһ исеме белән! Ул сине чирләрдән пакьләсен, барча авыруллардан терелтсен, әгәр көнчел көнләшсә аның явызлыгыннан һәм начар күзле кешеләрдән сакласын!»[316]

11)

«بِسْمِ اللَّهِ أَرْقِيكَ مِنْ كُلِّ شَيْءٍ يُؤْذِيكَ، مِنْ حَسَدِ حَاسِدٍ، وَمِنْ كُلِّ ذِي عَيْنٍ اللَّهُ يَشْفِيكَ»

– /Бисмилләһи әръкыйкә мин күлли шәй‘ин йү‘ҙикә, мин хәсәди хәсидин үә мин күлли ҙий гайнин Аллаһү йәшфикә/

— «Сине җәфалаган барча нәрсә-

316 Мөслим 2185

дән, көнчелләрнең хөседләреннән һәм барча начар күзле кешеләрдән, мин Аллаһ исеме белән сине өшкерәм! Аллаһ сине шифаландырсын!»[317]

Аллаһка бу сыенулар, догалар һәм өшкерүләр сихердән, күз тиюдән, җен кагылудан һәм башка төрле чирләрдән дәвалануга сәбәп булып торалар. Аллаһ теләге белән, алар барысы да гомум вә файдалы.

3 – Хиҗәмә. Әгәр дә тәндә сихер әсәрләре беленсә, шул урынга хиҗәмә ясарга кирәк. Ә инде хиҗәмә ясау мөмкин булмаса, өстә әйтеп узган ысуллар дәваланырга җитәр, иншәАллаһ.

4 – Табигый дәвалар. Коръән Кәрим һәм пәйгамбәребезнең ﷺ пакъ Сөннәте белгерткәнчә, файдалы табигый дәвалар бар. Әгәр дә, кеше бу дәваларны кабул иткәндә аның

317 Ибен Мәҗәһ 3527

файдасы Аллаһтан икәнлегенә нык-лы инану, ышану белән кулланса, Аллаһ файда вә шифа бирәчәк, иншәАллаһ.

Табигый, файдалы дәваларга **Бал, Кара Тмин орлыгы, Зәмзәм суы, Яңгыр суы** ***(Без күктән мөбәрак су иңдердек)***[318]**, Зәйтүн мае** кенә ***«Бу майны ашагыз һәм сөртегез, чөнки ул мөбәрак агачтан»***[319], һәм ул иң яхшы май санала. Шулай ук, госел коену, пакъләнү һәм хушбуйлар куллану да табигый дәвалардан санала.

2 — Күз тиюдән дәвалану

Күз тиюдән дәвалану берничәгә бүленә:

Беренчесе: ***Күз тиюдән саклану:***

1 – Әгәр дә кеше күз тиюдән курыкса, ул алда (сихердән саклану

318 «Каф» 9

319 әт-Тирмизи 1851, ибен Мәҗәһ 3319

бүлегендә әйтеп узылганча) зикерләр, догалар һәм Аллаһка сыенулар белән сакланырга тиеш.

2 – Әгәр дә кеше башка кешегә, яки аның мал-мөлкәтенә, яки баласына, туганына яки башка берәр нәрсәсенә үзенең күзе тиюдән курыкса, аның өчен бәрәкәт сорап дога кылсын:

«مَا شَاءَ اللَّهُ لاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللَّهِ»،
«اللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَيْهِ»

– ***/Мәшә'Аллаһү лә куүәтә иллә билләһ, Аллаһүммә бәрик галәйһи/***

— «Бу Аллаһ теләгән нәрсә. Аллаһтан башка куүәт юк. Әй Аллаһ! Аңа бәрәкәт бир!»

Чөнки пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә берәрегез үзенең кардәшендә аны гаҗәпләндерерлек нәрсә күрсә, аңа бәрәкәт сорап дога кылсын»***[320]

320 Ибен Мәҗәһ 1160

3 – Әгәр дә берәүгә күз тияр дип курку янаса, ул вакытта аның матурлыгын ят күзләрдән яшерергә кирәк[321].

Икенчесе: ***Күз тигәннән соң дәвалану:***

1 – Әгәр дә күзе тигән кеше билгеле булса, ул вакытта аны намаз таһәрате алырга кушып, шул су белән күз тигән авыруны госел коендырырга кирәк[322].

2 – Авырткан урынга төкерепөреп һәм уң кул белән сыпырып еш кына «әл-Ихлас», «әл-Фәлакъ», «ән-Нәс», «әл-Фәтихә» сүрәләрен, «аять әл-Көрси»не, «әл-Бәкара» сүрәсенең соңгы ике аятен укып, өшкерүдә билгеле булган догалар белән Аллаһка яләарырга кирәк. Бу өшкерү догаларының мисалы 214-223 битләрдә искә алынды («В»

321 «Шәрех әс-Сүннәһ» әл-Бәгауи, «Зәд әл-Мәгад»
322 Әбү Дауыд 5056

бүлеге 1-11 номерлар).

3 – Алда искә алынган сүрәләрне, аятьләрне вә өшкерү догаларын суга төкереп-өреп укырга һәм авыруга бераз эчертергә кирәк, ә калган су аның өстенә коела[323]. Яки шушы сүрәләр, аятьләр вә өшкерү догалары Зәйтүн маена укыла, һәм авыруның тәненә сөртелә[324]. Искә алынган сүрәләрне, аятьләрне вә өшкерү догаларын Зәмзәм яки яңгыр суына укыганда, тагын да яхшырак.

4 – Шулай ук, «әл-Фәтихә» сүрәсен, «аять әл-Көрси»не, «әл-Бәкара» сүрәсенең соңгы ике аятен, «әл-Ихлас», «әл-Фәлакъ», «ән-Нәс» сүрәләрен һәм өшкерүдә билгеле булган догаларны язып, аннары су белән чайкап авыруга эчертергә мөмкин.

323 Әбү Дауыд 3885. Пәйгамбәребез Сәбит бин Кайска шулай эшләде. Шәйх Әлбәни зәгыйфь диде.
324 «Мүснәд» Әхмәд

Өченчесе: Көнчел кешенең начар күзеннән саклану чаралары:

1 – Аллаһка көнчел кешенең явызлыгыннан сыену.

2 – Аллаһка тәкъвалы булу, һәм Аның әмерләрен вә тыюларын үтәү. Чөнки пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Аллаһның кушканнарын һәм тыйганнарын үтә, һәм Ул сине саклар»***[325]

3 – Көнчел кешегә карата сабырлык күрсәтергә, аны гафу итеп анның белән ачуланышмаска, шикаять кылмаска һәм ул китергән зыян турында уйламаска тырышырга кирәк.

4 – Аллаһка тәвәккәлек кылырга кирәк, чөнки кем дә кем Аллаһка тәвәккәллек кылса, аңа ярдәм йөзеннән шул җитәр.

5 – Көнчел кешедән куркырга да, аның турында уйлап күңелне шомландырырга да кирәкми. Бу иң

325 әт-Тирмизи 2516

файдалы сәбәпләрдән.

6 – Аллаһка омтылырга, Аңа ихлас булырга һәм Аның ризалыгын эстәргә кирәк.

7 – Гөнаһлардан Аллаһка тәүбә итәргә кирәк. Чөнки гөнаһлар кешене дошманнар кулына буйсындыра. Аллаһ әйтте: **«Сезгә ирешкән бәла-казалар вә кайгылар, үзегез кәсеп иткән гөнаһларыгыз сәбәпледер, шулай булса да Аллаһ гөнаһларыгызның күбрәген гафу итә»**[326]

8 – Мөмкинчелек булганда садәка бирү вә ихсанлык күрсәтү кирәк. Чөнки бу нәрсәләрдә кешене бәла-казалардан, күз тиюдән һәм көнчел кешенең явызлыгыннан саклауда зур тәэсир бар.

9 – Көнчелнең, залимның һәм рәнҗетүченең явызлык утын, аңа карата ихсанлы булып сүндерергә кирәк. Сиңа күпме генә җәберләү-

326 «әш-Шүра» 30

не, рәнҗетүне вә көнләшүне арттырса да, син аңа ихсанлыкны, нәсыйхәтне һәм кызгануны арттыр. Ләкин, моны барча кеше дә эшли алмый, иллә-мәгәр Аллаһтан олуг насыйп өлеше тигән кеше генә мондый тәүфыйккъка ирешә.

10 – Бер Аллаһка гына ихлас инану тиешле. Аның теләгеннән тыш бернәрсә зыян да, файда да китерә алмый. Барча нәрсә дә Аның теләгендә, һәм сәбәпләрнең дә нәтиҗәсе Аннан. Тәүхид - Аллаһ тәгаләнең кешеләргә биргән кирмәне[327], кем анда керсә, ул кеше иминлектә була.

Искә алып узган бүлекләр күз тиюдән, сихерченең һәм көнчелнең явызлыгыннан саклый торган сәбәпләр.

327 Кальга (крепость)

3 — Кешегә җен керүдән дәвалану

Кешегә җен керүдән дәвалану икегә бүленә:

Беренчесе: ***Җен керүдән саклану:***

– Аллаһ кушкан барча йөкләмәләрне үтәү, хәрамнардан саклану, барча начарлыклардан тәүбә кылу, шәригатебездә рөхсәт ителгән зикерләр, догалар һәм Аллаһка сыенулар белән үз-үзеңне саклау тиешле.

Икенчесе: ***Җен кергәннән соң дәвалану:***

1 – Мондый дәвалау ысулы белән, йөрәге теләнә муафыйкъ булган мөселман шөгыльләнергә тиеш. Бу очракта иң яхшы дәвалау, өшкерү белән була. Өшкергәндә авыруга төкереп-өреп өч тапкыр яки күбрәк «әл-Фатихә» сүрәсе, «Аять әл-Көрси», «әл-Бәкара» сүрәсенең сонгы ике

аятен, «әл-Ихлас», «әл-Фәлакъ» һәм «ән-Нәс» сүрәләрен, яки башка Коръән аятьләрен укырга кирәк, чөнки Коръән тулысы белән мөэминнәр өчен йөрәк вә тән шифасы, һидәят һәм рәхмәт. Шулай ук, бу очракларда алда искә алынып киткәнчә, өшкеру догалары белән Аллаһка ялвару файдалы булып тора (Икенче бүлек: Сихер ирешкәннән соң дәвалану «Б», «В»).

Дәвалануда уңышлы нәтиҗәгә ирешү өчен, авыру кеше ныклы ихтыяр көченә ия булырга тиеш. Аның йөрәге теленә муафыйкъ булып, ихлас күңелдән Аллаһка ялварырга вә сыенырга тиеш.

Шушы ук нәрсәләр дәвалаучыдан да таләп ителә, чөнки коралның тәэсире — кулланучының осталыгына бәйле.

Әйткәнебезчә, җеннәргә каршы иң яхшы корал булып Коръән һәм

зикерләр тора, бигрәк тә, «аять әл-Көрси». Чөнки, хәдистә әйтелгәнчә, кем дә кем йоклар алдыннан «аять әл-Көрси»не укый икән, аны иртәнгә кадәр Аллаһтан билгеләнгән сакчы саклый һәм аңа шәйтан якынлаша алмый[328]. Шулай ук, икенче риваятьтә; кем дә кем бу аятьне иртән укыса – кичкә кадәр шәйтаннан сакланыр, ә кем кичтән укыса – иртәнгә кадәр шәйтаннан сакланыр[329].

Ибен Тәймийә бу хакта болай диде: «Шәйтанга каршы көрәшкәндә күп кешеләр бу аятьнең уңышлы нәтиҗәләргә китергәнен сынады. Ул (аять әл-Көрси), кешеләрнең йөрәкләреннән шәйтанны куарга яки җен керү сәбәпле акылга зәгыйфьләнгән кешеләрдән аларны чыгаруда һәм җеннәр ярдәм иткән бозыклык таратучы шәйтанның

328 әл-Бохари 2311
329 әл-Хәким, «әт-Тәргыйб үә әт-Тәрһиб»

иярченнәре вә дуслары белән көрәшүдә, искиткеч көчле тәэсиргә ия...»

Җен керү сәбәпле акылдан язган кешеләрдән, пәйгамбәребез ﷺ җен чыгаруы хакында кайбер хәдисләр:

1) Үммү Әбәән бинт Үәзигь этисеннән риваять итте: «Бабасы әз-Зәригь үзенең акылдан язган улы (яки бертуган апасының улы) белән Аллаһның расүленә ﷺ килде. Бабам болай диде:

— Без Аллаһның расүленә ﷺ килгәч, мин аңа: «Минем белән акылдан язган улым (яки бертуган апасының улы). Мин аны синең янга, син аның өчен Аллаһка дога кылсын дип алып килдем», — дидем. Аллаһның расүле ﷺ миңа: «Минем янга алып кер аны», — диде. Мин улым (яки бертуган апасының улы) артыннан киттем, чөнки ул дөя өстендә утырып калган иде. Аны дөядән

җиргә төшердем дә, өстендәге сәфәр киемнәрен салдырып ике яхшы кием кидердем, һәм кулыннан тотып пәйгамбәребезгә ﷺ алып килдем. Аллаһның расүле ﷺ : «Миңа якынрак китер һәм аркасы белән бор», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ аны кулы белән күлмәгенең өстеннән һәм астыннан җыеп тотты да: «Чык, Аллаһның дошманы! Чык, Аллаһның дошманы!», — дип әйтә-әйтә, аркасына суга башлады, хәтта мин аның култык астының агын күрдем. Шуннан соң, улым (яки бертуган апасының улы) минем яныма килде һәм миңа әүвәлге карашы белән түгел, ә бәлки сәламәт кеше күзләре белән карады. Аннары, Аллаһның расүле ﷺ аны алдына утыртып, суга дога кылды (өшкерде) һәм улымның (яки бертуган апасының улы) битен сыпырып аның өчен дога кылды. Пәйгамбәребезнең ﷺ догасыннан соң, безнең төркемдә аннан да

яхшырак кеше юк иде»[330]

2) Ягьлә бин Мүрра әйтте:

— Мин пәйгамбәребез ﷺ белән булган өч вакыйгага шаһит булдым. Андый хәлне миңа кадәр беркем дә күрмәгән, һәм миннән соң да беркем күрмәс. Бервакыт, без пәйгамбәребез ﷺ белән юлга чыктым, һәм күпмедер баргач, кечкенә баласын тотып утырган бер хатынны очраттык. Ул, пәйгамбәргә ﷺ : «Әй Аллаһның расүле! Бу сабый чирли, ул безне интектерә һәм аның көненә бик күп өянәкләре[331] була», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: «Бир әле аны миңа», — диде. Ул хатын баласын күтәреп Аллаһның расүленә ﷺ сузды, һәм аны иярнең уртасына утыртты. Пәйгамбәребез сабыйның авызын ачты да, анда өч тапкыр төкереп өрде, һәм: «Бисмилләһ! Мин Аллаһның

330 «әл-Мүгьҗәм әл-Кәбир» әт-Табәрани

331 Чирнең аерым бер вакытта көчәеп китүе (приступ)

колы, кит вә югал Аллаһның дошманы!», — диде. Моннан соң, ул ﷺ баланы әнисенә кайтарды, һәм әйтте: «Кире кайтканда безне шушы урында ук каршыла, сабый үзен ничек токанлыгын безгә сөйләрсең».

Без юлыбызны дәвам иттек. Кире кайтканда, шул ук урында без теге хатынны өч сарык белән очраттык. Аллаһның расүле ﷺ аннан: «Балаң ни хәлдә?», — дип сорады. Ул хатын: «Сине хаклык белән җибәргән Зат белән ант итәм! Без ул сабыйдан бер генә сәер нәрсә дә күрмәдек. Менә бу сарыкларны ал», — диде. Пәйгамбәр ﷺ миңа: «Төшеп берсен ал, ә калганнарын аңа кайтарып бир», — диде[332]

3) Госман бин Әбү әл-Гас әйтте:

— Пәйгамбәребез ﷺ мине Таиф шәһәренә башлык итеп куйгач, минем башыма намаз вакытында төрле уйлар килә башлады, хәтта

332 «Мүснәд» Әхмәд

мин намазда ничәнче ракәгатьне укыганымны да онытып ялгыша башладым. Бу нәрсәләрне тоеп, мин Аллаһның расүленә ﷺ юнәлдем. Ул ﷺ миннән: «Әбү әл-Гасның улымы?», — дип сорады. Мин: «Әйе, әй Аллаһның илчесе», — дидем. Пәйгамбәр ﷺ миңа: «Нәрсә китерде сине?», — диде. Мин: «Әй Аллаһның расүле! Миңа намаз вакытында төрле уйлар килә, хәтта мин ничәнче ракәгатьне укыганымны да онытам», — дип зарландым. Ул ﷺ : «Бу шәйтан. Минем яныма якынрак кил», — диде. Мин Аллаһның расүле ﷺ янына якынрак килеп аякларымны бөкләп утырдым. Пәйгамбәребез ﷺ күкрәгемә кулы белән сукты, авызыма төкереп өрде һәм: «Чык, Аллаһның дошманы!», — диде. Ул шушылай өч тапкыр эшләде, аннары миңа: «Үзеңнең эшеңә кире кайт», — диде[333]

333 Ибен Мәҗәһ 3548

Җеннең имам Әхмәдкә буйсынуы хакында риваять

Пәйгамбәребез ﷺ җеннәргә әмер итеп, аларны ачуланып вә ләгънәт кылып куып чыгара иде. Ләкин, расүлебездән ﷺ башка булган, гади мөэмин-мөселманга болар гына җитми. Мондый гамәлдә иманның көчлелеге, ныклы инану һәм Аллаһка якын булу да зур әһәмият уйный. Боларга ачык мисал вә раслама булып, имам Әхмәд белән булган вакыйганы китерергә мөмкин:

«Бервакыт имам Әхмәд мәчеттә утырганда, аның янына хәлиф Мүтәвәккилдән кеше килде, һәм:

– Хәлифнең йортындагы бер хезмәтче хатын өянәк авыруы белән интегә. Син шушы хатын өчен Аллаһтан шифа сорасын, дип әйтергә, хәлиф мине сиңа җибәрде, — диде.

Имам Әхмәд бу кешегә үзенең агач

аяк киемен бирде дә, болай диде:

— Хәлифнең йортына кайт, ул чирле хатынның баш очына утыр да, аңа кергән җенгә: «Имам Әхмәд сорарга кушты: «Сиңа нәрсә яхшырак, бу хатыннан чыгуыңмы, әллә шушы агач сандали белән битеңә җитмеш тапкыр сугумы?», — диген.

Бу кеше сандалиларны кулына алды да, җен кергән хезмәтче хатын янына килеп баш очына утырды, һәм имам Әхмәд әйткән сүзләрне аңа җиткерде.

Моннан соң, җен теге хезмәтче хатын теле белән:

— Ишеттем һәм буйсынам имам Әхмәдкә! Әгәр дә ул безгә хәтта Гыйрак җирләреннән китәргә боерса, без китәр идек. Чөнки, дөреслектә ул Аллаһка буйсынды, ә кем Аллаһка буйсына икән – аңа барча нәрсә буйсына.

Бу сүзләрдән соң, җен хезмәтче

хатыннан чыкты. Ул хатын тынычланып калды. Шулай ук, Аллаһ тәгалә ул хатынны балалар белән ризыкландырды.

Ләкин, имам Әхмәд вафат булганнан соң, теге җен тагын шул ук хатынга керде. Хәлиф, имам Әхмәднең бер дустын чакыртты. Ул шул вакыттагы сандалиларны алып, хәлифкә килде һәм җенгә:

— Чык! Югыйсә, мин сине шушы сандалилар белән кыйныйм! — диде.

Җен аңа җавап итеп:

— Мин чыгарга җыенмыйм, һәм сиңа буйсынмыйм. Имам Әхмәд Аллаһка тиешлечә буйсына иде, һәм безгә дә Аллаһка буйсынырга куша иде, — диде.

4 — Эренле яраларны һәм җәрәхәтләрне дәвалау

Әгәр дә, берәр кеше эренле ярасына яки җәрәхәтенә зарланса, пәйгамбәребез ﷺ бармагы белән болай эшли иде, (һәм Суфьян бин Гуяйнәһ имән бармагын җиргә тидерде), аннары күтәреп болай дип әйтте:

«بِسمِ اللهِ، تُرْبَةُ أرْضِنَا، بِرِيقَةِ بَعْضِنَا، يُشْفَى بِهِ سَقِيمُنَا، بِإِذْنِ رَبِّنَا»

– /Бисмилләһ! Түрбәту әръдыйнә бирикати бәгьдыйнә йүшфә биһи сәкыймүнә би‘иҙни Раббинә/

— «Аллаһ исеме белән! Җиребезнең туфрагы — кайберебезнең төкреге белән, безнең чирлебез терелер — Раббыбызның теләге белән!»[334]

Хәдиснең мәгънәсенә килгәндә, гыйлем әһелләре болай дип аңлат-

334 әл-Бохари 5745, Мөслим 2194

ты: «Авыру кеше имән бармагын төкерегә белән юешли дә җиргә тидерә, аның бармагына җир туфрагы ябыша. Аннары, туфрак ябышкан имән бармагы белән җәрәхәтен яки авырткан урынын сыпыра. Сыпырганда өстә искә алынган сүзләрне укый.

5 — Чирле кешенең үз-үзен дәвалауы

— Кулыңны тәнеңнең авырткан урынына куй да, өч тапкыр:

«بِسْمِ اللَّهِ»

— **/Бисмилләһ/**

— «Аллаһ исеме белән», — дип әйт, аннары 7 тапкыр:

«أَعُوذُ بِاللَّهِ وَقُدْرَتِهِ مِنْ شَرِّ مَا أَجِدُ وَأُحَاذِرُ»

– /Әгүзү билләһи үә кудратиһи мин шәрри мә әҗидү үә ухәзиру/

— «Мин сизгән һәм курыккан яманлыклардан Аллаһка вә Аның кодрәтенә сыенам», — диген[335]

6 — Авыруның хәлен белгәндә, аны дәвалау догасы

«أَسْأَلُ اللَّهَ الْعَظِيمَ رَبَّ الْعَرْشِ
الْعَظِيمِ أَنْ يَشْفِيَكَ»

– ***/Әс‘әлүллаһәл-газыймә раббәл-гаршил-газыйми өн йәшфийәк/*** (7 тапкыр әйтелә)

— «Бөек гарешнең Раббысы булган Бөек Аллаһтан сине шифаландыруын сорыйм»[336]

335 Мөслим 2202

336 Әбү Дауыд 3106. Мөселман, авыру булган һәм әҗәле җитмәгән кардәшенең хәлен белеп зиярат кылса, һәм 7 тапкыр ошбу доганы кабатласа, ул кешене Аллаһ тәгалә һичшиксез авыруыннан шифа кылыр

7 — Бизгәк[337] чирен дәвалау

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

«الْحُمَّى مِنْ فَيْحِ جَهَنَّمَ فَأَبْرِدُوهَا بِالْمَاءِ»

— «Бизгәк Җәһәннәм уты эссесеннән тарала, аны су белән суытыгыз!»[338]

8 — Агулы еланнар һәм хәшәрәтләр чагуыннан дәвалау

1 – «әл-Фәтихә»не укып, чагылган урынга төкереп өрергә кирәк[339]

2 – Чагылган урынны тозлы су белән сыпыра-сыпыра «әл-Кәфирун», «әл-Фәлакъ» һәм «ән-Нәс» сүрәләрен укырга кирәк[340]

337 Туңдырып калтырата торган йогышлы авыру
338 әл-Бохари 3264, Мөслим 2210
339 әл-Бохари2276
340 «әл-Мүгъҗәм әс-Сагыйрь» әт-Табәрани,

9 — Кара тмин орлыгы белән дәвалану

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

«فِي الْحَبَّةِ السَّوْدَاءِ شِفَاءٌ مِنْ كُلِّ دَاءٍ إِلَّا السَّامَ»

– «Кара тмин орлыгында, сәмнән башка барча чирдән дә дәва бар»[341]

Ибен Шиһәб: «Сәм» — ул үлем, ә кара тмин орлыгын шулай ук «әш-шүниз» дип тә әйтәләр», — диде.

Кара тмин орлыгының файдасы бик күп, ә инде пәйгамбәребезнең ﷺ ***«...барча чирдән дә дәва бар»*** дигәне, Аллаһ тәгаләнең Коръәндә болай дип әйтүе шикелле: **«Ул (туфан), Аллаһның әмере белән барча нәрсәне дә юк итә»**[342]

«Силсилә әл-әхәдис әс-сахиха» 548

341 әл-Бохари 5688, Мөслим 2215

342 «әл-Әхкаф» 25

10 — Бал белән дәвалану

Аллаһ тәгалә бал кортларын искә алып болай диде:

«يَخْرُجُ مِنْ بُطُونِهَا شَرَابٌ مُخْتَلِفٌ أَلْوَانُهُ فِيهِ شِفَاءٌ لِلنَّاسِ إِنَّ فِي ذَلِكَ لَآيَةً لِقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ»

— «Бал кортлары эченнән төрле төстәге баллар чыга, ул балларда кешеләр өчен шифа бар. Дөреслектә, бу — фикерли белгән кешеләргә могҗиза»[343]

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Шифа өч нәрсәдә: Хиҗәмәдә, балда һәм ярага ут белән (тимер) кыздырып басуда. Ләкин мин өммәтемне ут белән кыздырып басудан тыям!»***[344]

343 «ән-Нәхел» 69
344 әл-Бохари 5681

11 — Зәмзәм суы белән дәвалану

1 – Пәйгамбәребез ﷺ Зәмзәм суы хакында болай диде: ***«Дөреслектә ул мөбәрак су. Ул (ризык кебек) тукландыра [һәм авыруны шифаландыра]»***[345]

2 – Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Зәмзәм суы нинди ният белән эчелсә (нинди чирдән эчелсә), шуның өчен (дәва булып тора)»***[346]

3 – Пәйгамбәребез ﷺ Зәмзәм суын үзе белән савытларга һәм турсыкларга[347] салып ала иде, һәм аны чирлеләргә коеп, аларны эчертә торган иде[348]

Ибен әл-Кайим болай диде: *«Мин вә башка кешеләр Зәмзәм суы белән*

345 Мөслим 2473, җәя эчендәгеләр әл-Бәззәр, әл-Бәйһәкый һәм әт-Табәраниләрдә китерелә

346 Ибен Мәҗәһ 3062

347 Бурдюк

348 әт-Тирмизи 963, «Силсилә әл-әхәдис әс-сахиха» 883

дәваланып карадык, һәм без искит-кеч гаҗәеп нәтиҗәләр күрдек. Мин үзем генә дә Зәмзәм суы бәрәкәтен-дә, Аллаһ тәгаләнең теләге белән, күп кенә чирләрдән дәваландым»[349]

349 «Зәд әл-мәгад» ибен әл-Кайим

ИСМЕ ӘГЪЗАМ

Сорау:

Нинди исем Исме Әгъзам?

Җавап:

1)

عن بريدة قال: سَمِعَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ رَجُلًا يَدْعُو وَهُوَ يَقُولُ: اللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ بِأَنِّي أَشْهَدُ أَنَّكَ أَنْتَ اللَّهُ لَا إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ الأَحَدُ الصَّمَدُ الَّذِي لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ وَلَمْ يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ. قَالَ: فَقَالَ: «وَالَّذِي نَفْسِي بِيَدِهِ، لَقَدْ سَأَلَ اللَّهَ بِاسْمِهِ الأَعْظَمِ الَّذِي إِذَا دُعِيَ بِهِ أَجَابَ وَإِذَا سُئِلَ بِهِ أَعْطَى»

Мәгънәсе: Бүрәйдәһ ﷺ әйтте: Бервакыт пәйгамбәр ﷺ бер кешенең болай дип дога кылганын ишетте:

– ***/Аллаһүммә инни әс‘әлүкә би-әнни әшһәдү әннәкә әнтәАллаһү лә иләһә иллә әнт, әл-Әхәдү әс-Самәдү әлләҙи ләм йәлид үә ләм йүләд үә ләм йәкүлләһү күфүән әхәд/***

— «Әй Аллаһ! Дөреслектә, мин Синнән: «Син Аллаһ! Синнән башка иләһ юк! *Син* Бердәнбер; Омтылылган Хуҗа, Ихтыяҗларны Үтәүче; *Ул* тудырмады вә тудырылмады һәм

һичкем Аңа тиң булмады», — дип шаһитлык кылуым белән сорыйм».

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Минем җаным Аның кулында булган Зат белән ант итәм! Бу кеше Аллаһтан, Аның Бөек Исеме (Исме Әгъзам) белән сорады. Әгәр дә, ул исем белән дога кылынса – *Аллаһ* җавап бирә, ә аның белән соралса – сораганын бирә».[350]

2)

عَنْ أَنَس أَنَّهُ كَانَ مَعَ رَسُولِ اللهِ صلى الله عليه وسلم جَالِسًا وَرَجُلٌ يُصَلِّي ثُمَّ دَعَا اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْأَلُكَ بِأَنَّ لَكَ الْحَمْدَ لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ الْمَنَّانُ بَدِيعُ السَّمَوَاتِ وَالأَرْضِ يَا ذَا الْجَلاَلِ وَالإِكْرَامِ يَا حَىُّ يَا قَيُّومُ. فَقَالَ النَّبِىُّ صلى الله عليه وسلم «لَقَدْ دَعَا اللهَ بِاسْمِهِ الْعَظِيمِ الَّذِى إِذَا دُعِىَ بِهِ أَجَابَ وَإِذَا سُئِلَ بِهِ أَعْطَى»

Мәгънәсе: Әнәстән ﷺ риваять ителә, бервакытны ул пәйгамбәр ﷺ белән бергә утырганда алар янында бер кеше намаз укый иде. Шуннан соң бу кеше болай дип дога кылды:

350 әт-Тирмизи 3475

– /Аллаһүммә инни әс‘әлүкә би‘әннә ләкәл-хәмдә лә иләһә иллә әнт, әл-Мәннәнү Бәдийгус-сәмәүәти үәл-әрьдъ, йә Ҙәл-Җәләли үәл-Икрами йә Хәййү йә Каййүм/

— «Әй Аллаһ! Дөреслектә, барча мактау хәмед-сәнә Сиңа гына булганлыктан чыгып, мин Синнән сорыйм! Синнән башка иләһ юк! Син - Нигъмәтләүче; күкләрне һәм җирне юктан Бар Кылучы; әй Бөеклек вә Икрам-Юмартлык Иясе! Әй Тере! Әй барча тереклекне, яшәешне Барлап (тәртипкә салып, карап) Торучы!».

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «*Бу кеше Аллаһка, Аның Бөек Исеме (Исме Әгъзам) белән ялварды. Әгәр дә, ул исем* белән дога кылынса – *Аллаһ* җавап бирә, ә аның белән сораса – сораганын бирә».[351]

3)

عَنْ أَسْمَاءَ بِنْتِ يَزِيدَ أَنَّ النَّبِىَّ ﷺ قَالَ: اسْمُ اللَّهِ

351 Әбү Дауыд 1495

الأَعْظَمُ فِى هَاتَيْنِ الآيَتَيْنِ (وَإِلَهُكُمْ إِلَهٌ وَاحِدٌ لاَ إِلَهَ إِلاَّ هُوَ الرَّحْمَنُ الرَّحِيمُ) وَفَاتِحَةُ سُورَةِ آلِ عِمْرَانَ (الم اللهُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ هُوَ الْحَىُّ الْقَيُّومُ)

Мәгънәсе: Әсмә бинт Язидтән риваять ителә, пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Аллаһның Бөек Исеме (Исме Әгьзам) менә бу ике аятьтә: «Сезнең Иләһегез — Бердәнбер Иләһ. Аннан башка иләһ юк. Ул — Мәрхәмәтле, Рәхимле!»[352] Һәм Әли Гыймран сүрәсен ачып җибәрүче аять «Әлиф-Ләәм-Миим. Аллаһтан башка иләһ юк, мәгәр Ул гына! *Ул — мәңге* Тере, Ул – яшәешне Барлап торучы!»[353].

4)

عن القاسم بن عبد الرحمن، عن أبي أمامة ﷺ عن النبي ﷺ قال: «إن اسم الله الأعظم لفي ثلاث سور من القرآن: في سورة البقرة، وآل عمران، وطه». قال القاسم: فالتمستها فوجدت في سورة البقرة آية الكرسي: (الله لا إله إلا هو الحي

352 әл-Бәкара 163

353 Әли Гыймран 1-2

القيوم[354])، وفي سورة آل عمران: (الم الله لا إله إلا هو الحي القيوم[355])، وفي سورة طه: (وعنت الوجوه للحي القيوم[356]).

Мәгънәсе: әл-Касим бин Габдуррахманнан, Әбү Үмәмәдән ﷺ риваять ителә, пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Дөреслектә, Аллаһның Бөек Исеме (Исме Әгъзам) Корънннең менә бу өч сүрәсендә: «әл-Бәкара» «әли Гыймран» һәм «Таһә». Шуннан соң, әл-Касим әйтте: «Мин аларны эзләдем һәм «әл-Бәкара» сүрәсендә аятель Көрсине, «әлиГыймран» сүрәсендә 1-2нче аятьләрне һәм «Таһә» сүрәсендә 111нче аятьне таптым»[357].

5)

عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ قَالَ كَانَ النَّبِىُّ ﷺ إِذَا كَرَبَهُ أَمْرٌ قَالَ «يَا حَىُّ يَا قَيُّومُ بِرَحْمَتِكَ أَسْتَغِيثُ»

Мәгънәсе: Әнәс бин Маликтән ﷺ

354 әл-Бәкара 255

355 Әли Гыймран 1-2

356 Таһә 111

357 әл-Мүстәдрак гәлә әс-Сахихәйн лил-Хәким

риваять ителә: «Әгәр дә пәйгамбәрне ﷺ берәр нәрсә борчуга салса, ул:

– */Йә Хәййү, йә Каййүмү, бирахмәтикә әстәгыйсү/*

— «Әй Тере! Әй барча тереклекне, яшәешне Барлап Торучы! Синең рәхмәтең илә ярдәм эстим!» — дип әйтә иде»[358].

6)

عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ قَالَ قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم «أَلِظُّوا بِيَا ذَا الْجَلاَلِ وَالإِكْرَامِ»

Мәгънәсе: Әнәс бин Маликтән ﷺ риваять ителә, пәйгамбәр ﷺ әйтте:

– */Йә Зәл-Җәләли үәл-Икрам/*

— «Әй Бөеклек вә Икрам-Юмартлык Иясе!», — дигән сүзләрне күп әйтеп дога кылыгыз»[359].

7)

عَنْ سَعْدٍ قَالَ قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ «دَعْوَةُ ذِى النُّونِ إِذْ دَعَا وَهُوَ فِى بَطْنِ الْحُوتِ لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ سُبْحَانَكَ

358 эт-Тирмизи 3524

359 эт-Тирмизи 3525

إِنِّى كُنْتُ مِنَ الظَّالِمِينَ. فَإِنَّهُ لَمْ يَدْعُ بِهَا رَجُلٌ مُسْلِمٌ فِى شَىْءٍ قَطُّ إِلاَّ اسْتَجَابَ اللهُ لَهُ»

Мәгънәсе: Сәгьдтән ﷺ риваять ителә, пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Балык иясе (Йунус пәйгамбәр) балык эчендә булганда болай дип дога кылды:

– ***/Лә иләһә иллә әнтә сүбхәнәкә инни күнтү минәҙ-ҙалимин/***

124 — «Синнән башка иләһ юк, Син барча кимчелектән пакь! Дөреслектә, мин залимнәрдән булдым»

Нинди генә мөселман ошбу сүзләр белән дога кылмасын, Аллаһ һичшиксез аның догасына җавап бирер».[360]

Ошбу һәм башка хәдисләрдән чыгып кайбер гыйлем әһелләре Аллаһның Бөек Исемен (Исме Әгъзамны) тәгаенләп ул хәдисләрдә килгәнчә диделәр. Икенчеләре Аллаһның Бөек Исеме (Исме Әгъзам) **«әл-Хәййү әл-Каййүм»** диделәр. Өченчеләре Аллаһның **барча исемнә-**

360 әт-Тирмизи 3505

ре дә бөек (Әгъзам) диделәр. Ә гыйлем әһелләренең кайберләре (Әбү Хәнифә, имам Тахауи вә башкалар) **«Аллаһ»** исеме «Исме Әгъзам» һәм бу исем Аның барча исемнәрен дә үз эченә ала диделәр. Аллаһу әгъләм.

الله

(1) **Аллаһ** (Коллык вә гыйбадәт кылына торган Зат)

Күпчелек гыйлем әһелләре әйтүенчә, дөресрәге «Исме Әгъзам» шушы була. Бу Аңа гына хас булган тәгаенле, билгеле исем. Ул Аллаһның барча күркәм исемнәренең мәгънәләрен җыя һәм Аның барча сыйфатларын үз эченә ала. Бу исем «Гыйбадәткә лаеклы», «Гыйбадәт кылына торган Зат», «Гыйбадәт вә коллык Иясе» дигән мәгънәләрне аңлата.

Коръәндә 2724 тапкыр искә алына һәм шулай ук күп кенә хәдисләрдә кабатлана.

الرَّبُّ

(2) әр-Рабб (Хуҗа, Тәрбия Кылучы)

әр-Рабб – Үзенең барча колларының язмышлары белән идарә итеп, аларны барча нигъмәтләр белән нигъмәтләп хәлләрен хәстәрләүче.

Коръәндә 900 артык урында искә алына, мәсәлән: [әл-Фәтихә:2], [әл-Әнгам:164], [Һүд:66], [әл-Мү'минүн:97], [Сәбә:15], [әл-Үәкыйга:74], һәм шулай ук күп кенә хәдисләрдә зикер ителә.

الوَاحِدُ

(3) әл-Үәхид (Бер)

әл-Үәхид – Ул, Бер генә. Аның иптәше дә, сандашы да юк.

Коръәндә 20 артык урында искә алына, мәсәлән: [әр-Рагьд:16], [ән-Нәхл:51], [Гафир:16], һәм шулай ук күп

кенә хәдисләрдә зикер ителә.

الأَحَدُ

(4) **әл-Әхәд** (Бердәнбер)

әл-Әхәд – Ул, Бердәнбер. Аңа охшаш та, тиң дә юк.

Коръәндә «әл-Ихлас» сүрәсендә искә алына, мәсәлән: [әл-Ихлас:1], һәм шулай ук хәдисләрдә зикер ителә.

الرَّحْمَنُ

(5) **әр-Рахмән** (Мәрхәмәтле, Шәфкатьле)

әр-Рахмән – Ул, дөньяда барча мәхлукъларга да, ә ахирәттә мөэминнәргә генә киң мәрхәмәтлек Иясе, һәм ул Аллаһның Заты белән бәйле.

Габдуллаһ бин Мүбәрак әйтте: «әр-Рахмән – әгәр дә, Аннан соралса

— бирә; әр-Рахийм – әгәр дә, Аннан соралмаса — ачулана».

әр-Рахмән сүзе Аллаһка карата гына кулланыла.

Коръәндә 57 урында искә алына, мәсәлән: [әр-Рахмән:1], [Таһә:5], [Мәрьям:45], һәм шулай ук күп кенә хәдисләрдә зикер ителә.

الرَّحِيمُ

(6) **әр-Рахийм** (Рәхимле)

әр-Рахийм – дөньяда да, ахирәттә дә мөэминнәргә генә ирешә торган мәрхәмәтлек Иясе, һәм ул Аллаһның фигыле белән бәйле.

әр-Рахийм исеме алдындагы «әл» тәгаенләү билгесе булмаса, Аллаһтан башкаларга карата да кулланыла, мәсәлән берәр йомшак күңелле кеше хакында бу кеше бик тә рәхимле дип әйтелүе мөмкин.

Коръәндә 123 урында искә алына,

мәсәлән: [әл-Фәтихә:2], [әл-Әхзәб:34], [әш-Шүгара:191], [әл-Мүзәммил:20], һәм шулай ук күп кенә хәдисләрдә зикер ителә.

الْحَيُّ

(7) әл-Хәйй (Мәңге Тере)

Аллаһ тәгаләгә үлем вә фанилык (бетү) юк һәм мөмкин түгел. Ул бу нәрсәләрдән пакь, саф вә ерак, һәм Ул Мәңге Тере, Калучы.

Коръәндә 5 урында искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:255], [Әли-Гыймран:2], [Таһә:5], [әл-Фуркан:58], [Гафир:16], һәм шулай ук күп кенә хәдисләрдә зикер ителә.

الْقَيُّومُ

(8) әл-Каййүм (Үзлегеннән Бар Булучы, Барлап Торучы)

Ул Үзлегеннән Бар булучы, һәм беркемгә дә, бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел. Аллаһ Үзенең камиллегендә вә сыйфатларында бернинди үзгәрешсез, тәэсирсез даими Калучы, һәм Ул барча мәхлукъларның тереклеген, яшәешен тәртиптә тотып Барлап Торучы!

Бу исем Коръәндә 3 урында искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:255], [Әли-Гыймран:2], [Таһә:111], «әл-Ка'им» дип [әр-Рагьд:33] сүрәсендә искә алына, һәм шулай ук күп кенә хәдисләрдә зикер ителә.

الْأَوَّلُ

(9) **әл-Әүүәл** (Әүүәлге, Беренчел)

әл-Әүүәл – Әүүәлге, Беренчел исеме, Аннан башка барча нәрсәләрнең дә булмаганнан соң бар булуларына ишарәт итә, ә Ул бернинди чиксез барча нәрсәгә кадәр бар булды, һәм Аның барлыгының башлангычы юк. Аңа

кадәр вә Аның белән бергә һич шәй (һичкем, һичнәрсә) юк һәм булмады.

Бу исем Коръәндә бер урында гына искә алына [әл-Хәдид:3], һәм шулай ук сөннәттә дә бер генә урында искә алына, Аллаһу әгьләм.

الْآخِرُ

(10) **әл-Әәхыйр** (Ахыргы, Соңгы)

әл-Әәхыйр – Ахыргы, Сонгы һәм Аннан соң һич шәй (һичкем, һичнәрсә) юк. Аның барлыгының бетүе юк вә Ул барча мәхлукатлар беткәннән соң да Калучы. Ибен әл-Кайим әйтте: «Ул Үзенең Әүүәллеге белән барча нәрсәләрдән дә алда булды вә Үзенең Соңгылыгы белән барча нәрсәләрдән соңда калды».

Шулай ук, бу исем дә Коръәндә дә, сөннәттә дә бер генә урында искә алына [әл-Хәдид:3], Аллаһу әгьләм.

الظَّاهِرُ

(11) **әҙ-Ҙаhир** (Өстен; Ап-Ачык)

әҙ-Ҙаhир – Ул, берүзе генә Өстенлек вә Бөеклек Заты. Ул барча нәрсәдән Өстен вә Бөек булды һәм Аннан да өстен бернәрсә дә, беркем дә юк. Ул барча мәхлукатларны буйсындырып, җиңеп Өстен Торучы.

Ул – Ап-Ачык, чөнки күргән һәр нәрсәдә Аның Барлыгына вә Берлегенә ишарәт иткән ап-ачык дәлилләр, галәмәтләр чагыла.

Шулай ук, бу исем дә Коръәндә дә, сөннәттә дә бер генә урында искә алына [әл-Хәдид:3], Аллаһу әгьләм.

الْبَاطِنُ

(12) **әл-Бәтыйн** (Иң Якын)

әл-Бәтыйн – Иң Якын, һәм Аннан да якын бер шәй (һичнәрсә, һичкем) юк.

Ул барча эчке вә яшерен нәрсәләрне Белүче, һәм безгә муен кан тамырыннан да якынрак. Ул мәхлукъларның күрүеннән пәрдәләнгән, ягъни Ул дөньяда мәхлукъларга күренми, ә ахирәттә мөэминнәргә күренә, ләкин дөньяда да, ахирәттә дә Аңа ирешү (барча яклап чолгап алу, белү) мөмкин түгел.

Шулай ук, бу исем дә Коръәндә дә, сөннәттә дә бер генә урында искә алына [әл-Хәдид:3], Аллаһу әгьләм.

ٱلْوَارِثُ

(13) **әл-Үәриҫ** (Варис)

әл-Үәриҫ – барча мәхлукълар беткәннән соң, үлгәннән соң аларның барча мал-мөлкәтләренә, мирасларына, гомүмән барча нәрсәгә Ул гына Варис булып кала. Ул Көнне Аллаһ әйтәчәк: «Бүген мөлек-патшалык кемнеке?!», — дип, һәм Үзе үк җавап би-

рәчәк: «Куәтле Бер Аллаһныкы!», — дип.

Бу исем Коръәндә өч урында искә алына, барысы да күплек сан белән, мәсәлән: [әл-Хиҗр:23], [әл-Әнбия:89], [әл-Касас:58], һәм бер урында фигыль рәвешендә зикер ителә [Мәръям:40].

الْقُدُّوسُ

(14) **әл-Куддүс** (Изге, Кимчелексез)

әл-Куддүс – Ул берүзе генә Үзенә лаек булган камил сыйфатлар белән сыйфатлы Изге Зат, һәм Барлыкка Китерүчегә лаек булмаган барча кимчелектән, җитешсезлектән, мәхлукатларга охшаудан саф вә пакь.

Бу исем Коръәндә ике урында искә алына, мәсәлән: [әл-Хәшр:23], [әл-Җүмүга:1], һәм шулай ук күп кенә хәдисләрдә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

ٱلسُّبُّوحُ

(15) **әс-Сүббүх** (Пакьтән-Пакь)

әс-Сүббүх – Ул берүзе генә Үзенә лаек булган камил сыйфатлар белән сыйфатлы Пакьтән-Пакь Зат һәм Иләһкә лаек булмаган барча кимчелектән, иптәшлектән, тиңдәшлектән, җитешсезлекләрдән, мәхлукатларга охшаудан саф вә пакь. Аны күкләрдәге вә җирдәге барчасы пакьлый, тәсбихли.

Аллаһның бу күркәм исеме хәдисләрдә искә алына, мәсәлән [Мөслим:487]

ٱلسَّلَامُ

(16) **әс-Сәләм** (Иминлек-Тынычлык Иясе; Пакь-Сәламәт)

әс-Сәләм – Ул Үзенең Затында, сыйфат-фигыльләрендә булган камиллек сәбәпле, барча кимчелекләрдән,

җитешсезлекләрдән Пакь-Сәламәт. Ул Үзенең колларын иминлек-тынычлык таратуга, Ислам диненә һәм иминлек-тынычлык йортына чакыра. Аның чакыруына җавап бирүчеләр, ул йортка ирешә. Аллаһның газабы, җәзасы, үч алуы, Аңа лаек булмаган золым кебек нәрсәләрдән сәламәт. Коллар тузан бөртеге кадәр дә золым кылынмаслар, чөнки Ул Үзенең гаделлеге белән хөкем итүче. Барча иминлек-тынычлыкның башлангычы Аннан, һәм ахыры да Аңарда.

Бу исем Коръәндә бер урында искә алына: [әл-Хәшр:23], һәм шулай ук хәдисләрдә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْمُؤْمِنُ

(17) **әл-Мү'мин** (Тәсдикъләүчы, Раслаучы, Ныгытучы; Саклаучы, Иминлек-Тынычлык Бирүче)

әл-Мү'мин – Ул: Тәсдикъләүчы, Раслаучы, Ныгытучы: 1) Үзенең берлеге вә сыйфатлары белән Үзен-Үзе Тәсдикъләүчы, Раслаучы. Аллаһ әйтте: «Аллаһ – гаделлекне торгызучы, тотып торучы – Аннан башка иләһ юк икәнлегенә шаһитлык кылды, шулай ук фәрештәләр һәм гыйлем ияләре шаһитлык кылдылар»[361]. Бу аятьтә Ул Үзенә тәүхид-берлек белән шаһитлык итте, һәм бу шаһитлык иң олуг вә иң зур шаһитлык булып тора. Моннан да олуграк, зуррак шаһитлык юк. 2) Ул Үзенең илчеләрен, пәйгамбәрләрен вә аларга ияргәннәрне Тәсдикъләүчы, Раслаучы, Ныгытучы. Расүлләргә аларның тугрылыгын раслап аять-могҗизалар иңдерде, Шулай ук, мөэминнәрне хак динне тотуда вә кәферләргә каршы көрәштә төрле ярдәмнәр белән ныгытты. 3) Кыямәт Көнендә Аллаһ кешеләрдән сорау алачак һәм мөэминнәрне иманнары

361 Әли-Гыймран:18

белән раслаячак, ә кәферләрне ялганга чыгарачак. 4) Үлем алдыннан мөэминнәрне иманнарында ныгытачак.

Саклаучы, Иминлек-Тынычлык Бирүче: 1) Аның золымыннан мәхлукатлар имин. Аның золым кылуы мөмкин түгел. 2) Мөэминнәр иман вә тәүхид сәбәпле, бу дөньяда Аллаһ тарафыннан үзләренең йөрәк-күңелләрендә иминлек һәм тынычлык табалар. 3) Ул Үзенең яраткан колларын Кыямәт Көненең дәһшәтеннән, куркынычлыгыннан саклый вә имин кыла. 4) Ул барча мәхлукатларны, булсын мөэминнәр яки кәферләр, һәммәләрен дә әҗәлләре җиткәнче саклый, ризыкландыра.

Бу исем Коръәндә бер урында искә алына: [әл-Хәшр:23], әмма сахих хәдисләрдә зикер ителгәне билгеле түгел, Аллаһу әгьләм.

الْحَقُّ

(18) **əл-Хəккъ** (Хак, Чын, Дөрес)

əл-Хəккъ – Аллаһ даими барлык, тереклек, үзлегеннəн бар булучылык, барлап торучылык белəн сыйфатлы һəм Аңа фанилек, бетү хас түгел. Аның барлыгы Чын, Хак һəм барлыгында бернинди дə шик-шөбһə юк. Ул Үзенең раббылыгында, илəһлегендə Хак. Аның барча күркəм исемнəре вə камил сыйфатлары, фигыльлəре, хəбəрлəре, шəригате, тəкъдире, җəзасы, иңдергəн китаплары, җибəргəн илче-расүллəре, Җəннəт, Җəһəннəм, кабер газабы, Кыямəт Көне, хисаб.. гомумəн Аннан булган барча нəрсə чын вə хак.

Бу исем Коръəндə ун аятьтə искə алына, мəсəлəн: [əл-Əнгам:62], [əл-Йунус:32], [əн-Нур:25], [Лукман:31], [Таһə:114] һəм шулай ук пəйгамбəребезнең ﷺ хəдислəрендə зикер ителə, Аллаһу əгълəм.

الْمُتَكَبِّرُ

(19) **әл-Мүтәкәббир** (Олуг, Горур)

әл-Мүтәкәббир – Аллаһ олуглык вә горурлык Иясе. Ул мәхлукатларның сыйфатларыннан Бөек, аларның үзләрен өстен куюларыннан, мин-минлекләреннән Олуг, Горур, Мөтәкәббир. Аннан башка олуглык, горурлык, тәкәбберлек Иясе юк, бу исем Аңа гына хас һәм Ул гына Олуг, Горур, ә Аннан башкалар барчасы да түбән, кечкенә, чүп кенә.

Бу исем Коръәндә бер урында искә алына: [әл-Хәшр:23], Аллаһу әгьләм.

الْعَظِيمُ

(20) **әл-Газыйм** (Бөек)

әл-Газыйм – Аллаһ Үзенең Затында, исемнәрендә, сыйфатларында, патшалыгында, милкендә бөеклек Иясе. Ул

мотлак (абсолют рәвештә) Бөек, һәм бөеклегендә Аңа беркем-бернәрсә тиң була алмый, хәтта якын да килә алмый.

Мәсәлән, кешеләр бер-берсе турында: «Бу бөек шәхес, яки бөек милләт», — дип әйтүләре мөмкин, ләкин бу аларның үзләренең акылларына таянып тасвирлаулары гына. Ә Аллаһның бөеклеген тасвирлап бетерү мөмкин түгел, чөнки Аның бөеклеге Үзенә лаек вә хас рәвештә.

Бу исем Коръәндә тугыз аятьтә искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:255], [әш-Шүра:4], [әл-Үәкыйга:96], [әл-Хәкка:33], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْكَبِيرُ

(21) **әл-Кәбийр** (Зур)

әл-Кәбийр – Аллаһ Үзенең Затында, сыйфатларында, фигыльләрендә Зур.

Аннан башка барча нәрсә кечкенә, түбән һәм Анан да зуррак Зат юк.

Бу исем Коръәндә алты урында искә алына, мәсәлән: [ән-Нисә:34], [әр-Рагьд:9], [Локман:30], [әл-Хәҗ:62], [Сәбә:23], [Гафир:12], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْعَلِيُّ

(22) әл-Галий (Биек, Югары, Өстен)

әл-Галий – Аллаһ Үзенең Заты белән барча мәхлукълардан да Биек, Югары дигәнне аңлата, ягъни бу исем Аллаһ Затының биеклегенә, югарылыгына, өстенлегенә ишарәт итә. Ул Үзенең Заты белән гарештән Биек, Югары, Өстен һәм аның ничеклеге бер Аңа гына билгеле.

Бу исем Коръәндә берничә урында искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:255],

һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الأَعْلَى

(23) **әл-Әгьлә** (Биегрәк, Югарырак, Өстенрәк)

әл-Әгьлә – Бу исем Аның үзенчәлегенең, сыйфатларының биеклегенә, югарылыгына ишарәт итә һәм иләһлекне, раббылыкны инкяр кылырлык барча кимчелекләрдән, җитешсезлекләрдән Ул Биек, Югары, Өстен икәнне күрсәтә.

Бу исем Коръәндә берничә урында искә алына, мәсәлән: [әл-Әгьлә:1], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

اَلْمُتَعَالِ

(24) әл-Мүтәгал (Биектән-Биек, Югарыдан-Югары, Өстеннән-Өстен)

әл-Мүтәгал – Аллаһ Үзенең бөтен көч-кодрәте белән барча нәрсәдән дә югарыланды, өстенләнде.

Бу исем Коръәндә берничә урында искә алына, мәсәлән: [әр-Рагьд:9], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

С - Бу өч исем арасында нинди аерма бар?

Җ — әл-Галий Аның Затының биеклегенә, югарылыгына, өстенлегенә ишарәт итә. әл-Әгьлә Аның үзенчәлегенең вә сыйфатларының биеклегенә, югарылыгына, өстенлегенә ишарәт итә. әл-Мүтәгал Аның бөтен көч-кодрәтенең биеклегенә, югарылыгына, өстенлегенә ишарәт итә.

اللَّطِيفُ

(25) **әл-Ләтыйф** (Үтә Күрүчән, Игелекле)

әл-Ләтыйф – Аллаһ барча эшләрнең бөтен нечкәлекләрен белүче Үтә Күрүчән, һәм колларына уйламаган җирдән рәхмәтен ирештереп, аларга карата Игелекле.

Бу исем Коръәндә җиде урында искә алына, мәсәлән: [әл-Әнгам:103], [Локман:16], [әл-Мүлк:14], [әл-Әхзәб:34], [әш-Шүра:19], [Йүсүф:100], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْحَكِيمُ

(26) **әл-Хәкийм** (Хәким, Хикмәт Иясе)

әл-Хәкийм – Ул Хикмәт иясе. Бернәр-

сәне дә юкка гына, мәгънәсез, файдасыз эшләмәде. Аның сүзләрендә, фигыльләрендә бернинди кимчелек тә, хата да юк, алар барчасы да дөрес. Ул һәрнәрсәне үз урынына куеп, булырга лаек булган нәрсәләрне генә булдыра һәм тиешле боерыклар гына бирә. Аның хикмәтендә шик-шөбһә булу мөмкин түгел вә аны шелтәләү дә мөмкин түгел. әл-Хәкийм – Ул барча вакыйгаларның асылын вә нәтиҗәсен белүче киң гыйлем Иясе.

Бу исем Коръәндә туксан бер урында искә алына, мәсәлән: [ән-Нисә:56], [әл-Мәидә:38], [әл-Хәдид:1], [әл-Әхзәб:1], [әш-Шүра:51], [ән-Нүр:10], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْوَاسِعُ

(27) әл-Үәсигь (Киң, Киңлек Иясе)

әл-Үәсигь – Бу исем Аның барча сый-

фатларын һәм үзенчәлекләрен үзенә ала. Ул Үзенең гыйлемендә, байлыгында, фазыйләтендә, нигъмәтендә, патшалыгында, хакимлыгында, көч-куәтендә, бөеклегендә, хикмәтендә, ярлыкауында вә рәхмәтендә һ.б. чиксез Киң, Киңлек Иясе.

Бу исем Коръәндә тугыз аятьтә искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:115], [әл-Бәкара:247, [әл-Бәкара:268], [ән-Нисә:130], [әл-Мәидә:54], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْعَالِمُ، الْعَلِيمُ، عَلَّامُ الْغُيُوبِ

(28) әл-Гаалим (Белүче)
(29) әл-Галийм (Күп Белүче)
(30) Галләм әл-гуйүб
(Яшеренне Үтә Нык Белүче)

әл-Гаалим – Аллаһ барча нәрсәне Белүче. Ул колларының күңелләрендә

иманмы яки көферлекме, хаклыкмы яки батыйл-ялганмы, яхшылыкмы яки яманлыкмы, барчасын белеп тора.

Бу исем Коръәндә унөч тапкыр искә алына, мәсәлән: [әт-Тәүбә:94], [әл-Җинн:26], [әл-Әнбия:51], [әл-Әнбия:81], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

әл-Галийм – Аның гыйлеме ачык күренә торганны вә күренми торганны, билгелене вә яшеренне, тиешлене, мөмкин түгелне вә мөмкин булганны, югары вә түбән галәмне, үткәнне, хәзергене вә киләчәкне һәммәсен чолгап алды. Аның гыйлеменнән бернәрсә дә яшеренеп кала алмый.

Аллаһ элек булганны, хәзерге вакытта булып торганны вә киләчәктә булачакны белә, һәм әгәр дә берәр нәрсә булса - аның ничек булганын белә.

Бу исем Коръәндә йөздә илле җиде тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-

Бәкара:32], [ән-Нисә:12], [әл-Мәидә:97], [Локман:34], [ән-Нәмл:78], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

Галләм әл-гуйүб – Аллаһ Үзен гаип-яшереннәрне Үтә Нык Белүче дип аерым әйтеп узды һәм Локман сүрәсенең 34нче аятендә шул яшереннәрнең бишесен искә алып узды, алар: Кыямәтнең кайчан буласы, яңгырның явасын, ана карыннарында кемнең туасын, кешенең иртәгә нәрсә кәсеп итәсен һәм кайда үләсен. Әлбәттә, Аллаһ белгән яшерен нәрсәләр болар белән генә чикләнми, ә болары мөһимнәрдән кайберләре генә.

Бу исем Коръәндә дүрт тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Мәидә:109], [әл-Мәидә:116], [әт-Тәүбә:78], [әс-Сәбә:48], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْمَلِكُ، الْمَالِكُ، الْمَلِيكُ

(31) әл-Мәлик (Патша, Хаким) **(32) әл-Мәәлик** (Хуҗа) **(33) әл-Мәлийк** (Патшаларның Патшасы, хуҗаларның Хуҗасы)

Бу исемнәр барчасы да Аллаһның патшалык Иясе икәнлегенә ишарәт итә.

әл-Мәлик – Аллаһ хакыйкый, чын Патша, Хаким һәм Аннан да өстенрәк патша юк. Ул Үзе теләгәнчә эш итә, барча нәрсәне тәртипкә салып барлап тора. Ул боера вә тыя, бүләкли вә ала, күтәрә вә түбәнсетә. Ул дөнья вә ахирәт Патшасы һәм Аның хөкеме Үзенең патшалыгында хөкем сөрә.

Бу исем Коръәндә биш тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Мү'минүн:116], [Таһә:114], [әл-Хәшер:23], [әл-Җүмүга:1], [ән-Нәс:2], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

әл-Мәәлик – Аллаһ Үзенең милке булган җир вә күкләрнең, дөнья вә ахирәтнең Хуҗасы һәм Ул Үзе теләгәнчә идарә итүче.

Бу исем Коръәндә ике тапкыр искә алына, мәсәлән: [Әли-Гыймран:26], [әл-Фәтихә:3], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

әл-Мәлийк – Аллаһ патшаларның Патшасы, хуҗаларның Хуҗасы. Бу исем олуглау төре һәм алдагы ике исемне дә үз эченә ала.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Камәр:55], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْحَمِيدُ

(34) әл-Хәмийд (Мактаулы, Мактауга Лаек)

әл-Хәмийд – Аллаһ Үзенең барча фигыльләрендә дә, сүзләрендә дә Мактаулы. Ул сөенечтә дә, көенечтә дә; авырлыкта да, җиңеллектә дә; ягъни барча хәләттә дә Мактауга Лаек, чөнки Ул хикмәт Иясе, Аның эшләрендә ялгышлык-хата булу мөмкин түгел вә юк.

Бу исем Коръәндә унҗиде аятьтә искә алына, мәсәлән: [әл-Хәҗ:24], [Һүд:73], [Ибраһим:8], [Фуссыйләт:42], [әш-Шүра:28], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْمَجِيدُ

(35) әл-Мәҗийд (Данлы, Шанлы)

әл-Мәҗийд – Аллаһ Үзенең Затында, сыйфатларында, фигыльләрендә дан, шан, шәрәф Иясе. Дан ул — затның шәрәфе, югары дәрәҗәсе белән күркәм сыйфатларның, эшләрнең бергә

җыелуы. Затының даны – ул Аның матурлыгы, биеклеге, бөеклеге... Сыйфатының даны – киңлеге, камиллеге. Фигыльләренең даны – ягъни, Аның барча эшләре дә яхшы, күркәм дәвамлы. Ә инде, камил сыйфаты да, хәерле эшләре дә булмаган зат – данлы да, шанлы да, шәрәфле дә була алмый. Мәсәлән, кеше үзенең күркәм холык-сыйфатлары вә эшләре белән данлы, шөһрәтле була, ә инде мотлак кимчелексез, җитешсезлексез мәгәр күп вә киң камил сыйфатлы һәм күп вә киң хәерле эш-фигыль иясе булган Аллаһ турында әйтү мөмкинме?!

Бу исем Коръәндә ике тапкыр искә алына, мәсәлән: [Һүд:73], [әл-Бүруҗ:15], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْخَبِيرُ

(36) **әл-Хабийр** (Хәбәрдар)

әл-Хабийр – Ул Үзенең гыйлеме белән барча нәрсәдән Хәбәрдар, булсын ул яшерен яки ачык, эчке яки тышкы нәрсәләр, күңелдәге уйларны вә йөрәктәге серләрне – һәрнәрсәнең нечкәлекләрен белеп тора. Аннан бернәрсә дә беленмичә калмый. Аның патшалыгында, галәмдә нәрсә генә хәрәкәтләнмәсен, селкенмәсен яки туктап калмасын – Ул барчасыннан да Хәбәрдар.

Бу исем Коръәндә кырык биш тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Әнгам:18], [әл-Әнгам:103], [әт-Тәхрим:3], [Фәтыйр:31], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْقَوِيُّ

(37) **әл-Кауий** (Көчле)

әл-Кауий – Ул камил, мотлак көч Иясе. Аңа беркайчан да көчсезлек, зәгыйфьлек ирешми. Аны һичкем-һичнәрсә җиңә алмый һәм Аның билгеләгән нәрсәсен беркем кире кага алмый, тыя алмый, туктата алмый. Ул *газаб белән* тотуда Көчле һәм эшен төгәлләргә Кадир. Аның теләге мотлак вә барча нәрсә Аның патшалыгында.

Бу исем Коръәндә тугыз тапкыр искә алына, мәсәлән: [әш-Шүра:19], [әл-Хәдид:25], [Гафир:22], [Һүд:66], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْمَتِينُ

(38) **әл-Мәтийн** (Ныклы, Какшамас)

әл-Мәтийн – Ул көч-куәттә, кодрәттә – камил, мөкәммәл. Җирдә һәм күкләрдә Аны беркем-бернәрсә көчсез, зәгыйфь итә алмый. Ул көч-куәттә Ныклы, Какшамас, беркайчан да Аның көч-куәте, кодрәте бетмәс вә үзгәрмәс.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр искә алына: [әҙ-Ҙәрият:58], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْعَزِيزُ

(39) **әл-Газийз** (Куәтле, Җиңүче, Җиңелмәс)

әл-Газийз – Куәтле, Җиңүче вә беркем-бернәрсә Аны җиңә вә Аңа каршы тора алмый торган Ул Бердәнбер Җиңелмәс Зат. Коллар Аңарга барча нәрсәдә дә мохтаҗлар, ә Ул һичкемгә-һичнәрсәгә мохтаҗ түгел.

Бу исем Коръәндә туксан ике тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:260],

[Әли-Гыймран:4], [Садь:9], [Фәтыйр:28], [Садь:66, [әл-Бүруҗ:8], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

اَلْقَهَّارُ

(40) **әл-Каһһәр** (Җиңеп Өстен Чыгучы, Җиңүче)

әл-Каһһәр – Галәмнәрдә булган барча нәрсә Аның көче, карамагы астында. Барча нәрсә, булсын хәрәкәтендә яки тукталышында, Аның әмеренә буйсынган. Мәхлукатлар Аңа буйсыну астыннан берничек тә чыгулары мөмкин түгел.

Бу исем Коръәндә алты тапкыр искә алына, мәсәлән: [әр-Рагьд:16], [Йүсүф:39], [Ибраһим:48], [Гафир:16, [Садь:65, [әз-Зүмәр:4], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْقَادِرُ

(41) **әл-Кадир** (Кодрәтле, Көче Җитүче)

әл-Кадир – Ул эшләргә теләгәнен кайчан вә ничек теләсә – шуңа Кодрәтле, Көче Җитүче һәм һичкем-һичнәрсә Аны гаҗиз, көчсез итә алмый. Ул юкны бар итәргә, барны юк итәргә Кодрәтле. Ул мотлак Кодрәт Иясе.

Бу исем Коръәндә унике тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Әнгам:65], [әл-Мү'минүн:95], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْجَبَّارُ

(42) **әл-Җәббәр** (Буйсындыручы)

әл-Җәббәр – Бу исем үзенә ошбу мәгънәләрне ала: 1) Ул барча мәхлукатлардан да Өстен, Югары. 2) Ул

авырлыкларга сынган кешеләрнең хәлен төзәтә һәм мохтаҗларга ярдәм итә. 3) Ул мәхлукатларын Үзенең теләгән нәрсәсенә буйсындыра.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Хәшр:23], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

اَلْخَالِقُ

(43) **әл-Халикъ** (Халикъ Кылучы, Юктан Бар Кылучы)

әл-Халикъ – Ул барча мәхлукатларны элгәре булмаганча юктан бар итте. Барчасына тәкъдирләрен билгеләде һәм һәр нәрсәне үз урынына куеп тәртип урнаштырды.

Бу исем Коръәндә берничә урында искә алына, мәсәлән: [әл-Хәшр:24], [әл-Әнгам:102], [әз-Зүмәр:62], [Садь:71], [Фәтыйр:3], һәм шулай ук пәйгамбә-

ребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә.

ٱلْبَارِئ

(44) **әл-Бәри’** (Булдыручы, Яралтучы)

әл-Бәри’ – Бу исемнең мәгънәсе хакында кыскача болай дип әйтергә мөмкин: 1) Булдыручы, Яралтучы Бар Кылучы. 2) Мәхлукатларның берсен икенчесеннән аермалы кылучы, һәр-берсен үзенчәлекле итүче. 3) Кешене балчыктан Яралтучы. 4) Аллаһ мәхлукатларны аларга ярашмаган, туры килмәгән нәрсәләрдән пакь кылды, ягъни аларга карасаң син бер ярашмаган, туры килмәгән нәрсә тапмассың, һәр нәрсә үз урынында.

Бу исем Коръәндә өч тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Хәшр:24], [әл-Бәкара:54], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

ٱلْمُصَوِّرُ

(45) әл-Мүсаууир
(Сурәтләүче, Килбәтләүче, Кыяфәтләүче, Шәкелләүче)

әл-Мүсаууир – Аллаһ Үзенең мәхлукатларын юктан бар кылды, һәм кайсын озын, ә кайсын кыска, кайсын күркәм, ә кайсын кабахәт, кайсын ир җенесе, ә кайсын хатын-кыз җенесе кылып аларга төрле сурәт-кыяфәт бирде, шәкелләрен билгеләде. Аларның һәрберсе үзенә хас сурәттә-кыяфәттә-шәкелдә.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Хәшр:24], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә.

ٱلْمُهَيْمِنُ

(46) әл-Мүһәймин (Күзәтеп

Торучы, Шаһит)

әл-Мүһәймин – Ул галәмдәге барча мәхлукатларның гамәлләрен, ризыкларын, әҗәлләрен күзәтеп, барлап тора, аларны саклый. Ул аларның һәрнәрсәсеннән хәбәрдар, аларның өстеннән хөкем итә һәм аларны саклый. Ул һәр эшнең асылын Күзәтеп, Барлап Торучы.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Хәшр:24], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә.

ٱلْحَفِيظُ

(47) **әл-Хәфийҙ** (Саклаучы, Коткаручы)

әл-Хәфийҙ – Ул күкләрне вә җирне билгеле вакытка кадәр Саклаучы. Ул колларын билгеләнгән вакытка кадәр төрле бәла-казалардан, афәтләрдән, һәлакәтләрдән Саклаучы, Коткаручы.

Ул колларының кылган гамәлләрен, сөйләгән сүзләрен Саклаучы, аларның ниятләрен, күңелләрендәге серләрен Белүче. Ул Үзенең яраткан колларын гөнаһлардан, шәйтанның мәкерлегеннән Саклаучы.

Бу исем Коръәндә өч тапкыр искә алына, мәсәлән: [Һүд:57], [Сәбә: 21], [әш-Шүра:6], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْوَلِيُّ

(48) **әл-Үәлий** (Вәли, Химаяче, Яклаучы)

әл-Үәлий – Бу исем берничә мәгънәдә килүе мөмкин, мәсәлән: 1) Барлап Торучы, Тәрбияче. Ул барча мәхлукатларны барлап, күзәтеп тәрбияләп тора, һәм әлбәттә Ул Үзенең колларына муен тамырыннан да якынрак, чөнки тәрбия кылу тәрбияләнүче-

гә якын булу белән бәйле. 2) Яклаучы, Ярдәм Итүче. Аллаһ Үзенең мөселман колларын дошманнардан Яклаучы, аларга каршы торырга Ярдәм Итүче. 3) Яратучы. Ул Үзенә буйсынган колларын ярата һ.б.

Бу исем Коръәндә унбиш тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:257], [Әли-Гыймран:68], [эн-Нисә:45], [Йүсүф:101], [әл-Әгъраф:155], [әш-Шүра:28], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْوَكِيلُ

(49) **әл-Үәкийл** (Вәкил, Караучы)

әл-Үәкийл – Ул Үзенең гыйлеме, камил кодрәте вә чиксез хикмәте белән мәхлукатлар белән идарә итә. Ул Үзенең яраткан колларына (әүлияләргә) җиңеллек бирә, аларны авырлыклардан ерагайта һәм аларның барча эшләрен җайлый. Ул галәмнәрне ка-

рап, барлап, тәрбия кылып торучы. Шуңа да, әгәр дә мөселман берәр нәрсә эшләргә уйласа, ул булдыра алганча барча сәбәпләрен кыла һәм аннары Аллаһка тапшыра, тәвәккәлли.

Бу исем Коръәндә ундүрт тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Әхзәб:3], [Әли-Гыймран:173], [әл-Исра:65], [әз-Зүмәр:62], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْكَافِي

(50) **әл-Кәфи** (Җитүче)

әл-Кәфи – Коллары мохтаҗ булган барча нәрсәләрдә дә Аллаһ Җитүче, һәм Ул аларны барча кирәк-яраклар белән тәэмин итеп тора. Аңа иман китергәннәргә, тәвәккәлләгәннәргә, дөнья вә дин эшләрендә Аннан ярдәм сораучыларга Ул аеруча ярдәм итә. Барча ихтыяҗларны үтәүдә – Ул җитә.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр искә алына, мәсәлән: [әз-Зүмәр:36], ә башка аятьләрдә фигыль тәрендә килә [әл-Бәкара:137], [әл-Әхзәб:25], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الصَّمَدُ

(51) **әс-Самәд** (Омтылылган Хуҗа, Ихтыяҗларны Үтәүче)

әс-Самәд – Бу исем үз эченә бик күп мәгънәләрне ала һәм күпчелек гыйлем әһелләре әйтүенчә, Ул – барча нәрсәдә, ихтыяҗларда Аңа Омтылылган Хуҗа. Коллар барча хәлләрендә дә, ихтыяҗларында да түбәнсенеп, ялварып Аңа омтылалар. Барча мәхлукат Аңа мохтаҗ, ә Ул беркемгә-бернәрсәгә мохтаҗ түгел. Кайбер сәләфләр әс-Самәд – Ул, Даими, мәхлукатлар беткәннән соң Калучы, Мәңге мәгънәсендә диделәр.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Ихлас:2], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә.

الرَّازِقُ، الرَّزَّاقُ

(52) әр-Разикъ (Ризыкландыручы) **(53) әр-Раззәкъ** (Ризыкны Күпләп Бирүче)

әр-Разикъ – Аллаһ барча мәхлукатларны да Ризыкландыручы. Ул аларның ризыкларын галәмнәрне халикъ кылганчы ук билгеләде, һәм ризыкларын аларга җиткереп-биреп торуны Үз өстенә алды. Бер генә мәхлукъ та үзенә билгеләнгән ризыкны алмыйча үлми, һәркем үзенә тиешле ризыкны ала. әр-Разикъ, мотлак ризык бирүче мәгънәсен аңлата, ягъни барча мәхлукатларның да ризыгы Аллаһтан

икәнлекне белдерә.

Бу исем Коръәндә биш тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Мәидә:114], [әл-Мү'минүн:72], [әл-Җүмүга:11], шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

әр-Раззәкъ – Бу исем ризыкларны күп, мул итеп бирүче дигәнне аңлата.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр искә алына, мәсәлән: [әҙ-Ҙәрият:58], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

اَلْفَتَّاحُ

(54) әл-Фәттәәх (Ачучы; Хөкемдар; Җиңү Бирүче)

әл-Фәттәәх – Бу исем берничә мәгънәдә килергә мөмкин. 1) әл-Фәт-тәәх – Ул колларына ризык вә рәхмәт ишекләрен ача, һәм шулай ук аларга авыр вакытларда җиңеллек

ишекләрен ача. 2) Ул мөэминнәргә ярдәм вә җиңү ишекләрен ача, хаксыз рәнҗетелгәннәргә ярдәм бирә. 3) Ул колларының үзара бәхәсләшкәннәрен гадел хөкем итә.

Ул Үзенә итагать иткәннәргә мул ризык вә киң рәхмәт ишекләрен ача, шулай ук, кәферләргә хәсрәт вә һәлакәт ишекләрен ача. Ул мөэминнәрнең калебләрен вә күзләрен хаклыкка ача.

Әгәр дә, сиңа җир тарайса, тормыш сукмаклары кысылса, күңелең урын тапмаса, ул вакытта авырлыклардан җиңеллеккә ишекләрне Ачучыга елап-елап ялвар, сора, билеңне бөк, тезлән, башыңны сәҗдәгә ий, Ул сиңа җавап бирер.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр искә алына, мәсәлән: [Сәбә:26], һәм күплек сан белән дә бер тапкыр искә алына [әл-Әгьраф:89], шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

ٱلْمُبِينُ

(55) **әл-Мүбийн** (Ачык; Бәян Итүче, Ачыклаучы)

әл-Мүбийн – Бу исемнең ике мәгънәдә килүе мәгълүм: 1) Рубубияттаүлүһияттә-күркәм исемнәрдә вә камил сыйфатларда Аллаһның берлегенә, Аның барлыгына дәлилләрнең анык булып гакылда вә фитрада төпләнүе – Аллаһның Ачык икәнлеген билгелиләр. 2) Аллаһ барча мәхлукъларга да аларның ни сәбәпле бар булуларын вә максатларын; шәригать хөкемнәре белән аларның диннәрен; Үзенең берлегенә катгый дәлилләрне; кодрәтен һәм хикмәтен бәян итте, ачыклады.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр искә алына, мәсәлән: [ән-Нур:25], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْهَادِي

(56) әл-Һәәдий
(Һидәятләүче, Юнәлтүче)

әл-Һәәдий – Ул Үзенең колларын аларга файда китерә торган барча нәрсәгә юнәлтә һәм дә зыян китерә торган нәрсәләрдән саклану юлын күрсәтә. Ул аларны белмәгәннәренә өйрәтә һәм тәүфикъка вә туры юлга юнәлтә. Ул колларының калебләренә тәкъвалыкны сала (илһам кыла) һәм аларның йөрәкләрен Аңа омтылучы вә буйсынучы кыла.

Бу исем Коръәндә ике тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Фуркан:31], [әл-Хәҗ:54], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْحَاكِمُ، الْحَكَمُ

(57) әл-Хәәким (Хөкемдар, Хаким) (58) әл-Хәкәм (Гадел Хөкемдар, Гадел Хаким)

әл-Хәәким һәм әл-Хәкәм – Ул хаклык белән батылны, изгелек белән явызлыкны аера һәм һәрбер кешегә гамәлләренә карап тиешлесен бирә. Ул мәхлукатларының арасын дөньяда да, ахирәттә дә Үзенең гаделлеге белән хөкем итә. Беркемне дә тузан бөртеге кадәр дә рәнҗетми, вә беркемгә дә башка кешенең гөнаһын йөкләми. Беркемне дә гөнаһыннан артык җәзаламый, һәркемгә хокукларын кайтара һәм бәхетлегә тиешле әҗер-савабын, ә хәсрәткә ирешүчегә тиешле җәзасын билгели. Аның кылган хөкемен инкяр итү мөмкин түгел вә инкяр итү юк.

әл-Хәәким һәм әл-Хәкәм дигән исемнәрнең кайсысы олуграк мәгънәдә дигәндә, әл-Куртубий болай диде: «әл-

Хәкәм исеме әл-Хәәким исеменнән олуграк мәгънәдә. әл-Хәкәм исеме мәгәр хаклык-гаделлек белән хөкем итүчегә генә әйтелә, чөнки ул мактау-да олуглау сыйфаты *(һәм бу Аллаһка гына хас)*, ә әл-Хәәким ул фигыльгә *(кылына торган эшкә)* бәйләнә, шуңа бу исем белән хаксыз хөкем итүче дә аталырга мөмкин. *(Чөнки хаким, хакимнар дип кешеләр арасын хөкем итүче кешеләргә дә әйтелә)*»[362].

әл-Хәкәм исеме Коръәндә бер тапкыр гына искә алына, [әл-Әнгам:114], ә әл-Хәәким исеме Коръән-дә яхшырак-өстенрәк тәрләнүендә биш тапкыр искә алына [әл-Әгьраф:87], [Һүд:45], [әт-Тин:8], һәм шулай ук пәй-гамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الرَّؤُوفُ

(59) әр-Рауф (Шәфкатьле)

362 әл-Куртубий тәфсире

әр-Рауууф – Ул Үзенең мөэмин колларына карата бик тә Нык Рәхимле, Шәфкатьле. әр-Рахим исеме белән Ул барча колларга карата да рәхимле булса, ә әр-Рауууф исеме белән Ул мөэминнәргә генә карата Рәхимле, Шәфкатьле. әр-Ра'фә (шәфкатьлек) – ул барча яклап та нигъмәт һәм рәхәтлек кенә, ә әр-рахмә (рәхмәт, рәхимлек) ул кайбер халәттә авырлык белән килеп аның нәтиҗәсе рәхәтлек булуы мөмкин. Мәсәләнән-Нур сүрәсенең икенче аятендә Аллаһ зина кылучыларны җәзага тарттырганда сезне шәфкатьлек (бик нык рәхимлек) алмасын диде. Чөнки җинаять кылучыларны җәзага тарттыру ул алар өчен рәхимлек, ләкин шәфкатьлек түгел. Шулай ук, мәсәлән Аллаһ Үзенең рәхмәте белән кәферләргә дә яңгыр яудыра, ризык булдыра. Бу рәхимлек, ә шәфкатьлек түгел. Шәфкатьлек ул рәхимлектән нечкәрәк, олуграк һәм ул мөэминнәргә генә хас, башкалар аңа ирешми.

Бу исем Коръәндә ун тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:143], [әл-Хәҗ:65], [әл-Хәдид:9], [ән-Нур:20], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

ٱلْوَدُودُ

(60) **әл-Үәдүүд** (Сөюче, Яратучы; Сөекле, Яратылучы)

әл-Үәдүүд – Ул Үзенең расүл-илчеләрен, нәби-пәйгамбәрләрен, әүлияләрен һәм мөэмин колларын ярата. Шулай ук, Ул коллар өчен иң Сөекле, иң яратыла торган бердәнбер Зат, Аны барча пәйгамбәрләр дә, әүлияләр дә, мөэминнәр дә бик нык яраталар.

Бу исем Коръәндә ике тапкыр искә алына, мәсәлән: [Һүд:90], [әл-Бүруҗ:14], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْبَرُّ

(61) **әл-Бәрр** (Күп Яхшылык Кылучы)

әл-Бәрр – Ул колларына карата игелекле, аларга Күп Яхшылык Кылучы һәм аларның хәлләрен төзәтүче. Аллаһ изгелек кылучыларның әҗер-савабларын арттырып – аларга Күп Яхшылык Кылучы. Ә явызлык кылучыларны шунда ук җәзаламыйча, ә бәлки аларга тәүбә итәргә вакыт бирә, һәм тәүбә итсәләр аларның тәүбәләрен кабул итеп вә гөнаһларын ярлыкап – аларга Күп Яхшылык Кылучы.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр гына искә алына, мәсәлән: [әт-Тур:28], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

ٱلْحَلِيمُ

(62) әл-Хәлиймъ
(Тотанаклы, Түземле)

әл-Хәлийм – Ул колларының буйсынмауларына һәм күп хаталар кылуларына карамастан, аларны ачык вә яшерен нигъмәтләр белән нигъмәтли. Коллар тарафыннан Үзенә карата булган бу әдәпсезлекләргә Ул Тотанаклы, Түземле. Ул буйсынмаучы гөнаһкәр кешеләрне җәзалау белән ашыкмый, ә бәлки алар тәүбә кылып Аңа кайтсыннары өчен билгеле вакытка кадәр кичектерә. Ул беркемне дә шул ук мизгелдә җәзага тарттырмый.

Бу исем Коръәндә унбер тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:225], [Әли-Гыймран:155], [ән-Нисә:12], [әл-Бәкара:263], [әт-Тәгабүн:17], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

غَافِرُ الذَّنْبِ، الْغَفُورُ الْغَفَّارُ

(63) Гафиру әҙ-ҙәнби (Гөнаһны Яшерүче, Ярлыкаучы) **(64) әл-Гафур** (Гөнаһларны Күп Яшерүче, Күп Ярлыкаучы) **(65) әл-Гаффәрь** (Гөнаһларны Үтә Нык Яшерүче, Үтә Нык Ярлыкаучы)

Гафиру әҙ-ҙәнби – Ул гөнаһ кылучының гөнаһын яшерә һәм аны фаш кылмый.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр гына искә алына, мәсәлән: [Гафир:3]

әл-Гафур – Ул гөнаһларны ярлыкаудан туктамый, һәм гөнаһлар күпме генә кабатланса да, әгәр дә кол ширек кылмыйча тәүбә кылса, Ул аларның гөнаһларын яшерә вә ярлыкый.

Бу исем Коръәндә туксан бер тапкыр гына искә алына, мәсәлән: [ән-Нисә:100], [әш-Шүра:5], [әл-Фәтыйр:28], [ән-Нисә:99], [әл-Фәтыйр:30].

әл-Гаффәръ – Ул гөнаһларны ярлыкауда Үтә Нык Ярлыкаучы. Ул аларны дөньяда да, ахирәттә дә фаш кылмый. Ягъни, кеше бик зур вә авыр гөнаһлар кылып та Аллаһ аны ярлыкамас дип уйлаган очракта да, Ул аны әл-Гаффәръ буларак ярлыкый.

Бу исем Коръәндә биш тапкыр искә алына, мәсәлән: [әз-Зүмар:5], [Садь:66], [Нух:10].

Гыйлем әһелләре әйтүенчә, мәсәлән кеше «залим» булса – Аллаһ әл-Гафир (Ярлыкаучы); кеше «залум» күп золым кылучы булса – Аллаһ әл-Гафур (Күп Ярлыкаучы); кеше «залләм» үтә нык залим булса – Аллаһ әл-Гаффәръ (Үтә Нык Ярлыкаучы).

ٱلْعَفُوُّ

(66) әл-Гафүү (Гафу Итүче)

әл-Гафүү – Ул гөнаһларны гафу итә, аларны җуя, син аларны эшләмәгән

кебек юкка чыгара, һәм Кыямәт Көнендә синңа да, фәрештәләргә дә аларны оныттыра.

Ярлыкау белән гафу итүнең нинди аермасы бар дигәндә, мәсәлән: әгәр дә, син гөнаһ кылсаң Аллаһ аны бу дөньяда да, ахирәттә дә ярлыкый, яшерә һәм ул гөнаһ өчен сине җәзаламый, ләкин ул гөнаһ гамәл дәфтәрендә бар. Ә инде гафу итсә, ул гөнаһ асылында җуела, юкка чыга, әйтерсең лә син аны эшләмәгәнсең.

Шуның өчен дә, пәйгамбәребез Гаишәгә Рамазан аенда Кадер кичәсенә ирешкәндә ошбу доганы кылырга кушты: «Аллаһүммә иннәкә Гафүүн түхибүл-гафүә фәгфү ганни» – Әй Аллаһ! Син Гафу итүче, гафу итәргә яратасың, мине гафу ит!».

Бу исем Коръәндә биш тапкыр искә алына, мәсәлән: [ән-Нисә:43], [ән-Нисә:99], [ән-Нисә:149], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْتَّوَّابُ

(67) **әт-Тәүүәб** (Тәүбәләрне Кабул Итүче)

әт-Тәүүәб – Ул, кешеләрнең гөнаһ кылуларын ташлап, тәүбә кылып вә үкенеп, Аңа кайтуларын кабул итүдән туктамый. әт-Тәүүәб исеме ике төр белән билгеләнә: 1) Аллаһ Үзенең рәхмәте белән колның йөрәгендә үкенүне, тәүбәне, гөнаһны ташлап Аңа кайтуны илһам кыла, булдыра. 2) Ул колларының үкенүләрен, тәүбәләрен кабул итә.

Бу исем Коръәндә унбер аятьтә искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:37], [әл-Бәкара:128], [әл-Хүҗүрат:12], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

اَلْكَرِيمُ، اَلْأَكْرَمُ

(68) **әл-Кәриймъ** (Юмарт) **(69) әл-Әкрам** (Иң Юмарт)

әл-Кәриймъ – Ул тиешле җәзасын билгеләгәннән соң – гафу итә, вәгъдә кылганнан соң – үти. Әгәр дә Ул бирә икән, өметләнгәннән дә күбрәк бирә һәм күпме бирсә дә, кемгә бирсә дә Аның өчен барыбер. Әгәр дә, ихтыяҗларны сораганда Аннан башкага ялварсалар, Ул ризасызлык белдерә. Аннан читләшсәләр – шелтәли, ләкин ерагаймый. Ул Аннан сыену урыны вә яклауны сораган кешене ярдәмсез калдырмый, ә Үзе һичкемгә-һичнәрсәгә мохтаҗ түгел. Кемдә шушы нәрсәләр барчасы да җыелса, Ул «әл-Кәриймъ» була, ә бу мәгәр Бер Аллаһка гына хас.

Бу исем Коръәндә өч тапкыр искә алына, мәсәлән: [ән-Нәмл:40], [әл-Инфитар:6], [әл-Мү'минүн:116],

һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

әл-Әкрам – Ул юмартларның Юмарты, Иң Юмарт, Үтә Юмарт һәм Аннан да Юмартрак беркем-бернәрсә дә юк. Ул юмартлыкта берүзе генә иң бөеге вә иң олугы.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр гына искә алына, мәсәлән: [әл-Галәкъ:3], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә.

اَلْشَّاكِرُ اَلْشَّكُورُ

(70) әш-Шәәкир (Рәхмәтле, Яхшылыкны Белүче) (71) әш-Шәкүүръ (Күп Рәхмәтле, Яхшылыкны Күп Белүче)

әш-Шәәкир һәм әш-Шәкүүръ – Ул колларының аз гына ихлас гамәлләренә Рәхмәтле буларак әҗер-савабын бирә,

гөнаһларын гафу итә, ә бәлки кечкенә генә изге гамәл өчен әҗер-савабларны күпкә арттырып бирә. Ул дөньяның санаулы көннәрендә кылынган гамәлләр өчен, мәңгелек ахирәттә нигъмәтләрен бихисап бирә.

әш-Шәәкир исеме Коръәндә ике тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:158], [ән-Нисә:147], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

әш-Шәкүүрь – исеме Коръәндә дүрт тапкыр искә алына, мәсәлән: [әт-Тәгабүн:17], [Фәтыйр:30], [Фәтыйр:34], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә.

اَلسَّمِيعُ

(72) **әс-Сәмийгь** (Ишетүче)

әс-Сәмийгь – Аллаһ барча тавышларны Ишетүче. Аның ишетүе мәхлукатларныкы кебек түгел, ә бәлки

Үзенә генә хас рәвештә камил ишетү һәм ул ике төрле: 1) Аңа җирдә вә күкләрдә һичнәрсә дә яшерен түгел. Ул барча ишетелә торган нәрсәләрне Үзенең ишетүе белән чолгап алды һәм тавышларның барчасын да бер вакытта ишетә, Аның өчен алар берсе дә буталмый. Ул тышкыны да, эчкене дә; ачыкны да, яшеренне дә ишетә. 2) Аннан сораучыларны, дога кылучыларны вә Аңа гыйбадәт кылучыларны Ул игътибарсыз калдырмый, Аларның сорауларына җавап бирә вә әҗер-савап белән бүләкли.

Ягъни, беренчесе мотлак ишетү булса, икенчесе сораганнарга җавап бирү мәгънәсендә була.

Бу исем Коръәндә кырык биш тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:127], [әш-Шүра:11], [Сәбә:50], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

ٱلْبَصِيرُ

(73) **әл-Бәсыйрь** (Күрүче)

әл-Бәсыйрь – Аллаһ барча нәрсәләрне; ачыкны вә яшеренне, якынны вә еракны Күрүче. Аның күрүе мәхлукатларныкы кебек түгел, ә бәлки Үзенә генә хас рәвештә камил күрү. Аның күрүе җирдәге һәм күкләрдәге барча нәрсәләрне чолгап ала, хәтта караңгы төндә кечкенә кара кырмысканы, аның тышкы вә эчке әгъзаларын, эчендәге ризыкларын Күрүче. Ул үсемлекләрнең эченнән агучы суларны Күрүче. Аннан һичкем-һичнәрсә яшерен түгел, Аның күрүенең чиге юк.

Бу исем Коръәндә кырык ике тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:233], [әш-Шүра:27], [Әли-Гыймран:15], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الشَّهِيدُ

(74) **әш-Шәһийд** (Шаһит)

әш-Шәһийд – Аллаһ колларының гамәлләренә Шаһит, аларның сөйләгәннәрен Саклаучы, серләрен һәм күңелләре яшергән нәрсәләрне Белүче. Аннан һичнәрсә дә кача алмый, хәтта җирдәге вә күкләрдәге тузан бөртеге дә яшерен була алмый. Ул колларының гамәлләренә карата аларга уңай яки каршы шаһитлык кыла.

Бу исем Коръәндә унсигез тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Мәидә:117], [ән-Нисә:166], [әл-Хәҗ:17], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الرَّقِيبُ

(75) **әр-Ракыйб** (Күзәтеп Торучы)

әр-Ракыйб – Ул мәхлукатлардан Хә-

бәрдар, күңелләр яшергән нәрсәләрне белеп тора һәм барча нәрсәне иң күркәм рәвештә тәртипкә салган. Ул һәрбер җан иясенең эшләгәнен барлап, күзәтеп тора. Һичбер нәрсә Аның күзәтүеннән төшеп калмый. Аннан яшеренгән, Ул күрмәгән, ишетмәгән вә белмәгән бер нәрсә дә юк.

Бу исем Коръәндә өч тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Мәидә:117], [ән-Нисә:1], [әл-Әхзәб:52], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الْقَرِيبُ

(76) **әл-Карийб** (Якын)

әл-Карийб – Ул барча мәхлукатларга да Якын, һәм Аның якын булуы ике төрле: 1) Гомуми якын булуы. Ул Үзенең гыйлеме, хәбәрдарлыгы, күзәтүе, шаһитлыгы һәм чолгап алуы белән барчасына да Якын. 2) Аерым, махсус

якын булуы. Монысы Аңа гыйбадәт кылган, Аннан сораган вә Аны яратканнарга карата билгеләнә.

Аның аерым, махсус якын булуы, ул кешеләргә карата Аның мәхәббәтен, ярдәмен, дога кылучыларга җавап бирүен, гыйбадәтләренең кабул итүен һәм әҗер-саваб белән бүләкләүен белдертә.

Бу исем Коръәндә өч тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:186], [Сәбә:50], [Һүд:61], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْمُجِيبُ

(77) **әл-Мүҗийб** (Җаваб Бирүче, Кабул Итүче)

әл-Мүҗийб – Ул Үзенең колларының догаларына, сорауларына җаваб бирә һәм кабул итә.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр искә

алына, мәсәлән: [Һүд:61], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

ٱلْمُحِيطُ

(78) әл-Мүхийтъ (Чолгап Алучы)

әл-Мүхийтъ – Ул Үзенең гыйлеме, кодрәте, рәхмәте һәм җиңеп өстен чыгуы белән барча нәрсәне чолгап алды. Аның гыйлеме барча беленә торган нәрсәне чолгады; күрүе барча күренә торган нәрсәне чолгады; ишетүе барча ишетелә торган нәрсәне чолгады. Аның теләге вә кодрәте барча барлыкка ирешә; Аның рәхмәте җир вә күкләр әһелләрен иңләп ала; Барча мәхлукълар Аңа күнә һәм буйсына.

Бу исем Коръәндә сигез тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:19], [Әли-Гыймран:120], [Фүссыйләт:41], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә.

ٱلْحَسِيبُ

(79) әл-Хәсийб (Җитүче; Хисаб Кылучы)

әл-Хәсийб – исеме ике мәгънәдә килүе мөмкин: 1) «әл-Кәфи» Җитүче мәгънәсендә. Коллар мохтаҗ булган барча нәрсәләрдә дә Аллаһ Җитүче, һәм Ул аларны барча кирәк-яраклар белән тәэмин итеп тора. Барча ихтыяҗларны үтәүдә – Ул җитә. 2) Хисаб Кылучы мәгънәсендә. Ул Үзенең хикмәте вә гаделлеге белән колларының гамәлләре өчен Хисаб Кылучы вә тиешле җәзасын бирүче.

Бу исем Корьәндә өч тапкыр искә алына, мәсәлән: [ән-Нисә:6], [ән-Нисә:86], [әл-Әхзәб:39], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْغَنِيُّ

(80) әл-Ганий (Бай)

әл-Ганий – Ул беркемгә-бернәрсәгә мохтаҗ түгел, ә бәлки киресенчә барчасы да Аңа фәкыйрьләр, мохтаҗлар. Аллаһ камил, мотлак Бай һәм Аңа тиң вә иптәш юк. Ул барча мәхлукатларны да ризыкландыра, ә Үзенә якын булган колларын иман вә гыйлем белән йөрәкләрен тутырып аеруча нигъмәтли.

Бу исем Коръәндә унсигез тапкыр искә алына, мәсәлән: [әл-Бәкара:263], [Йүнүс:68], [Фәтыйр:15], [әл-Хәдид:57], [ән-Нәмл:40], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْوَهَّابُ

(81) **әл-Үәһһәб** (Бүләкләүче)

әл-Үәһһәб – Ул алмашка бернәрсә таләп итмичә теләгән кешесен Үзе теләгәнчә мул итеп бүләкли. Ул, ихтыяҗларны сораусыз, нигъмәтләрне күп вә даими-өзлексез биреп Бүләкләүче.

Бу исем Коръәндә өч тапкыр искә алына, мәсәлән: [Әли-Гыймран:8], [Садь:9], [Садь:35], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْمُقِيتُ

(82) **әл-Мукыйт** (Ашатучы, Тәэмин Итүче)

әл-Мукыйт – Ул мәхлукатларны яшәү чыганагы белән тәэмин итә. Аларга ризыкларын җиткерә һәм хикмәте вә Аңа гына тиешле мактауы белән Үзе

теләгәнчә сарыф итә.

Шулай ук, кайбер гыйлем әһелләре бу исемнең мәгънәсе «Кодрәтле», «Күзәтеп Торучы», «Барлап Торучы», «Саклаучы», «Шаһит», «Җитүче» диделәр.

Бу исем Коръәндә бер тапкыр искә алына, мәсәлән: [ән-Нисә:85], һәм шулай ук пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْقَابِضُ، الْبَاسِطُ

(83) **әл-Каабидъ** (Кысып Тотучы), (84) **әл-Бәәситъ** (Киң Җәюче)

Бу ике күркәм исем капма-каршы исемнәр буларак, аларны бер-берсеннән аерып, Аллаһны берсе белән генә искә алырга һәм мактарга ярамый, ә бәлки икесе бергә искә алынулары тиешле.

Җан ияләре үлгәндә Ул аларның

җаннарын тәннәреннән тотып кала, кыса, ә яшәгәндә җаннарын тәннәренә җәя.

Кемнедер Исламга китереп күкрәген киң җәя, ә кемнедер һидәяттән мәхрүм итеп күкрәген тарайта, кыса.

әл-Каабидъ – Аллаһ Үзенең хикмәте белән колларының ризыкларын, сәбәпләрен һәм башка нәрсәләрен (булсын сәламәтлек, нәсел; байлык) теләгән вакытында тарайта, кысып тота, азайта.

әл-Бәәситъ – Аллаһ Үзенең юмартлыгы белән колларының ризыкларын арттыра, киң итеп җәя.

Бу исемнәр Коръәндә фигыль төрләнешендә искә алыналар, мәсәлән: [әл-Бәкара:245], ләкин пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә исем буларак зикер ителәләр, Аллаһу әгьләм.

الْمُقَدِّمُ، الْمُؤَخِّرُ

(85) әл-Мукаддим (Алга Чыгаручы), **(86) әл-Мү’аххыйр** (Артка Калдыручы)

Алдагы исемнәр кебек, бу ике күркәм исем дә капма-каршы исемнәр буларак аларны бер-берсеннән аерып Аллаһны берсе белән генә искә алырга һәм мактарга ярамый, ә бәлки икесе бергә искә алынулары тиешле.

әл-Мукаддим – Аллаһ Үзенең теләге буенча кайбер нәрсәләрне алга чыгара һәм хикмәт вә хаклык йөзеннән һәрнәрсәне үз урынына куя. Мәсәлән: Ул тәкъдирне мәхлукатлардан алга чыгарды, кайбер халыкларны икенчеләреннән алга чыгарды, Үзенең яраткан колларын дәрәҗәләрдә алга чыгарды, пәйгамбәребезне башка пәйгамбәрләрдән шәрәфлектә алга чыгарды, пәйгамбәрләрне башкалардан алга чыгарды һ.б.

әл-Мүәаххыйр – Аллаһ Үзенең теләге буенча кайбер нәрсәләрне артка калдыра һәм хикмәт вә хаклык йөзеннән һәрнәрсәне үз урынына куя.

Бу исемнәр пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (әл-Бухари:1120) зикер ителәләр, Аллаһу әгьләм.

الرَّفِيقُ

(87) әр-Рафийкъ
(Йомшаклык Иясе)

әр-Рафийкъ – Аллаһ Үзенең эшләрендә Йомшаклык Иясе. Ул мәхлукатларны Үзенең хикмәте вә йомшаклыгы белән акрынлап юктан бар кылды, югыйсә Ул бит аларның барысын берьюлы, бер мизгелдә бар кылырга кодрәтле.

Аллаһ Үзенең әмерләрендә, тыюларында Йомшаклык Иясе. Ул Үзенең колларына берьюлы гына авыр йөкләмәләр йөкләми, ә бәлки аларның кү-

целләре йомшарсын вә холыклары ияләшсен өчен акрынлап кына, бер халәттән икенчесенә күчеп йөкли. Мисал итеп Аның колларына уразаны фарыз кылуын, исерткечне, рибаны тыюын китерергә мөмкин. Һ.Б.

Бу исем пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (әл-Бухари:6024) зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

ٱلْمَنَّانُ

(88) **әл-Мәннәән** (Нигъмәтләүче)

әл-Мәннәән – Аллаһ Нигъмәтләүче. Ул Үзенең колларын яшәү-тормыш, гакыл, сөйләшү, ишетү, күрү, күркәм сурәт, һидәят кебек бик күп төрле күренгән вә күренмәгән нигъмәтләр белән нигъмәтләде. Аның нигъмәт кылуының ахыры вә чиге юк һәм Ул соралганчы Нигъмәтләүче. Кешеләргә биргән, аларны нигъмәтләгән иң зур бүләкләрдән – пәйгамбәребез Мө-

хәммәднең ﷺ килүе. Чөнки аның аша Аллаһ тәгалә кешеләрне адашудан коткарды.

Бу исем Коръәндә фигыль төрләнешендә искә алына, мәсәлән: [Әли-Гыймран:164], ләкин пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (Әбү Дауыд:1495) исем буларак зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْجَوَّادُ

(89) **әл-Җәүүәд** (Мул Бирүче)

әл-Җәүүәд – Аллаһ мотлак Мул Бирүче һәм Үзенең мул бирүе белән бу дөньяда гомуми барча мәхлукатларны да чолгап алды. Шулай ук, бу дөньяда Аннан сораучыларга булсын ул мөэмин яки кәфер, изге яки гөнаһкәр, аларга аерым муллык күрсәтте.

Аның Мул Бирүче икәненә ишарәт кылган нәрсәләрдән; Үзенең яраткан колларына Җәннәтләрдә күз күрмәгән,

колак ишетмәгән нигъмәтләрне мул итеп бирүдәге вәгъдәсе генә дә ни тора!

Бу исем пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (Сахих әл-Җәмигь:1744) зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

اَلْمُحْسِنُ

(90) әл-Мүхсин
(Күркәмлек Кылучы)

әл-Мүхсин – Аллаһның исемнәре дә, сыйфатлары да һәм эшләре дә камил күркәмлеккә хас. Ул барча нәрсәне дә күркәм итеп бар кылды. Мәсәлән, кешене иң күркәм сыйфатта бар итте: бер күз түгел, ә ике; өч аяк түгел – ике; койрыклы түгел, мөгезле түгел һ.б. Ә хайваннарны аларга тиешле күркәмдә булдырды, мөгезле, койрыклы, йонлы һ.б. Ул барча мәхлукатларны да үзләренә тиешле күркәм итеп халикъ кылды. Шулай ук, Ул мәхлукатларны төрле нигъмәтләр белән бүләкләп

күркәмлек кылды.

Бу исем Коръәндә фигыль төрләнешендә искә алына, мәсәлән: [әл-Касас:77], ләкин пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (әс-Силсилә әс-Сахиха:469) исем буларак зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

ٱلسِّتِّيرُ

(91) әс-Ситтийр
(Каплаучы, Яшерүче)

әс-Ситтийр – Аллаһ колларының гаепләрен, кимчелек-хаталарын башкалардан каплый, яшерә, һәм шулай ук, Ул колларының да үзләренең гаеп-хаталарын каплаганны, яшергәнне вә ачып фаш кылмаганны ярата. Мөселманны каплап яшергән кешене Аллаһ бу дөньяда да, ахирәттә дә каплап яшерә. Шуның өчен дә, кеше үзенең гөнаһ-хаталарын башкаларга сөйләп ачып фаш кылмаска тиеш,

ә бәлки киресенчә яшерен рәвештә Раббысына тәүбә кылырга тиешле.

Бу исем пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (Әбү Дауыд:4012) зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الدَّيَّانُ

(92) **әд-Дәййән** (Тиешле Җәзасын Бирүче; Буйсындыручы)

әд-Дәййән – Аллаһ барча мәхлукатларны хисаб кылачак һәм тиешле җәзасын бирәчәк. Кем күркәм гамәл кылса – аңа Җәннәт, ә кем яман гамәл кылса – аңа Ут. Аңа барчасы да буйсына, Ул Хөкемдар, Казый, Буйсындыручы.

Бу исем пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (әл-Мүстәдрак:әл-Хәким) зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

الشَّافِي، الطَّبِيبُ

(93) әш-Шәфий (Шифалаучы, Шифа Бирүче), **(94) әт-Табийб** (Табиб)

әш-Шәфий – Шифалаучы – авыру-чирләрдән арындыручы димәктер. Тән һәм йөрәк чирләреннән Бер Аллаһ тәгалә генә чын-хакыйкый Шифалаучы. Аның шифасыннан башка шифа юк, һәм Ул гына авыру-чирләрдән арындыра.

әт-Табийб – Ул, чир-авыруның вә дәваның хакыйкатен Белүче, һәм сихәт-сәламәтлек вә шифа бирергә Аллаһ кына кодрәтле димәктер.

Бу ике күркәм исем Коръәндә искә алынмый, ә бәлки пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (әл-Бухари:5675), (Әбү Дауыд:4207) зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

اَلسَّيِّدُ

(95) **əс-Сəйид** (Әфəнде, Хуҗа)

əс-Сəйид – Аллаһ барча мəхлукълар белəн хакимлек итүче Әфəнде, Патша вə аларны химая кылучы Хуҗа. Аның əфəнделеге Аңа гына хас рəвештə камил вə мотлак, кешелəрнеке кебек кимчелекле вə тар түгел, ə мəхлукатлар һəммəсе дə Аның коллары.

Бу исем пəйгамбəребезнең ﷺ хəдислəрендə (Әбү Дауыд:4806) зикер ителə, Аллаһу əгълəм.

اَلْوِتْرُ

(96) **əл-Үитр** (Так, Берүзе)

əл-Үитр – Аллаһ Так, Берүзе генə. Аның тиңе дə, ише дə, охшашы да, иптəше дə юк. Аллаһ барча мəхлукатларны да (булсын ул кешелəр, хайваннар, үсемлеклəр һ.б.) парлы итеп

яратты, һәм алар парсыз дәвамлы була алмыйлар. Мәхлукатларга берүзләре булу ят нәрсә, ә Аллаһ һичнәрсәгә-һичкемгә мохтаҗ түгел.

Бу исем пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (әл-Бухари:6410, Мөслим:2677) зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْحَيِيُّ

(97) **әл-Хәйий** (Оялчан)

әл-Хәйий – Без Аллаһның оялчанлыгына иман китерәбез һәм ул оялчанлык Аның Үзенә генә хас рәвештә вә мәхлукъларныкына охшамаганлыкка инанабыз. Дөреслектә, Аллаһ тәгалә Оялчан, Ул оялганны ярата, шуңа да әгәр кол үзенең кулларын күтәреп Раббысыннан нәрсәдер сорый икән, Раббысы аның кулларының буш төшүеннән ояла. Аның оялчанлыгына аң ирешә алмый, ничеклеген гакыл белә алмый.

Бу исем пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (Әбү Дауыд:4012) зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الطَّيِّبُ

(98) **әт-Тайиб** (Яхшы)

әт-Тайиб – Аллаһтан яхшылык кына чыга, вә Аңа да яхшылык кына күтәрелә. Аңа яхшылар гына якыная вә Ул яхшылык чыганагы һәм аның ахыргы чиге дә Аңарда.

Аллаһ мотлак Яхшы. Шулай булгач барча яхшы гамәлләр, яхшы сүзләр, яхшы сыйфатлар вә яхшы исемнәр Аңа гына һәм моңа Аннан башка беркем дә лаек түгел. Аннан башка булган барча яхшылыклар Аның яхшылыгыннан.

Бу исем пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (Мөслим:1015) зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

الْمُعْطِي

(99) **әл-Мүгьтый** (Бирүче)

әл-Мүгьтый – Аллаһ биргәнне тыючы юк, ә Ул тыйганны бирүче юк. Аның бирүе киң һәм аның чиге юк. Ул дөньяда кәферләргә дә, мөэминнәргә дә, барча колларына да бирә, ә ахирәттә Аның бирүе вә фазыйләте иллә-мәгәр мөэминнәргә генә була.

Аллаһның бирүе киң һәм ул барча бирелгән вә бүләк ителгән нәрсәләрне биләп ала, ә иң зур бирелгән бүләк ул – иман вә һидәят.

Ул һәрнәрсәгә-һәркемгә тиешле шәкелен бирде, Үзенең тәрбиясенә алды һәм ризыгын бирде.

Аллаһ нәрсә булса да бирә икән, Ул аның өчен кимсенми, ә бәлки колларына яратып вә күп итеп бирә.

Бу исем пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (әл-Бухари:3116) зикер ителә, Аллаһу әгьләм.

ٱلْجَمِيلُ

(100) **әл-Җәмийл** (Матур)

әл-Җәмийл – Аллаһ Үзенең Затында да, исемнәрендә дә, сыйфатларында да, эшләрендә дә Матур. Аның Затының матурлыгын кеше күз алдына да, уена да китереп бетерү мөмкин түгел. Хәтта Җәннәт әһелләре даими нигъмәттә, бәхет-шатлыкта, санап вә әйтеп бетергесез рәхәттә була торып та, Раббыларын күргәч вә Аның матурлыгы белән рәхәтләнгәч үзләренең хәлләрен онытырлар.

Бу исем пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә (Мөслим:91) зикер ителә, Аллаһу әгъләм.

Әлхәмдулиллаһ, Аллаһның теләге һәм ярдәме илә хәерле вә изге гамәлләр тәмамлана. Пәйгамбәребезгә ﷺ вә аның йорт әһелләренә, сахәбәләренә һәм Кыяматкә кадәр аңа ияргән барча кешеләргә салават вә сәламнәребез булсын!

ЭЧТӘЛЕК

Зикернең фазыйләте..........................3
Дога кылуның әдәпләре...............9
Дога кабул була торган вакытлар һәм урыннар.......................................12
1 – Йокыдан уянгач та укыла торган зикер-догалар..............................14
2 – Кием кигәндә укыла торган дога..16
3 – Яңа кием кигәндә укыла торган дога..17
4 – Яңа кием киючегә әйтелә торган дога..18
5 – Кием салгач әйтелә..............18
6 – Бәдрәфкә кергәндә укыла торган дога..18
7 – Бәдрәфтән чыккач укыла торган дога..19
8 – Таһәрат алдыннан әйтелә...19
9 – Таһәрат алганнан соң әйтелә торган дога..20
10 – Өйдән чыкканда укыла торган дога..21

11 – Өйгә кергәндә укыла торган дога..21
12 – Мәчеткә барганда укыла торган дога..22
13 – Мәчеткә кергәндә укыла торган дога..23
14 – Мәчеттән чыкканда укыла торган дога..24
15 – Азан әйткәндә укыла торган зикер-догалар..25
16 – Истифтәх догасы..27
17 – Рөкүгь догасы..29
18 – Рөкүгьтан торгач укыла торган дога..30
19 – Сәҗдә догасы..31
20 – Ике сәҗдә арасында утырганда укыла торган дога..32
21 – Тиләвә сәҗдәсенең догасы..33
22 – Тәшәһһүд догасы..35
23 – Тәшәһһүдтән соң салават догасы..36
24 – Салаваттан соң, сәлам алдынан әйтелә торган дога..38

25 – Намаз ахырында, сәламнән соң укыла торган догалар..............41
26 – Истихара (хәерлене сорау) намазының догасы..........................49
27 – Иртә һәм кич укыла торган догалар..52
28 – Йоклар алдыннан укыла торган догалар.....................................75
29 – Төнлә йоклый алмыйча боргаланып ятканда укыла торган до га...83
30 – Йоклаганда төшендә куркучы һәм борчылучы укый торган дога...84
31 – Начар төш күргәндә нәрсә эшләргә...85
32 – Витр намазындагы кунүт догасы...85
33 – Витр намазында сәламнән соң укыла торган зикер-дога......88
34 – Тынычсызлык һәм ямансу биләп алганда укыла торган дога...89
35 – Олы кайгы килгәндә укыла

торган дога......................................92
36 – Дошман яки гаделсез хөкемдарлар белән очрашудан курыкканда укыла торган дога...93
37 – Патша золымыннан куркучы укый торган дога..............................94
38 – Дошманга каршы укыла торган дога..96
39 – Берәрсеннән курыкканда укыла торган дога...........................96
40 – Иманында шикләнүче кеше укый торган дога...........................97
41 – Бурычларны түләү өчен ярдәм сорап укыла торган дога..............98
42 – Намаз һәм Коръән укыганда шәйтан вәсвәсәсеннән саклану догасы..100
43 – Кешегә берәр эш авыр күренгәндә укыла торган дога....101
44 – Гөнаһ кылган кеше нәрсә эшләргә һәм укырга тиеш...........101
45 – Шәйтанны һәм аның вәсвәсәсен куа торган дога...................102
46 – Кешегә берәр нәрсә ошама-

ганда яки бернәрсә дә эшли алмаган очракта укыла торган дога...103
47 – Баласы туган кешегә котлап әйтелә торган дога һәм аңа җавап...104
48 – Балаларны саклау өчен укыла торган дога...104
49 – Авыруны зиярат кылганда укыла торган дога...105
50 – Авыруны зиярат кылуның фазыйләте...106
51 – Яшәү өметен югалткан авыруның догасы...107
52 – Үлүчегә тәлкыйнь кылу.....109
53 – Кайгыга юлыккан кеше укый торган дога...110
54 – Үлгән кешенең күзләрен йомдыргач укыла торган дога.....110
55 – Җеназа намазы догасы.....112
56 – Сабыйның җеназасында укыла торган дога...113
57 – Тәгъзия догасы...114
58 – Мәетне кабергә куйганда укыла торган дога...115

59 – Мәетне җирләгәч укыла торган дога..116
60 – Каберләрне зиярат кылганда укыла торган дога..............................116
61 – Җил чыкканда укыла торган дога..117
62 – Күк күкрәгәндә укыла торган дога..118
63 – Яңгыр сораганда укыла торган дога..118
64 – Яңгыр яуганда укыла торган дога..120
65 – Яңгыр яуганнән соң укыла торган дога..............................120
66 – Берөзлексез яуган яңгырны туктатуны сорап укыла торган дога 121
67 – Яңа туган ай күргәндә укыла торган дога..............................121
68 – Авыз ачканда укый торган дога..122
69 – Ашар алдыннан укый торган дога..123
70 – Ашаганнан соң укыла торган

дога..125
71 – Мәҗлес хуҗасы өчен укыла торган дога..125
72 – Су эчерүчегә яки эчерергә теләүче өчен укыла торган дога...126
73 – Авыз ачучы, мәҗлес хуҗасына карата укый торган дога.........127
74 – Әгәр ризык китерсәләр, ә ураза тотучы уразасын өзергә теләмәсә нинди дога укырга тиеш...
....128
75 – Әгәр ураза тотучыны берәү сүксә, ул нәрсә әйтергә тиеш......128
76 – Беренче өлгергән җимешләрне күргәч укыла торган дога......129
77 – Төчкергәннән соң укыла торган дога..130
78 – Әгәр кәфер төчкерсә һәм Аллаһны мактаса, аңа нәрсә әйтелергә тиеш...131
79 – Яңа өйләнгәннәрне котлап укыла торган дога..........................131
80 – Өйләнгән кеше укый торган дога..132

81 – Хатын белән җенси якынлык кылыр алдыннан укыла.................133
82 – Ачуланганда укыла............134
83 – Бәла-казага ирешүчене күргәндә укыла торган дога...............134
84 – Нинди дә булса җыенда яки мәҗлестә укыла торган дога.......135
85 – Җыен-мәҗлес ахырында укыла торган дога.........................136
86 – «Аллаһ сине ярлыкасын», — диючегә укыла торган дога..........137
87 – Сиңа яхшылык эшләгән кешегә әйтелә торган дога...........137
88 – Аллаһ мөселманны Дәҗҗәлдән саклый торган дога-зикер.....137
89 – «Дөреслектә, мин сине Аллаһ өчен яратам», — дигән кешегә карата укыла торган дога.........................138
90 – Сиңа үзенең акча-байлыгын тәкъдим итүче кешегә укыла торган дога...139
91 – Бурычны кайтарганда укыла торган дога...............................139
92 – Ширектән курыкканда укы-

ла торган дога....................................140
93 – Әгәр дә берәү сиңа: «Аллаһ сиңа бәрәкәт бирсен!» /Бәракә-Аллаһү фикә/ – дисә, ничек җавап бирелә....................................141
94 – Хорафатларга ышанмауны вә яратмауны белдереп укыла торган дога....................................141
95 – Машинага, атка яки нәрсәгә булса да утырганда укыла торган до га....................................142
96 – Сәфәр догасы....................144
97 – Шәһәр-авылга кергәндә укыла торган дога....................................146
98 – Базарга кергәндә укыла торган дога....................................148
99 – Менге ат кебек атланып йөри торган хайван абынса укыла торган дога....................................149
100 – Мөсафирның мөкыймга укый торган догасы....................149
101 – Мөкыймнең мөсафирга укый торган догасы....................150
102 – Сәфәрдә тәкбир һәм тәс-

бих...151
103 – Мөсафирның таң алдыннан укый торган догасы...........................151
104 – Сәфәрдә чакта яки башка вакытта берәр өйдә тукталганда укыла торган дога...........................152
105 – Сәфәрдән кайтканда укыла торган дога...........................153
106 – Берәр нәрсәгә шатланганда яки инде берәр нәрсә ошамаганда укыла торган дога...........................155
107 – Пәйгамбәргә ﷺ салават әйтүнең фазыйләте...........................156
108 – Сәламләшү...........................157
109 – Кәфернең сәламенә ничек җавап бирергә...........................159
110 – Әтәч кычкырганда яки ишәк акырганда укыла торган дога.....160
111 – Төнлә эт өргәндә укыла торган дога...........................160
112 – Синең тарафтан рәнҗетелгән кешегә карата укыла торган дога...........................161
113 – Бер мөселман икенче мөсел-

манны мактаганда укыла торган до га..162
114 – Әгәр мөселманны мактасалар, макталган мөселман укый торган дога....................................163
115 – Мөхримнең хаждa яки гомрәдәге тәлбиясе..................................164
116 – Кәгъбәтуллаһның Кара Таш булган почмагына җиткәч тәкбир әйтү...165
117 – Кәгъбәтуллаһның Йәмән почмагы белән Кара Таш почмагы арасында кылына торган дога....165
118 – Сафә һәм Мәръвә калкулыкларында басып торганда укыла торган дога......................................166
119 – Гарафә көнендә укыла торган дога...168
120 – «әл-Мәшгар әл-Хәрам» дигән урында укыла торган зикерләр...169
121 – Баганага таш атканда, һәрбер таш белән тәкбир әйтү....170
122 – Гаҗәпләнгәндә яки шатланганда әйтелә торган сүзләр..171

123 – Шатлык килгәндә нәрсә эшләргә....................................172
124 – Тәнендә авырту сизгән кеше укый торган дога..............................172
125 – Үз күзең тиюдән курыкканда бәракәт сорап дога кылырга тиешле....................................173
126 – Курыкканда әйтелә торган сүз......................................173
127 – Мал суйганда әйтелә....174
128 – Шәйтаннарның мәкерләреннән саклану өчен укыла торган до га......................................174
129 – Истигъфар һәм тәүбә.......176
130 – Тәсбих, тәхмид, тәһлил һәм тәкбир әйтүләрнең фазыйләте....179
131 – Пәйгамбәребез ﷺ ничек тәсбих кыла иде..............................187
132 – Изгелекләр һәм гомуми әдәп төрләре..................................188

Ω – ӨШКЕРҮ ТӘРТИБЕ............189

1 – Сихердән дәвалану..........190
Беренче: Сихер ирешкәнче аннан саклану..190
Икенче: Сихер ирешкәннән соң аннан дәвалану................................194
2 – Күз тиюдән дәвалану.......214
Беренче: Күз тиюдән саклану..214
Икенче: Күз тигәннән соң дәвалану..216
Өченче: Көнчел кешенең яман күзеннән саклану чаралары........218
3 – Кешегә җен керүдән дәвалану...221
Беренче: Җен керүдән саклану..221
Икенче: Җен кергәннән соң дәвалану..221
Җен керү сәбәпле акылдан язган кешеләрдән җен чыгару хакында кайбер хәдисләр..............................224
Җеннең имам Әхмәдкә буйсынуы турында риваять.............................229

4 – Эренле яраларны вә җәрәхәтләрне дәвалану........................232
5 – Чирле кешенең үз-үзен дәвалауы..233
6 – Авыруның хәлен белгәндә, аны дәвалау догасы...................234
7 – Бизгәк чипен дәвалау......235
8 – Агулы еланнар һәм хәшәрәтләр чагуыннан дәвалау.......235
9 – Кара тмин орлыгы белән дәвалану..236
10 – Бал белән дәвалану........237
11 – Зәмзәм белән дәвалану..238

❁❁❁

Ω – ИСМЕ ӘГЪЗАМ..................241

Нинди исем Исме Әгъзам?.........242
1 – Аллаһ..................................250
2 – әр-Рабб...............................251
3 – әл-Үәхид..............................251
4 – әл-Әхәд...............................252
5 – әр-Рахмән............................252

6 – әр-Рахийм....................................253
7 – әл-Хәий....................................254
8 – әл-Каййүм....................................254
9 – әл-Әүүәл....................................255
10 – әл-Әәхыйр....................................256
11 – әҙ-Ҙаһир....................................257
12 – әл-Бәтыйн....................................257
13 – әл-Үәриҫ....................................258
14 – әл-Куддүс....................................259
15 – әс-Сүббүх....................................260
16 – әс-Сәләм....................................260
17 – әл-Мү'мин....................................261
18 – әл-Хәккъ....................................264
19 – әл-Мүтәкәббир....................................265
20 – әл-Гаҙыйм....................................265
21 – әл-Кәбийр....................................266
22 – әл-Галий....................................267
23 – әл-Әгьлә....................................268
24 – әл-Мүтәгал....................................269
25 – әл-Ләтыйф....................................270
26 – әл-Хәкийм....................................270
27 – әл-Үәсигь....................................271
28 – әл-Гаалим....................................272
29 – әл-Галийм....................................272

30 – Галләм әл-гуйүб..........................272
31 – әл-Мәлик..........................275
32 – әл-Мәәлик..........................275
33 – әл-Мәлийк..........................275
34 – әл-Хәмийд..........................276
35 – әл-Мәҗийд..........................277
36 – әл-Хабийр..........................279
37 – әл-Кауий..........................280
38 – әл-Мәтийн..........................280
39 – әл-Газийз..........................281
40 – әл-Каһһәр..........................282
41 – әл-Кадир..........................283
42 – әл-Җәббәр..........................283
43 – әл-Халикъ..........................284
44 – әл-Бәри'..........................285
45 – әл-Мүсауиир..........................286
46 – әл-Мүһәймин..........................286
47 – әл-Хәфийҙ..........................287
48 – әл-Үәлий..........................288
49 – әл-Үәкийл..........................289
50 – әл-Кәфи..........................290
51 – әс-Самәд..........................291
52 – әр-Разикъ..........................292
53 – әр-Раззәкъ..........................292

54 – әл-Фәттәәх..............................293
55 – әл-Мүбийн..............................295
56 – әл-Һәәдий..............................296
57 – әл-Хәәким..............................297
58 – әл-Хәкәм..............................297
59 – әр-Ҕаууф..............................298
60 – әл-Үәдүүд..............................300
61 – әл-Бәрр..............................301
62 – әл-Хәлийм..............................302
63 – Гафиру әҙ-ҙәнби..............................303
64 – әл-Гафур..............................303
65 – әл-Гаффәръ..............................303
66 – әл-Гафүү..............................304
67 – әт-Тәүүәб..............................306
68 – әл-Ҡәрийм..............................307
69 – әл-Әкрам..............................307
70 – әш-Шәәкир..............................308
71 – әш-Шәкүүръ..............................308
72 – әс-Сәмийгъ..............................309
73 – әл-Бәсыйрь..............................311
74 – әш-Шәһийд..............................312
75 – әр-Ракыйб..............................312
76 – әл-Ҡарийб..............................313
77 – әл-Мүжҗийб..............................314

78 – әл-Мүхийтъ........................315
79 – әл-Хәсийб........................316
80 – әл-Ганий........................317
81 – әл-Үәһһәб........................318
82 – әл-Мүкыйт........................318
83 – әл-Кабидъ........................319
84 – әл-Бәситъ........................319
85 – әл-Мүкаддим........................321
86 – әл-Мү'аххыйр........................321
87 – әр-Рафиийкъ........................322
88 – әл-Мәннән........................323
89 – әл-Җәүүәд........................324
90 – әл-Мүхсин........................325
91 – әс-Ситтийр........................326
92 – әд-Дәййән........................327
93 – әш-Шәфий........................328
94 – әт-Табийб........................328
95 – әс-Сәийд........................329
96 – әл-Үитр........................329
97 – әл-Хәийй........................330
98 – әт-Таийб........................331
99 – әл-Мүгьтый........................332
100 – әл-Җәмийл........................333

❀❀❀

9 785905 607196

По вопросам оптовых закупок
обращайтесь по адресу:
423570, Республика Татарстан,
г. Нижнекамск, пр. Химиков, 59
"ООО Издательский центр Рисаля"
Тел.: 8-917-258-63-16
E-mail: Risalacentr@gmail.com

Заказ дисков и книг на сайте:
WWW.ISLAMCD.RU

Матбугат үзәге
Рисаля
Издательский центр